4. “Түгәрәк эчендә кал” уены. Укучылар түгәрәк рәвешендә тезеләләр. Музыкаль көй барышында укучылар флеш-картаны кулдан кулга җибәрәләр. Музыка кисәк кенә туктала. Флеш-карта кемнең кулында кала, шул укучы рәсемдәге сурәтнең атамасын әйтергә тиеш була. Әйтә алмаган очракта, ул түгәрәк эченнән чыгып китә. Биредә музыкаль бизәлеш тә мәгънәгә ия булырга тиеш, дип уйлыйбыз. Ул дәртле татар бию көе буларак сайланыла ала, бу очракта укучыларга тизлек белән карточканы кулдан-кулга тапшыруга өстәмә стимул хасил була, яки теге яки бу һөнәр иясенә багышланган җыр да (“Сез иң гүзәл кеше икәнсез”, “Ак чәчәкләр” һ.б.лар) уенның ямен арттырыр.

Нәтиҗә ясап, шуны әйтергә кирәк: флеш-карталар һәм алар нигезендә оештырылган дидактик уеннар ярдәмендә лексик күнекмәләрне формалаштыруда ике юнәлештә дә нәтиҗәле эш алып барырга мөмкин: беренчедән, сүзнең семантикасы аңлатыла, икенчедән, лексик берәмлекне сөйләмдә куллану автоматлаштырыла.

**ӘДӘБИЯТ**

1. Мещерякова В.Н. Татар теле – илем теле: рус теленә гомуми белем бирү оешмалары өчен уку әсбабы: 2 кисәктә, 2 нче кис. = Татарский язык – язык моей родины: учеб. пособие для общеобразовательных организаций с обучением на русском языке: в 2 частях. Ч. 2. / В.Н. Мещерякова, Р.Р. Нигматулина. – Казань: Татар. кн.изд-во, 2016. – 75 с.

2. Пассова Е.И., Кузнецова Е.С. Формирование лексических навыков / Е.И. Пассова, Е.С. Кузнецова. – Воронеж: НОУ “Интерлингва”, 2002. – 40 с.

**И.И. ГАБИЗОВ**

*Казан федераль университеты, Россия*

## ХӘЗЕРГЕ ВАКЫТЛЫ МАТБУГАТТА СҮЗЬЯСАЛЫШЫ (“ЯЛКЫН” ЯШҮСМЕРЛӘР ЖУРНАЛЫ ҺӘМ “ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН” ГАЗЕТАСЫ МИСАЛЛАРЫНДА)

**Аннотация.** В данной статье анализируются слова, образованные суффиксальным способом в журнале “Ялкын” и газете “Ватаным Татарстан”. В современном СМИ отражается богатство словарной системы татарского языка. С помощью разных способов словообразования появляются новые слова. Наиболее активными являются сложение, суффиксальный и лексико-семантический способы, часто встречаются заимствованные слова с татарскими словообразовательными суффиксами. Также выявилась большая активность заимствований с английского языка через русский язык.

**Ключевые слова**: Лингвистика, СМИ, словообразование

**Abstract.** This article analyzes the words formed by the suffix method in the magazine “Yalkyn" and the newspaper "Vatanym Tatarstan". The modern media reflects the richness of the vocabulary system of the Tatar language. With the help of different ways of word formation, new words appear. The most active are addition, suffixal and lexico-semantic methods, borrowed words with Tatar word-forming suffixes are often found. There was also a great activity of borrowing from English through Russian.

**Keywords:** Linguistics, mass media, word formation

Хәзерге татар теленең лексикасын бай сүзләр системасы һәм аларның мәгънәләре тәшкил итә. Анда төрле структураларга һәм стильләргә караган йөзләрчә мең сүзләр бар. Татар теленең лексик байлыгы, башка телләрдәге кебек үк, кинәт кенә барлыкка килмәгән. Анда акрынлап яңа сүзләр барлыкка килгән, яшәп килгән сүзләрнең мәгънәләре киңәйгән. Бу процесс халыкның сәяси, икътисади һәм мәдәни тормышы белән бәйле рәвештә барган. Әлеге мәкаләдә соңгы елларда басылган “Ялкын” журналында, “Ватаным Татарстан” газетасында сүзьясалышына кыскача күзәтү бирелә.

Татар телендә киң таралган, иң актив сүзьясалыш ысулларының берсе – кушымчалау ысулы. Телнең үсеш процессында күп санлы ясалма сүзләр ясаган традицион кушымчалар продуктивлыгын югалтмаган. Мәсәлән, исем ясагыч кушымчалар:-чы/ -че: “Фотограф аккаунты бар, ләкин я**зылучылар** юк” (Ялкын, 2020, № 12: 15). -лык/ -лек :“Фотографлар үз *актуальлеген* югалмаячаклар” (Ялкын, 2020, № 12, 14). Телнең үзенең ясагыч кушымчалары татар теле сүзләре нигезләренә ялганып ясалган сүзләр белән бер үк текстта алынма сүзләргә ялганып яңа сүзләр ясалу очраклары да еш күзәтелә: *креатив+лык, актуаль+лек* һ.б. Шулай ук соңгы елларда кушымчалау ысулы ярдәмендә барлыкка килгән һәм исем сүз төркеменә кертеп каралган сүзләрнең шактый булуын түбәндәге җөмләләрдә кулланылган ясалма сүзләр дә дәлилли. “Бирем *креативлыкны* үстерә һәм аны һәркем үти ала” (Ялкын, 2020, № 12: 12). Әлеге сүз бүгенге көндә сүзлекләргә кертелмәгән. “Фотографлар үз *актуальлеген* югалмаячаклар” (Ялкын, 2020, № 12, 14) җөмләсендәге ясалма исемне (*актуальлек)* сүзлекләрдә очратырга була. Без карап узган әлеге мисалларда яңа барлыкка килгән ясалма исемнәрнең нигезен алынмалар (*креатив+лык, актуаль+лек*) тәшкил итә. Түбәндәге җөмләдә *либертариан* сүзенә -*лык* исем ясагыч кушымчасы ялганган: “*Либертарианлык*” дигән сәяси фикер юнәлешендә “ирек” иң әһәмиятле төшенчә булып тора (Ялкын, 2020, № 3, 12) һәм әлеге сүз сүзлекләрдә әлегә урын алмаган. Кайбер фигыль ясагыч кушымчалар да текстларда алынмаларга да ялганып, яңа лексик берәмлек барлыкка китергән: “Танымаслык итеп “*фильтрланган*” фотоларга карагач, кызык булып китә” (Ялкын, 2020, № 12: 32) җөмләсендәге *фильтрланган* фигыле алынма сүз нигезендә барлыкка килгән һәм хәзерге вакытта сүзлекләргә кертелмәгән. “Казан, чөнки шәһәрне үстерергә һәм *модернизацияләүгә* мөмкинлекләр бар, ә Мәскәү болай да камил” (Ялкын, 2020, № 3: 7) җөмләсендәге *модернизацияләә* фигыле шулай ук алынма нигезгә -лә ясагыч кушымчасы ялганудан барлыкка килә. Әлеге сүз сүзлекләрдә бар һәм халык телендә кулланылышта йөри дигән сүз. Түбәндәге ясалма фигыльләргә игътибар итик: 3D-*модельләштерү*, электроника *прототиплаштыру* (Ялкын, 2020, № 3: 14 бит); *авиамодельләштерү* (Ялкын, 2020, № 3: 14 бит); *программалаштыра* (Ялкын, 2020, № 3: 15 бит). Алар барысы да бер үк төрле кушымча һәм алынма нигез ярдәмендә ясалган. *Модельләштерү, программалаштыру* сүзләре электрон сүзлекләр фондына кертелгән булса, калган сүзләр әле дә булса гомумкулланылышта түгел.

Сыйфат сүз төркемен ясаган яңа лексик берәмлек дә бар: “Алар актив, *амбицияле* – зур максатлар куя беләләр, креатив – яңача фикер йөртәләр” (Идел, 2020, № 11: 3). Әлеге җөмләдәге амбиция+ле сүзенең нигезе алынма сүздән

гыйбарәт. Илдә килеп туган вәзгыять нәтиҗәсендә, кайбер сүзләрнең мәгънәләре яңартылып, алар ешрак кулланыла башлауга да “Ялкын” журналында мисал таптык: “Бер тапкыр урамга *битлексез* чыктым” (Ялкын, 2020, № 12: 22). Бирелгән җөмләдә, коронавирус авыруы таралуга бәйле рәвештә, медицина битлеге турында сүз бара. *Битлек* сүзенә *+сез* сыйфат ясагыч кушымчасы ялгана. *Битлек* нигезенең татарның үз сүзе булуын да искәртергә кирәк. Әлеге сүз сүзлекләргә кертелгән, әмма аның хәзерге вакытта популярлашып киткән мәгънәсе турында аңлатма бирелмәгән.

Тикшерү барышында шундый ике үзенчәлек ачыкланды:

1. Газета-журналлар өлкәнрәк буынга багышланганда, татар сүзләренә кушылып килгән кушымчалар күпчелекне тәшкил итә. Ягъни “Ялкын” журналында күпчелек кушымчалар алынма сүзләргә ялганса, “Ватаным Татарстан” журналында исә мондый еш күренеш түгел, анда татар теленең сүзлекләрендә теркәлгән, традицион сүз ясалышын күрәбез.

2. Газета-журналның нинди буынга каравы шулай ук андагы сүзләрнең ни дәрәҗәдә гомумкулланышка кергәнлеге белән бәйле. Яшүсмерләр һәм яшьләр өчен булган медиа чаралардагы кайбер сүзләр корпусларда һәм сүзлекләрдә кермәгән вакытта (мәсәлән либертарианлык), урта буын өчен булган “Ватаным Татарстан”да теркәлгән сүз ясагыч кушымчалар алган сүзләр сүзлекләр дә, шулай ук корпусларда да теркәлгән.

**Сүзләр кушылу ысулы**. “Ялкын журналында кушма сүзләрнең күпчелеге татар теленең үз сүзенә алынма ялганып ясалган: “Сәясәт һәм фәлсәфәне видеоуен аша” (Ялкын, 2020, № 3: 12). Шулай ук әлеге журналдагы күп кенә сүзләр татар теле сүзлекләрендә урын алмаган. Чагыштыр: *“Блиц-сораштыру”* (Ялкын, 2020, № 3: 7). *“Онлайн-языщу* түгел инде бу сиңа!” (Ялкын, 2020, № 3: 10); Ә менә түбәндәге җөмләләрдә кулланылган сүзләр исә сүзлекләр фондына кертелмәгән: “Укучыларга *видеокушымталар* һәм текст язу осталыгына мәктәптә өйрәнеп калырга кирәк” (Ялкын, 2020, № 12: 10); “Сторислардагы сораштырулар һәм укытучылардан *видеокиңәшләр* өчен ошады” (Ялкын, 2020, № 12: 13); Әлеге төр кушма сүзләр башка газета-журналларда да еш очрый: “*Социаль челтәрләрдән һәм интернет-кибетләрдә* әйбер сатып алу” (Ватаным Татарстан, 2020, № 76: 2); “Имеш, тәмәке тартучылар арасында *таҗвирус* белән авыручылар аз, аларның организмы вируска бирешми” (Ватаным Татарстан, 2020, № 76: 3).

**Конверсия**. Конверсия ысулына килгәндә, яңа сүзләр ясау өчен, яки бу ысул белән ясалган мисаллар очрата алмадык, әлеге ысул тел белемендә актив ысул дип исәпләнә, ләкин безнең чыганаклар моны расламады.

**Аббривиаця.** Каралган газета-журналларда инде күп вакытлар кулланылышта йөрүче сүзләр белдән беррәттән (ЮХИДИ, Татмедиа һ.б.) телебезгә яңа гына кереп барган сүзләрне дә еш очратырга була: “Шаян-ТВ, “Әйдә ШаяРТ. Шуны әйтергә кирәк: “Ялкын” журналында аббривиаця ысулы белән ясалган сүзләр калган газета-журналларга караганда ешрак очрый. Мисаллар: Админ, имеш... – дуслар лидерлыкны болай җиңел генә бирергә теләмәде (Ялкын, 2020, № 11: 46); - Хәзер мин “Сәләт-Яр Чаллы” аланы *сәлкеше* (Ялкын, 2020, № 3: 5). Югарыда китерелгән кыскартылмалар халык телендә актив кулланылышта булмаса да, яшьләр иркен куллана.

Бүгенге көндә сүз ясау ысулларының иң актив куллана торганнары ул кушымчалау һәм сүзләр кушу ысулы. Кушымчалауга килгәндә, иң актив ясала торган сүз төркемнәр – исем һәм фигыль ясагыч кушымчалар (-чы/че, -лык/-лек, -ла/-лә). Шулай ук аббривиация ысулы белән яңа сүз ясау шактый актив.

Икенче үзенчәлек – алынма сүзләргә ясагыч кушымчалар ялганып, яңа сүзләр ясау шактый еш күзәтелә, бер компоненты алынма булган кушма сүзләр дә яшьләр журналларында урын алган.

**ӘДӘБИЯТ**

1. Ганиев Ф.Ә. Хәзерге татар әдәби телендә сүзьясалышы: төзәт. 3 нче басма / Ф.Ә. Ганиев. – Казан: Мәгариф, 2009. – 271 б.

2. Зәкиев М.З. Татар теле морфологиясенә кереш // Хәзерге татар әдәби теле морфологиясе / М.З. Зәкиева, З.М. Вәлиуллина, К.З. Зиннәтуллина, М.Ә. Сәгыйтов. – Казан, 1972. – 206 б.

3. Тумашева Д.Г. Хәзерге татар әдәби теле. Морфология / Д.Г. Тумашева. – Казан: КДУ нәшр., 1978. – 221 б.

4. Ганиев Ф.А. Современный татарский литературный язык. Словообразование по конверсии / Ф.А. Ганиев. – Казань: Дом печати, 2004. – 160 с.

**И.Р. ГАЗИЗОВА**

*Казан федераль университеты, Россия*

# МИЛЛИ МӘДӘНИЯТ РЕАЛИЯЛӘРЕ ҺӘМ АЛАРНЫ ТАТАР ТЕЛЕНӘ ТӘРҖЕМӘ ИТҮ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ (Ч. АЙТМАТОВНЫҢ «БУРАННЫЙ ПОЛУСТАНОК» («И ДОЛЬШЕ ВЕКА ДЛИТСЯ ДЕНЬ») ӘСӘРЕ МИСАЛЫНДА)

**Аннотация.** В данной статье исследуются проблема перевода без эквивалентной лексики на материале Ч. Айтматова «Буранный полустанок» («И дольше века длится день). Рас-

сматриваются способы передачи реалий с русского языка на татарский язык. Изучение проблем перевода мирового писателя на татарский язык представляет большой интерес в теории перевода и литературе.

**Ключевые слова:** Айтматов, перевод, татарский язык, реалии, транскрипция,

**Abstract.** This article examines the problem of translation without equivalent vocabulary on the material of Ch. Aitmatova «Buranniy polustanok» («And the day lasts longer than a century»). The ways of transferring realities from Russian to Tatar are considered. The study of the problems of translating a world writer into the Tatar language is of great interest in translation theory and literature.

**Key words:** Aitmatov, translation, Tatar language, realities, transcription,

Тәрҗемәдә милли-мәдәни үзенчәлекләрне бирү һәм чыганак текстның кабатланмас колоритын саклап калу проблемасы тәрҗемәчеләр өчен бик мөһим. Соңгы вакытта тел белгечләре аерым бер этносның милләтара-мәдәни үзенчәлекләрен билгеләүче тел фактларын эзләү белән кызыксыналар. Тәрҗемә ителә торган телдә «чит реалияләрне» бирү белән бәйле мәсьәләләр турында хезмәтләр чагыштырмача аз язылган һәм бу мәсьәлә шактый катлаулылардан санала.

«Джамиля», «Первый учитель», «Белый пароход», «И дольше века длится день» кебек киң танылу алган әсәрләр авторы Чынгыз Айтматов – чыннан да, әдәбиятка әйтеп бетергесез зур иҗади хәзинә калдырып киткән шәхес.

«Буранный полустанок» («И дольше века длится день») – Чыңгыз Айтматовның беренче романы. 1980 нче елда «Новый мир» журналында дөнья күрә. Әсәр дистәләгән телләргә тәрҗемә ителә, шул исәптән татар теленә дә. Чыңгыз Айтматовның «Буранный полустанок» («И дольше века длится день») романын татар теленә 1990 елда Рим Шириязданов тәрҗемә итә. Татарча «Бер көн – бер гомер» дип атала. Романда вакыйгалар казах далаларында бара. Бу әсәрне сайлау текстта милли үзенчәлекле берәмлекләрнең күп булуына нигезләнә. Бу берәмлекләр казах чынбарлыгының мәдәни, көнкүреш, тарихи күренешләрен чагылдыра. Реалияләр теленнән файдаланып, Ч.Айтматов үзенең милли-мәдәни үзенчәлекләре булган күчмә халык томышын күзәтергә мөмкинлек бирә.

Реалияләрнең иң төгәл классификациясен С.И. Влахов белән С.П. Флорин тәкъдим итә. Алар предмет, вакытка бәйле, урынга бәйле реалияләрне аерып тикшерәләр һәм реалияләрнең түбәндәге классификациясен тәкъдим итәләр:
1) Географик реалияләр: физик география объектлары атамасы (дала, чүл), кеше эшчәнлеге белән бәйле объектлар (ранчо), эндемик атамалары (көнгерә, тал песие); 2) Этнографик реалияләр (халыкның тормыш-көнкүрешенә бәйле сүзләр) (аршын, алты почмаклы өй, калфак); Иҗтимагый-сәяси реалияләр (патша, кызыл армия). [Влахов, Флорин 1980: 70–88].

«Милли мәдәният» реалияләре дигәндә, без Ч.Айтматов әсәрендә чагылыш тапкан казах халкына хас реалияләрне атыйбыз. Реалияләрне без С. Влахов һәм С. Флорин классификацияләренә нигеләнеп тикшердек. Реалияләрне тәрҗемә итү – милли һәм тарихи үзенчәлекләрне мәгънәләрен саклап, укучыга җиткерү дигән сүз. Мәдәният һәм телнең милли үзенчәлекләрен чагылдыра торган предмет-күренешләрне белдергән сүзләрнең мәгънәсен башка телдә дөрес бирү гаять мөһим.

Романда күзәтелгән милли мәдәният реалияләрен С. Влахов, С. Флорин һәм Г. Томахин классификацияләре нигезендә ике төркемгә берләштерергә булыр иде: ономастик һәм этнографик реалияләр. Ономастик реалияләргә һәм аларның тәрҗемәләренә мисаллар карап үтик. Романда түбәндәге торак пункт атамалары очрый: *Сары-Озеки, Кзыл-Орда, Казалинск, Кумбель.* Мәсәлән, *Две замужние дочери Едигея жили совсем в другой стороне – под* ***Кзыл-Ордой*** *– Аларның ике кызы да кияүдә, икесе дә читтә,* ***Кызыл Орда*** *тирәсендә яшиләр.*

Әсәрдә күзәтелгән ойконимнар күп очракта тулы яки өлешчә транслитерация (реалия исемен турыдан-туры алу яки аның тамырын тәрҗемә теле аффикслары белән бергә куллану) алымы белән бирелгән: *Кумбель – Кумбел, Кзыл-Орда – Кызыл Орда.* Бу, һичшиксез, иң киң таралган алым. Нәтиҗәдә реалия тәрҗемә теленә төгәл җиткерелә, аңлашылмаучанлыклар килеп чыкмый.

Әсәрдә кулланылган антропонимнар арасында түбәндәгеләр күзәтелде: *Едигей, Казаке, Буранный Едигей, Шаймерден, Оспан, Казангап, Сауле, Шарапат һәм башкалар.* Төрки чыгышлы исемнәрнең күпләп кулланылуы – вакыйгаларның төрки дөньяда баруы белән аңлатыла. Ялгызлык исемнәр язучы яшәгән милли мәдәният үзенчәлекләрен бик төгәл җиткерә. Мәсәлән, ***Казаке,*** *говорю,* ***Казаке****, может, вам чаю горячего, а он уже. – Якынрак килеп,* ***Казәкә, Казәкә****, кайнар чәй китеримме? – дисәм, ә ул инде.*

Романда очраган реалияләр татар теленә гадәттә транслитерация алымы белән тәрҗемә ителә: *Едигей – Идегәй, Айзада –Айзадә.*

Этнографик реалияләр төркеменә галимнәр көндәлек тормышка, кеше эшчәнлегенә, мәдәнияткә, дингә һәм башка өлкәләргә караган үзенчәлекле сүзләрне кертәләр. Бу төр реалияләр дә Ч.Айтматов әсәрендә күзәтелде. Болар – тормыш-көнкүреш атамалары, ислам диненә бәйле терминнар һәм башкалар. Димәк, тәрҗемәдә дә алар шактый урын ала.

Этнографик реалияләр тәрҗемәдә аеруча зур кызыксыну тудыра. Безгә дин (*омовение – тәһарәт*), мәдәният (*домбра – думбра*), туганлык (*твой ини – энең*), көнкүреш (*юрта – тирмә*) темаларына караган реалияләр һәм аларның ике телдә бирелеше (кайбер очракта алар гомумән төшеп кала) үзенчәлекле то-

елды. Шунысы мөһим: тәрҗемәчеләр һәр реалияне зур игътибар белән, дөрес һәм төгәл тәрҗемә итә, нәтиҗәдә текстның мәгънәсенә төшенү, милли колоритны тулаем күз алдына китерү авыр булмый.

Нәтиҗә ясап әйткәндә, Ч. Айтматовның «Буранный полустанок» («И дольше века длится день») романдагы реалияләр татар теленә нигездә транслитерация, калькалаштыру юлы белән тәрҗемә ителә яки аларның эквивалентлары кулланыла. Транслитерация һәм транскрипция алымын кулланып, Рим Шириязданов реалиянең мәгънәсен төгәл җиткерә, иң мөһиме – чыганак һәм тәрҗемә телләренең төрле тел гаиләләренә керүләренә карамастан, аңлашылмаучанлыклар килеп чыкмавын раслый.

### ӘДӘБИЯТ

1. Айтматов Ч.Т. Бер көн – бер гомер: Роман / Ч.Т. Айтматов. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1990. – 287 б.

2. Айтматов Ч.Т. Буранный полустанок (И дольше века длится день...) / Ч.Т. Айтматов. – М: Советский писатель, 1984. – 304 с.

3. Алексеева И.С. Введение в переводоведение: Учеб. пособие для студ. филол. и лингв. фак. высш. учеб. заведений / И.С. Алексеева. – СПб.: СПбГУ; М.: Издательский центр «Академия», 2004. – 181 с.

4. Влахов С.И. Непереводимое в переводе / С.И. Влахов, С. П. Флорин. – М.: Международные отношения, 1980. – 352с.

5. Юсупов Р.А. Тәрҗемә һәм сөйләм культурасы / Р.А. Юсупов. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2008. – 74 б.

**Р.М. ГАЙФЕТДИНОВА, М.Р. САТТАРОВА**

*Казан федераль университеты, Россия*

## ТАТАР ТЕЛЕНДӘ *[А]* АВАЗЫНЫҢ СҮЗ БАШЫ ПОЗИЦИЯСЕНДӘ АКУСТИК ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

**Аннотация.** В данной статье изучется акустичексие особенности гласного звука [а] в татарском языке. В фонематическом контексте фонема подвергается различным изменениям и чтобы их выявить звук был проанализирован с помощью программы “Speech Analyzer”.

**Ключевые слова:** звук [а], фонематический контекст, акустические особенности, фонетика.

**Abstract.** This article studies the acoustic features of the vowel sound [a] in the Tatar language. In a phonemic context, the phoneme undergoes various changes and, in order to identify them, the sound was analyzed using the “Speech Analyzer” program.

**Key words:** sound [a],  phonemic context, acoustic features, phonetics.

Галимнәр дөньядагы телләр турында мәгълүмат туплар өчен аларны төрле яклап тикшерәләр һәм анализлыйлар. Татар теле дә игътибардан читтә калмыйча, һәр яклап үзебезнең һәм чит ил галимнәре тарафыннан өйрәнелә. Татар телендә авазларның җанлы сөйләм барышында акустик үзгәрешләре турында фәнни хезмәтләр аз күзәтелә, шуңа күрә әлеге тема фәнни күзлектән тел белеменең актуаль мәсьәләсе санала.

Сөйләм барышында авазлар фонематик контекстта килеп бер-берсенә яраклашалар һәм шуңа күрә аларның акустик үзлекләре төрле үзгәрешләргә дучар була. Авазның фонематик контексты күрше авазлар, хәреф һәм фраза басымы булу-булмау һәм кешенең индивидуаль үзенчәлекләре белән аңлатыла.

Әлеге фәнни эшнең максаты – сүз башында килгән *[а]* фонемасының озынлыгын, ешлыгын, интенсивлыгын тикшерү һәм басымның ролен билгеләү. Куелган максатка ирешер өчен татар телендә эмоциональ-экспрессив лексикага бай, әдәби телгә якын булган һәм шул ук вакытта җанлы сөйләм үзенчәлекләренә ия булган “Дию мулла” татар халык әкият тексты һәм аның Илтөзәр Мөхәммәтгалиев тарафыннан укылган аудиоязма варианты алынды. Әлеге тексттан *[а]* авазының сүз башында килгән бер басымлы һәм бер басымсыз сүз сайланылып алынды: ***а́л*** һәм ***авылда́***. Әлеге ике сүзгә дә аудио материалда фраза басымы төшә. Алга таба әлеге ике сүз Speech Analyzer программасы ярдәмендә тикшерелде.

***авылда́*** ***а́л***



*1 нче рәсем*

1 нче рәсемнең астагы өлешендә программа сүзнең һәм авазның спектограммасын (ягъни аваз спектры үзгәрешенең график сурәтен) күзәтергә мөмкинлек бирә. Әлеге график ярдәмендә тавышның авазны әйткән вакытта нинди дәрәҗәдә катнашуын күрә алабыз һәм ул рәсемдә авазларны бер-

берсеннән аерырга ярдәм итә. Шулай итеп, басымлы вариантны әйткәндә тавыш күбрәк кулланыла

1 нче рәсемдә өстәге өлештә сүзнең һәм авазның осцилаграммасын (ягъни сүзне/авазны әйткән вакытта аваз басымының амплитуда үзгәрешен) күрә алабыз. Һәм ул безгә авазның озынлыгын билгеләргә ярдәм итә. Шулай итеп, сүз башында басымсыз позициядә килгән *[а]* фонемасының (***а****вылдá)* озынлыгы – 0.0240 с., ә сүз башында басымлы позициядә (***а́л***) килгән очракта сузык озынлыгы – 0.1434 с. тәшкил итә. Күргәнебезчә көчле позициядә килгән очракта *[а]* авазы озынрак әйтелә.

***а****вылдá* ***а́****л*



*2 нче рәсем*

2 рәсемдә авазның тирбәнеш ешлыгын билгели алабыз. ***А****вылдá* сүзендә *[а]* фонемасының ешлыгы иң югары ноктасы 119.9 герцтан башланып 118 герц белән тәмамлана. ***А́****л* сүзендәге вариантта тирбәнеш ешлыгының дулкынсыман үзгәреше күренә: аваз 165 герцтан башланып, 178 герцка кадәр күтәрелә һәм яңадан 165 герцка төшеп тәмамлана. 2 нче вариантта ешлык беренчесенә караганда үзгәрүчән икәнен билгели алабыз. Әлеге рәсемдә ешлык нокталар ярдәмендә күрсәтелгән вариант та бар һәм аның ярдәмендә авазны әйткән вакытта ешлыкның үзгәрү процессын төгәлерәк күрә алабыз: ***а́****л* сүзендә аваз башлангыч процесста бер төшкән, бер күтәрелгән һәм бу үзгәрешләр сызыклы графикта күренми. Шулай итеп *[а]* авазының ешлыгы көчле позициядә булган вакытта зур һәм кечкенә амплитудалы дулкынсыман үзгәрешләргә дучар була.

*авылдá* *áл*



*3 нче рәсем*

4 нче рәсем авазларның интенсивлыгын (көчен) күрсәтүче график. *Авылдá* сүзендәге *[а]* авазының көче -29,6 дб (7%) башлана, ахырга таба -13,5 дб (20%) күтәрелеп ала һәм -13,6 дб (23,8%) белән тәмамлана. Фонема ахырга таба көчәя бара. ***Á****л* сүзендә сузыкның интенсивлыгы -14 дб (24%) башланып иң югары өлешендә -6,3 дб (48%) җитә, анна соң экренләп көче -8 дб (38%) төшә һәм ахырда 8,3 дб (37,7%) белән тәмамлана. Фонеманың көче актык миллисекундта күтәреләә башлау, аннан соң килгән сонор [л] сузык авазына бәйле булырга тиеш. Графикта күренгәнчә әлеге тартыкка ялганып китү өчен сузык аваз аңа җайлаша. Бирелгән саннардан күренгәнчә, *[а]* авазының көчле позициядә торган варианты интенсивррак әйтелә.

Чагыштырып карар өчен килеп чыккан күрсәткечләр таблицага салынды:

*1 нче таблица*

| | *Озынлык* | *Ешлык* | *Интенсивлык* | *Фраза басымы* |
|---|---|---|---|---|
| ***á****л* | 0.1434 с. | 165 Гц – башында<br>178 Гц – иң биеге<br>165 Гц - азагында | 14 дб – башында<br>6.3 дб – иң биеге<br>8 дб – иң түбәне<br>8.3 дб – азагында | + |
| ***авылдá*** | 0.0240 с. | 119.9 Гц – башында<br>118 Гц – азагында | 29,6 дб – башында<br>13.5 дб – иң биеге<br>13.6 дб – азагында | + |

Үткәрелгән тикшерүдән чыгып алдагы нәтиҗәләрне билгеләргә мөмкин: сүз башында көчле позициядә килгән вакытта *[а]* авазының озынлыгы басым-

сыз вариантка караганда алты тапкырга озынрак; ешлык һәм интенсивлык ягыннан караганда басымлы вариат зуррак күрсәткечләргә ия. Шулай итеп, басымның аваз күрсәткечләренә зур йогынтыга ия икәне билгеләнә.

**ӘДӘБИЯТ**


1. Дою мулла. https://power.gybka.com/song/180607099/Tatar_halyk_kiyatl_re_-_Diyu_mulla/
2. Зәкиев М.З. Татар грамматикасы / М.З. Зәкиев. – Казан: ТӘһСИ, 2015. – Т.1. – 512 б.
3. Speech Analyzer. https://software.sil.org/speech-analyzer/



**Г.Ф. ГАЛИЕВА**

*Казанский федеральный университет, Россия*


## ОСОБЕННОСТИ ПРЕПОДАВАНИЯ ТУРЕЦКОГО ЯЗЫКА В ТАТАРСКОЙ АУДИТОРИИ


**Аннотация.** В статье представлены близкородственные языки – татарский и турецкий. В данной работе рассмотрен сравнительно-сопоставительный метод татарского и турецкого языка. С помощью данного метода выявлены сходства и различия морфологической и лексической системы указанных языков.



**Ключевые слова:** сопоставительный метод, сходства и расхождения между татарским и турецким языками, морфологическая система татарского и турецкого языка.



**Abstract.** The article presents closely related languages – Tatar and Turkish. In this paper, the comparative method of the Tatar and Turkish languages is considered. With the help of this method, the similarities and differences of the morphological and lexical systems of these languages are revealed.



**Keywords:** comparative method, similarities and discrepancies between Tatar and Turkish languages, morphological system of the Tatar and Turkish languages.


Во время обучения иностранному языку, можно провести некоторые параллели с родным языком. В таком случае, процесс преподавания будет доставлять меньше трудностей. Частенько получается так, что в родном языке не бывает аналогов или же используется по-другому. Во время преподавания турецкий и татарский язык вступают в тесный контакт. Турецкий и татарский языки входят в одну и ту же языковую подгруппу. Из этого следует, что они являются близкородственными языками. Однако, чтобы передать мысль на иностранном языке, недостаточно просто иметь словарный запас, а нужно владеть хотя бы простейшими представлениями о строении предложений и уметь свободно конструировать их.

Метод сопоставления позволяет обнаружить сходства и различия между исследуемыми языками. Языки также сходны и в использовании. В данном докладе будет затронуты некоторые различия способов выражения логической построении мысли и расхождения лексической и морфологической систем.

I. Различия в построении выражений турецкого и татарского языков.

А) В турецком языке, союз **ki** соединяет две части сложного предложения, при этом главное предложение предшествует придаточному, тогда как в татарском языке нет аналога: *Seni seviyorum ki bunca cefaya katlandım. – Мин сине шул кадәр нык яратам, хәтта барлык авырлыкларны кичердем. «Я люблю тебя так, что пережил все эти страдания».* [1, с. 99]

Б) В турецком языке очень часто употребляется простое предложение, которое распространяется за счет группы подлежащего. Например: *İstanbul şehrinde okuyan Fetih Kerimi Rusça Arapça Türkçe ve Fransızca öğrenen eğitimli entelektüel. – «Получивший образование в Стамбуле Фатих Карими, был образованным интеллигентом знавший русский, арабский, турецкий и французские языки».* На татарском языке из сложного предложения может получится два простых предложений: *Фатих Кәрими Төркиянең Истанбул шәһәрендә белем ала. Ул рус, гарәп, фарсы, төрек, француз телләрен белүче укымышлы зыялы була.* [1, с. 100]

II. При рассмотрении морфологических систем татарского и турецкого языков можно увидеть расхождения в структуре морфологической системы, также как и в функционировании форм. [1, с. 100]

1) **-yor** в турецком языке является конструкцией глагола настоящего времени, а в татарском языке эта форма отсутствует. Однако в татарском языке **а/-ә, -ый/-и** приходится формой настоящего времени, напоминающая форму желательного наклонения в турецком языке. Например, в татарском языке *яза* на русский переводится как «пишет»; а с турецкого *yaza* на русский – «напишет», что также похоже по созвучию с татарского. [1, с. 100]

Форма на (**-a, -e, -ı, -i, -u, -ü,) -r** выражающая в турецком языке настоящее-будущее время (Geniş Zaman). Эта форма часто употребляется в турецких пословицах *Sağır işitmez uydurur* [2, с. 284] «Глухой не слышит, а выдумывает», *Dilsizin dilinden anası anlar.* [2, с. 10] – «Мать поймёт даже своего немого ребёнка». В родном татарском языке эта форма указывает на неопределенное будущее время. [1, с. 100]

2) В турецком языке между глаголами в личной форме имеется долженствовательное наклонение с конструкцией -malı/-meli, которое отсутствует в татарском языке. Например: çalışmalıyım «я должен работать» в татарском языке

передается при помощи конструкций -рга кирәк или -рга тиеш: миңа эшләргә кирәк/мин эшләргә тиеш. [1, с. 100]

3) А также есть такие различия в моделях образования безличных глаголов:

В турецком языке инфинитив имеет форму на -mak/-mek (gülmek, yapmak) в татарском языке на: -рга/-ргә (көләргә, эшләргә);

языке название действия представлено конструкцией -у/-ү: чыгу, тегү и т. д. [1, с. 100].

2. В родственных языках лексическая система распределяется по лексико-семантическим и лексико-тематическим группам. Отметим самых распространенных слов, образующих смысловую основу языка:

gitmek "китү" (уйти), bakmak "карау" (смотреть), düşünmek "уйлау" (думать), göstermek "күрсәтү" (показать), konuşmak "сөйләшү" (разговаривать), sevmek "ярату" (любить), yatmak "яту" (ложиться), gülmek "көлү" (смеяться), oturmak "утыру" (сидеть), gelmek "килү" (приходить). [1, с. 102]

Представленные 10 глаголов, являются тюркскими, полное смысловое сходство этих языков образует 40%; отличается и смысловое построение многих совпадающих слов. (Например: тат. төшенү «убедиться» и тур. düşünmek «уйлау». [1, с. 102]

Однако при этом нельзя упускать из виду, что внешнее сходство этих связей может скрывать за собой семантические расхождения. Выявлением этих расхождений занимается сопоставительное изучение родственных языков. Определение и систематизация семантических, фонетических и других расхождений облегчает преподавание турецкого языка как иностранного языка в учебных заведениях Республики Татарстан.

Таким образом, турецкий и татарский языки являются тюркскими языками, но входящие в разные подгруппы, которые имеют много общих черт и связи. Выявление данных связей для сравнительного изучения языков данной группы имеет огромный смысл. Однако нужно иметь в виду, что они могут быть внешне похожими, но иметь разные значения. И определением этих несоответствий, как раз таки занимается сравнительно-сопоставительное изучение родственных языков.

**ЛИТЕРАТУРА**

1. Рахимова А.Р. Родственные языки и их сравнительно-сопоставительное изучение (на материале турецкого и татарского языков) / А.Р. Рахимова. – К.: Гум. науки, 2007. – Том 149, кн. 4. – 103 с.

2. Aksoy Ö.A. Atasözleri ve deyimler sözlüğü Bağcılar / Ö.A. Aksoy. – İstanbul Maatbacılar Sit. – No.: 38. – 328 s.

**И.И. ГАЛИМБИКОВА**
*Казанский федеральный университет, Россия*

# «ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН» ГАЗЕТАСЫНДАГЫ ӨСТӘЛМӘЛӘРНЕҢ СТРУКТУР ХАРАКТЕРИСТИКАСЫ

**Аннотация**. Экспрессивность текстов в последние годы возрастает все больше и больше. Вставные конструкции очень часто используются журналистами при написании статей. Они используются для установления «близости» с читателем, для выражения своей мысли и для достижения доступного языка для читателей. В данной работе рассматривается история изучения экспрессивных конструкций, структурные и функциональные особенности вставных конструкций в текстах современной татарской печати. Целью данной научной работы является анализ экспрессивных конструкций газеты «Ватаным Татарстан», а также в ходе исследования определение особенностей вставных конструкций.

**Ключевые слова:** экспрессивные конструкции, вставные конструкции, язык СМИ, структурные особенности вставных конструкций, функциональные особенности вставных конструкций.

**Abstract**. The expressiveness of texts has been increasing more and more in recent years. Plug-in constructions are very often used by journalists when writing articles. They are used to establish "intimacy" with the reader, to express their thoughts and to achieve an accessible language for readers. This paper examines the history of the study of expressive constructions, structural and functional features of inset constructions in the texts of the modern Tatar press. The purpose of this scientific work is to analyze the expressive constructions of the newspaper "Vatanym Tatarstan", as well as in the course of the study to determine the features of insert structures.

**Keywords:** expressive constructions, plug-in designs, media language, structural features of plug-in structures, functional features of plug-in structures

Эмоциональ-экспрессив функция кешенең тел ярдәмендә үз хисләрен, тойгыларын, кичерешләрен тапшыру сәләтендә чагыла. Әлеге функция сөйләүченең шәхесен, аның кәефен интонация, сүз сайлау һәм семантик-синтаксик структуралар ярдәмендә чагылдырырга ярдәм итә. Бу функция адресантның сөйләм предметына карата субъектив психологик мөнәсәбәтен (интонация, ымлыклар, эмоциональ-экспрессив коннотация һ.б.) турыдан-туры белдергәндә гамәлгә ашырыла.

Өстәлмә конструкцияләр җөмләләрне тулыландырып, төгәлләштереп, фикерне тагын да ачыграк итеп әйтү өчен җөмләгә килеп өстәләләр.

Тикшеренүләр күрсәткәнчә, өстәлмә конструкцияләр XVIII гасыр текстларында барлыкка килә, һәм алга таба төрле стиль текстларда арта.

Хәзерге матбугатта өстәлмә конструкцияләр шактый киң кулланыла һәм алар структур-синтаксик, функциональ үзенчәлекләргә ия.

Ф.С. Сафиуллина «Татар телендә сүз тәртибе» дигән хезмәтендә өстәлмә конструкцияләрнең мәгънә ягыннан 9 төрен аерып күрсәтә: беренче җөмләдәге яисә үткәндә өзелеп калган фикер дәвам иттерелгән очрак; әйтелгән фикернең билгесен ачыклау нияте белән өстәлгән конструкцияләр; өстәлмә конструкция алда әйтелгән фикерне дөресләп килә, бер төрле аңлашырга мөмкин булган фикерне дөресли; өстәлмә конструкция икенче телдәге сүзләр белән алдагы берәр фикерне ачыклап килә; өстәлмә конструкция алдагы җөмләдәге бер кисәкнең эчтәлеген ачып бирә; өстәлмә конструкциядәге сүзләр тагын да ныграк ышандыру өчен кулланылалар; өстәлмә конструкцияләрдә элек «истән чыгып киткән» вакыт, урын, максат, рәвеш, шарт, сәбәп, объект һ.б. төшенчәләре чагыла; өстәлмә конструкциядә алдагы җөмләдә телгә алынган берәр затның фамилиясе, исеме, профессиясе белдерелә; өстәлмә конструкциядә өстәмә хәбәр килеп алдагы хәбәрне тагын да конкретлаштыра торган төрләре.

Өстәлмә конструкцияләрне, вакытлы матбугатка таянып, тикшергән хезмәтләрдә аларның ике төре аерыла: вербаль булмаган һәм вербаль. Алар үз эчендә берничә тармакка аерылалар.

Вербаль булмаган конструкцияләр: тыныш билгеләре ярдәмендә һәм саннар ярдәмендә белдерелгән төрләре аерылып чыгарыла.

*Чир йоктыручылар арасында күбесе – 30–50 һәм 60–70 яшь аралыгындагы кешеләр (22шәр)* (Ватаным Татарстан, 2021, №15).

Вербаль конструкцияләр – тел чаралары ярдәмендә белдерелгән, бер сүздән алып, тулы җөмлә ярдәмендә кулланылган төзелмәләр. Алар: лексик типтагы өстәлмә конструкцияләр һәм синтаксик типтагы өстәлмә конструкцияләр.

Лексик типтагы өстәлмә конструкцияләр түбәндәгеләргә аерыла:

– өстәлмә сүз (аерым лексема)

*Сәнҗапов Рәшит Шәйхулла улы (фермер) хуҗалыгы башлыгы Сәнҗапов Рәшит Шәйхулла улына...* (Ватаным Татарстан, 2021, №16).

*Алар арасында менә кемнәр бар: Владислав Пельш (телевидениедә алып баручы), Алексей Маклаков (актер)...*(Ватаным Татарстан, 2021, №16).

*Бәлкем хәзер алай түгелдер, яшьләр баштан ук талант булып киләдер (көлә )* (Ватаным Татарстан, 2021, №16).

– аббревиатура

*Бөтендөнья сәламәтлек саклау оешмасы (ВОЗ) белгечләре нәтиҗәлелеге 70 проценттан арткан теләсә кайсы вакцинаны уңышлы дип санаячакларын белдергән иде* (Ватаным Татарстан, 2021, №16).

*Бу айлык акчалата түләү (ЕДВ) алучыларга кагыла* (Ватаным Татарстан, 2021, №14).

Синтаксик типтагы өстәлмә конструкцияләр шулай ук 2 төргә аерыла: җөмлә алдыннан куела торган һәм җөмлә ахырыннан килә торган.

Әлеге беренче төр конструкцияләр: сүз формасы һәм сүзтезмәләрне үз эченә ала.

*AZD1222 (Оксфорд вакцинасы)*(Ватаным Татарстан, 2021, №16).

*BNT162b2 (Pfizer-BioNTech вакцинасы)*(Ватаным Татарстан, 2021, №16). ярдәмендә белдерелә алалар.

Ситаксик типтагы икенче төр конструкцияләр үз эченә:

- гади җөмлә ярдәмендә белдерелгән

*Аның зурлыгы 0,02-20,0% аралыгында үлчәнә һәм переферияләге (мәсәлән, аяк, кул чукларындагы) кан йөрешенең көченә, тамырларының кан белән тулышканлыгына, эшкә яраклы капилярларның санына бәйле* (Ватаным Татарстан, 2021, №16).

*Аерым биттә хәзерге вакытта эчә торган яки бераз алданрак эчкән барлык даруларыгыз (витаминнар, БАДлар да), дозалары да күренеп торсын* (Ватаным Татарстан, 2021, №16).

*Артем (ире, Тинчурин театры артисты. – Ред.) бу уңайдан атлыгып тора*) (Ватаным Татарстан, 2021, №16).

*Танылган тележурналист Михаил Любимовның (ТНВ каналындагы «7 дней» тапшыруы аша билгеле. – Ред.) шушы көннәрдә «кызыл зона»га 17 нче тапкыр керүе* (Ватаным Татарстан, 2021, №16).

*Бу – инвалид балаларга дарулар, медицина кирәк-ярагы, сихәтле ризыклар (акчалата бирелгәндә – аена 933,25 сум)...* (Ватаным Татарстан, 2021, №14).

- катлаулы җөмләнең бер өлеше ярдәмендә белдерелгән

*Бу нурлар гемоглобинны үтәли яктырта (ә гемоглобин – кислородны күзәнәкләргә ташый торган аксым ул)* (Ватаным Татарстан, 2021, №16).

*1 стакан кибет катыгы (стаканлы булса, тагын да әйбәтрәк)...* (Ватаным Татарстан, 2021, №16).

*Дөрес, үзе уйлап тапкан ысул түгел, ә инде бөтен дөньяга таралган «флай леди» (бал кортыдай хатын-кыз, «оча торган хатын-кыз» дип тә тәрҗемә ителә) ысулы икән бу* (Ватаным Татарстан, 2021, №16).

*Күпләр әле дөньяда иң беренче булып теркәлгән вакцинаны (Мәскәүнең Гамалея исемендәге фәнни үзәгендә җитештерелгән «Спутник V») гына беләдер* (Ватаным Татарстан, 2021, №16).

*Бүгенгә 3 меңнән артыграк трактор, (шул исәптән чит илдә җитештерелгән 300 трактор) ремонтланмаган әле* (Ватаным Татарстан, 2021, №14).

- катлаулы җөмләр ярдәмендә белдерелгән төрләргә аерылалар.

*Муса Җәлил истәлегенә газетабыз гамәлгә куйган ярышларда (шулай ук республика күләмендәге башка бәйгеләрдә дә – балалар, яшьүсмерләр, өлкәннәр арасында үткән һәр бәйгедә бит ул!) чемпион калучыларның абсолют күпчелеге безнекеләр була иде* (Ватаным Татарстан, 2021, №14).

Хәзерге матбугат теле күпкә экспрессив. Медиа-текстларның төп стратегияләренең берсе адресатка якынлык стратегиясе булып тора. Бу журналистның «җәмгыять белән бер телдә сөйләшергә» омтылуында тормышка ашырыла.

Анализ барышында бер мәкаләдә бердән алып берничә өстәлмә конструкция кулланыла алуын ачыкладык. Алар арасында тыныш билгеләре кулланылган өстәлмәләр очрамады. Саннар ярдәмендә белдерелгән өсәлмәләр 6,6% тәшкил итә. Өстәлмә сүзләр 16,6%, аббравиатуралар 6,6%. Сүз формалары очрамый, сүзтезмәләр 11,6%. Иң күп кулланылган конструкцияләр булып – гади җөмләләр ярдәмендә белдерелгән өстәлмәләрне аерып атап була, алар 35% алып торалар. Катлаулы җөмләнең бер өлеше ярдәмендә белдерелгән өстәлмәләр 11% алып торса, катлаулы җөмләләр ярдәмендә белдерелгән төре бары тик 5%.

**ӘДӘБИЯТ**

1. Кормилицына М.А. Экспрессивные синтаксические конструкции в современной прессе / М.А. Кормилицына // Проблемы речевой коммуникации: межвуз. Сб. науч. тр. / под ред М.А. Кормилицыной, О.Б. Сиротининой. – Саратов: Изд-во Сарат. ун-та, 2009. – С. 55–61.

2. Сафиуллина Ф.С. Развитие синтаксического строятатарского литературного языка (XX век): дисс. в виде науч. Докл... д-ра филол. Наук. / Ф.С. Сафиуллина. – К.: Изд-ва КГУ, 2000. – 116 с.

3. Экспрессивные конструкции в современных СМИ // URL: https://studwood.ru/985759/literatura/ekspressivnye_konstruktsii_sovremennyh_tekstah (дата обращения: 18.02.2021)

**Л.А. ГАЛЯУТДИНОВА**
*Казан федераль университеты, Россия*

# СПОРТ МӘКАЛӘЛӘРЕНӘ ИСЕМ БИРҮ ҮЗЕНЧӘЛЕГЕ

**Аннотация.** В статье расмотрена связь спортивного газетного заголовка с текстом и заголовок как отдельный жанр публицистического стиля.

**Ключевые слова:** спорт, спортивная журналистика, спортивные статьи, заголовок, газета, журнал.

**Abstract.** The article examines the connection between the sports headline and the text and the headline as a separate genre of journalistic style.

**Keywords:** sports, sports journalism, sports articles, headline, newspaper, magazine.

Мәкаләләрнең баш исеме – журналист текстының мөһим элементы. Фәнни әдәбиятта "баш исем", "мәкалә атамасы" билгеләмәләре төрлечә аңлатыла. Күп еллар дәвамында лингвист-галимнәр газета баш исеменә дөрес билгеләмә бирергә омтылалар.

Формалары буенча баш мәкаләләр ике төргә бүленә:

1) Номинатив мәкалә атамалары. Алар тулы булмаган җөмләләрдән тора. Еш кына ике исем яисә, исем белән сыйфаттан торалар. Спорт тематикасына караган мәкаләләрдә шундый баш исемнәре очрый. Мәсәлән: "Шахмат короле" (Гәрәев М. // Идел. – 2020. – №2. – Б. 18–19) мәкаләсендә сүз Рәшит Нәҗметдинов турында бара (Гәрәев М. Шахмат короле // Идел. – 2020. – №2. – Б. 18).

"Нәфис гимнастикада – татар йолдызчыклары" (Галимҗанова Р. // Гаилә һәм мәктәп. – 2020. – №3. – Б. 31–33) мәкаләсендә сүз Ильвина Абдуллина, Аделина Гарипова турында бара.

"Иман" батырлары" (Идел. – 2019. – №2. – Б. 12-13) мәкаләсендә сүз Актаныштагы Балалар һәм яшүсмерләр спорт мәктәбе турында сөйләнелә: ("Иман" батырлары // Идел. – 2019. – №2. – Б. 12).

2) Предикатлы баш исемнәр, ягъни тулы җөмләләрдән торган мәкалә атамалары.

Мәсәлән: "Иң мөһиме – уздыру" (Локманова Л. // Шәһри Казан. – 2021. – 11 август.) мәкаләсендә БДБ илләре ярышлары сөйләнелә ("Шәһри Казан").

"Махсус Олимпиада кичектерелә" (Ватаным Татарстан. – 2021. – 4 сентябрь.); Әлеге мәкаләдә Казанда инвалидлар арасында Бөтендөнья кышкы Махсус Олимпиада уеннарының, пандемия аркасында, 2023 елның гыйнварына күчерелүе языла.

Без өченче төр итеп туры сөйләмне кертер идек. Баш исемнәрдә туры сөйләм бик еш очрый. Мәсәлән: “Эльмира Галләмова: “Чын ир-ат икәнлеген аңладым” (Хәбибрахманова Г. // Гаилә һәм мәктәп. – 2020. – №12. – Б. 2–4.). Мәкаләдә сүз танылган көрәшче Муса Галләмовның гаиләсе турында сүз бара, шунлыктан баш исемдә аның хатынының туры сөйләмен куллану урынлы дип саныйбыз.

“Кара билбау иясе Василя Газизова: “Машина белән капландым да икенче көнне үк башыма яулык бәйләдем” (“Ватаным Татарстан”). Газетада журналист Гөлсинә Яруллинаның Василя Газизова белән интервьюсы тәкъдим ителә.

Н.Э. Шишкин, баш исемнәрнең катлаулылыгыннан чыгып, түбәндәге төрләрны аерып чыгара:

– “гади” баш исем. Ул тәмамланган фикерле бер җөмләдән тора. Ул сорау да, хикәя җөмлә дә булырга мөмкин. Мәсәлән: “Татарстан көрәшчеләре Екатеринбургта узган ярышта ике алтын медаль яулады” (Ватаным Татарстан. – 2019. – 11 сентябрь); “Тизлек, җитезлек, төгәллек” (Нигъмәтҗанова Р. // Гаилә һәм мәктәп. – 2021. – №3. – Б. 33–35.); “Татарстан спортчылары тхэквондо буенча Европа чемпионатына бару хокукын яулады” (Мәйдан. – 2019. – №3. – Б. 45) һ.б.

– “катлауландырылган” баш исем. Әлеге баш исемнәр “гади”ләрдән берничә мөстәкыйль, логик яктан төгәлләнгән кисәкләрдән торуы белән аерыла. Мәсәлән: “Ак Барс” клубы Эмиль Гарипов белән контрактны өзде. Хоккейчының яңа эш урыны билгеле” (Шәһри Казан. – 2019. – 1 декабрь); “Җиңү түгел, катнашу мөһим. Мөмкинлеге чикле булганнарга спортта урын җитәме?” (Сафина Л. // Ватаным Татарстан. – 2021. – 27 май) һ.б.

– “комплекслы” баш исем. Әлеге баш исемнәргә төп һәм өстәмә баш исемнәр керә. Димәк мәкалә берничә кисәккә бүленә. Мәсәлән: “Нәфис гимнастикада – татар йолдызчыклар” мәкаләсе ике кисәктән тора: “Сыгылмалык беренче урында” һәм “Камиллек – тырышлык нәтиҗәсе”. (Галимҗанова Р. // Гаилә һәм мәктәп. – 2020. – №3. – Б. 31–33.).

“Шахмат короле” (Гәрәев М. // Идел. – 2020. – №2. – Б. 18–19.) мәкаләсе өч кисәккә бүленгән. Кисәкләрнең исемнәре: “Бик тырышсам, откан булыр идем...”, “Миннән сәлам әйтерсез”, “Яшерен тренер”. Һәр бүлектә аерым вакыйга каралса да, мәкалә Рәшит Нәҗметдинов турында язылган.

Мәкаләләрнең баш исемнәре еш кына күренеп торырлык итеп билгеләнә. Мәсәлән, график (орфографик). Мәкалә атамаларын зур, кара шрифт белән язу укучыларны җәлеп итү өчен эшләнә. Шулай ук төрле атаклы фамилияләрне куллану да очрый. Мәсәлән: “Ак Барс” капитаны Данис Зарипов карьерасын

тәмамлавы турында хәбәр итте (Шәһри Казан. – 2021. – 26 август); “Эмиль Гариповның яңа эш урыны билгеле” (Шәһри Казан. – 2019. – 1 декабрь) һ.б.

М. Гуревич фикеренчә, “укучыны үзенең эчтәлеге һәм формасы белән җәлеп иткән ачык итеп язылу икенче текстны укырга яки аның астында торган иллюстрацияне карарга этәрә. Ул кармак ролен уйный, аны йотып, укучы үзенең “табышы” – мәкалә белән тулысынча таныша” [Гуревич, 2002: 46].

Еш кына баш исемнәрдә риторик сораулар яки өндәүләр кулланыла. Әлеге төр баш исем атамалары спорт темасына язылган мәкаләләрдә дә урын ала. Мәсәлән: “Данис Зарипов спорттан китәчәкме?” (Ватаным Татарстан. – 2021. – 21 апрель) мәкаләсендә Данис Зариповның “Ак барс” белән килешүе 30 апрельдә төгәлләнү, Казан клубыннан яңа тәкъдим булыр дип өметләнүе хәбәр ителә.

Еш кына риторик сорау / өндәү җөмләләр аерым гына бирелми: баш исемнәр ике җөмләдән дә тора. Мәсәлән: “Атлар бар. Ир-егетләр кайда?” (Диндаров И. // Шәһри Казан. – 2021. – 14 сентябрь).

“Җиңелү һәм мәхәббәт. Без типкән туп ник керми?” (Хөснуллин И. // Ватаным Татарстан. – 2021. – 22 июнь) язмасы Россия җыелма командасы Европа чемпионатыннан төшеп калуы турында сөйли.

“Җиңү түгел, катнашу мөһим. Мөмкинлеге чикле булганнарга спортта урын җитәме?” (Сафина Л. // Ватаным Татарстан. – 2021. – 27 май) мәкаләсенең эчтәлеге исеменнән үк тора.

Күзәтүләр күрсәткәнчә, татар газета-журналларындагы мәкаләләрдә атау функциясе башкаручы исемнәр аеруча еш эшкә җигелә. Бу очракта баш исеменә бөтен текстның кыскача эчтәлеге чыга [Гарифуллин, 2007: 19].

Мисаллар китерик: Данис Зарипов: “Әле уйнап туймадым” (Ватаным Татарстан. – 2021. – 20 апрель.”); “Самара егете командага алтын медаль китерде” (Идел. – 2021. – №1. – Б. 34.) һ.б.

Хәзерге публицистикада актив рәвештә мәкаль һәм әйтемнәр кулланыла. Н.О. Григорьева уйлавынча, “мәкаль һәм әйтемнәр ярдәмендә әйтелгән фикер, җиңел кабул ителә, яңара, тәмамлана...” [Григорьев, 2008: 126].

Мәкаләнең баш исемендә трансформацияләнгән мәкальләрне куллануның берничә сәбәбе бар. Беренчедән, укучының игътибарын җәлеп итәр өчен, чөнки баш исемдә таныш фраза булу – укучыга тәэсир итмичә калмый. Икенчедән, текст мәгънәсен ачуда ярдәм итә. Өченчедән, мондый баш исемнәр туры әйтүдән качарга ярдәм итәләр. Мәсәлән: “Спортчы уңышларына юл ашказаны аша салына” (Шәһри Казан. – 2019. – 27 октябрь). Әлеге мәкаләдә сүз спортчыларның туклануы турында бара, бүгенге медицина кагыйдәләре турында сөйләнелә. Легендар хоккейчы Вячеслав Фетисов, танылган теннисчы Марат

Сафин, “Рубин” футболчысы Кристиан Нобоаның нәрсә белән туклануы әйтелә.

Баш исемгә килгәндә ул “Мәхәббәткә юл ашказаны аша салына” рус әйтеменнән үзгәртелеп, ягъни трансформацияләнгән.

“Җырланмаган әле сезнең җыр” (Хөснуллин И. // Ватаным Татарстан. – 2021. – 23 март) “Җырланмаган әле безнең җыр” әйтеменнән трансформацияләнгән. Биредә сүз күчерелмә мәгънәне дә, туры мәгънәне дә аңлата.

“Чир китәр, спорт калыр” (Хөснуллин И. // Ватаным Татарстан. – 2020. – 04 август) баш исемле мәкаләдә Татарстанда спорт мәктәпләренең эшләве турында хәбәр ителә.

Кайчак мәкаләләрнең баш исеме гомуми (интегратив) теманы белдереп килә. Мәсәлән, “Казанны үзгәрткән 5 вакыйга” (Хөснуллин И. // Ватаным Татарстан. – 2020. – 28 май) баш исеме белән бирелгән мәкаләдә сүз спорт турында барганы аңлашылмый. Әмма биредә Казанда үткән Универсиада, Спортның судагы төрләре буенча дөнья чемпионаты, Футбол буенча дөнья чемпионаты турында сүз бара.

Атау функциясе үтәүче баш исемнәренең нинди төре кулланугa карамастан, калыплашан төзелешле текстларда, кагыйдә буларак, тема тулаем беренче җөмләдә хәбәр ителә һәм аннан соңгыларында тәгаенләнә [Гарифуллин, 2007: 20]. Мәсәлән: “Ак барс” Казандагы уенын Зиннәтулла Билалетдинов белән башлый” (Хөснуллин И. // Ватаным Татарстан. – 2019. – 13 сентябрь) мәкаләсенең беренче җөмләсе: “Металлург”ка каршы узасы очрашу алдыннан “Татнефть-Арена”да өч мәртәбә Гагарин Кубогын яулаган остазны хөрмәтләячәкләр. Соңгы җөмлә: “Металлург” исә ике көн элек Түбән Камада “Нефтехимик”ка 0:3 исәбе белән оттырды”.

Күргәнебезчә, татар матбугатындагы спорт тематикасы турындагы мәкаләләрнең баш исемнәре арасында төрле типтагылары очрый. Шулай итеп, барлык мәкалә атамасының да төп бурычы – үзеннән соң килгән текстның эчтәлеген кыска формада ачып бирү һәм шуның белән укучының игътибарын җәлеп итү.

## ӘДӘБИЯТ

1. Гарифуллин В.З. Вакытлы матбугатта жанрлар / Югары уку йортларының журналистика бүлеге студентлары өчен “Журналистның иҗади эшчәнлеге нигезләре” курсыннан уку ярдәмлеге. Икенче басма // В.З. Гарифуллин. – Казан: Казан ун-ты нәшр., 2007. – 120 б.

2. Григорьева Н.О. Публицистический стиль в системе функциональных разновидностей языка // Язык средств массовой информации: учеб. пособие / Н.О. Григорьева. – М., Альма Матер, 2008. – 356 с.

**Л.А. ГӘРАПШИНА, И.И. САДРИЕВА**
*Казан шәһәре Совет районының 171 нче мәктәбе, Россия*
*Казан шәһәре Совет районының 167 нче мәктәбе, Россия*

# ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ ДӘРЕСЕНДӘ ПРЕДМЕТАРА БӘЙЛӘНЕШЛӘРНЕ ИСӘПКӘ АЛЫП УКЫТУ

**Аннотация**. В данной работе рассмотрены вопросы интегрированного обучения на уроках родной (татарской) литературы. Главной целью уроков литературы является воспитывать всесторонне развитого человека, активизировать мыслительную деятельность учащихся, пробуждение доброго чувства к художественному слову. Школьный курс литературы имеет внутрипредметную и межпредметную интеграции. Межпредметная интеграция на уроках литературы достаточно вариативна: литература и русский язык; литература и история; литература и мировая художественная культура; литература и искусство (музыка и изобразительное искусство).

**Ключевые слова:** интегрированное образование, межпредметная интеграция, художественный текст, вариативность, анализ, эстетическое воспитание.

**Abstract**. In this paper, the issues of integrated learning in the lessons of native (Tatar) literature are considered. The main purpose of literature lessons is to educate a comprehensively developed person, to activate the mental activity of students, to awaken a good feeling for the artistic word. The school literature course has intrasubject and intersubject integration. Interdisciplinary integration in literature lessons is quite variable: literature and the Russian language; literature and history; literature and world art culture; literature and art (music and fine arts).

**Keywords:** integrated education, interdisciplinary integration, variability, artistic text, analysis, aesthetic education.

Һәрьяклы үсеш алган шәхес тәрбияләүдә әдәбият дәресләре зур роль уйный. Укучы әдәби әсәрләр, аларның авторлары фикере аша гомумкешелек кыйммәтләрен үзләштерә,халыкларның буыннардан-буыннарга күчеп килгән рухи байлыгы белән таныша,тормышның катлаулы фәлсәфәсен аңларга өйрәнә. Мәктәптә әдәбият укытуның төп максат һәм бурычлары укучыларны сүз сәнгатен аңларга өйрәтүне, татар әдәбияты һәм тәрҗемә әсәрләр аша рус һәм дөнья әдәбияты әсәрләренең байлыгы белән таныштыруны; халык тарихын һәм мирасын өйрәнү аша укучыларда Ватанга, халыкка, туган җиргә, кешеләргә ихтирам, мәрхәмәтлелек, тәрбияләүне; эстетик тәрбия бирү, табигатькә сакчыл караш булдыруны күз алдында тота. Эшебезнең төп максаты булып метапредмет компетенцияләр формалаштыруда әдәбият дәресендә предметара бәйләнешләр куллану нәтиҗәлеген нигезләү.

Бурычлар:

– интеграль дәрес үткәрү методикасын,үзенчәлекләрен фәнни-методик әдәбият укып өйрәнү;

– татар әдәбияты дәресләрендә предметара бәйләнешләр кулланып укытуны эш тәҗрибәсе аша күрсәтү.

Интеграль дәресләрне оештырганда, түбәндәге формаларны куллану нәтиҗәле: лекция, әңгәмә, конференция, семинар һ.б. Күбесенчә конференция, семинар дәресләр еш үткәрелә. Фәнни популяр әдәбият белән эшләү, таблиацалар, схемалар төзү – укучыларда анализлау, гомумиләштерү, системалаштыру сәләтен үстерә. Дәрес барышында укучылар яңа материалны үзләренең белемнәре белән чагыштыралар, шуңа күрә мондый укыту нәтиҗәле була. Интеграль дәресләрнең уңышлылыгы әзерлек этабының сыйфатына бәйле. Дәрес материалын ныклап тикшереп карап алырга кирәк. Дәресләрне нәтиҗәле үткәрү өчен, өйрәнү объектын һәм кирәкле материалны дөрес сайлау; дәреснең барлык этапларында да укучыларның фикерләү эшчәнлеген активлаштыра торган проблемалы укыту методларын куллану таләп ителә. Төрле фән укытучыларының иҗади дуслыгы укучыларның фәннәрне үзләштерүенә уңай йогынты ясый, чөнки бер предметны өйрәнгәндә кулланыла торган метод – алымнар интегральләштерү нәтиҗәсендә икенче предметны укыту методикасына да күчә, уңышлы кулланыла башлый.

Мәктәптә өйрәнелә торган шактый гына әсәргә рәссамнар тарафыннан иллюстрацияләр эшләнгән яки әсәрнең эчтәлегенә туры килгән картина-репродукцияләре бирелгән. Әдәби әсәрләрне анализлаганда иллюстрацияләр,картина-репродукцияләрен куллану дәрестә өйрәнелүче уку материалына укучыларның игътибарын тупларга, әсәрдә барган вакыйгаларны күз алдына китерергә ярдәм итә. Укучы картинага карап укытучы сөйләгәннәрне җиңелрәк үзләштерә һәм аларны билгеле эзлеклелектә сөйләп бирүгә ирешә. Мәсәлән, Г. Ибраһимовның “Табигать балалары” әсәреннән соң А. Пластов “Печән өсте”, Р. Загидуллин “Печәнгә төшү”, И. Шишкин “Арыш кыры” картина-репродукцияләре бирелгән, Ә. Еникиның “Кем җырлады?” әсәренә М. Покалев иллюстрациясе бирелә. Рәсем укытучысы белән уздырылган әлеге дәрестә укучылар әсәр белән иллюстрацияләрне чагыштыра, әсәр белән уртак якларын табарга өйрәнә. Рәсем укытучысы рәссамнар турында мәгълүмат бирә, сүрәтләнгән образлар, төсләр бирелешенә игътибар иттерә. Галимҗан Гыйлмановның “Ике дус һәм Ак бабай хакында кыйсса” хикәясен балалар яратып өйрәнә. Бу әсәрдә сурәтләнгән вакыйга балалар тормышына якын һәм таныш. Ике дус – Хәлим белән Сәлим – сыерчык оясы ясыйлар.“Ак бабай“ дип йөртелә торган Мөсәллим карт балаларга тормышта кирәкле киңәшләр бирә. Әмма балалар бу киңәшләрне тормышта төрлечә кулланалар. Әсәргә сорау-җавап, геройларга чагыштырма бәяләмә бирү юллары аша анализ ясаганнан

соң, хезмәт (технология) укытучысы әңгәмәгә кушыла. Ул әзер сыерчык оясын тәкъдим итә, ясау технологиясе белән таныштыра, әсәр геройлары ясаган сыерчык ояларына белгеч күзлегеннән бәя бирә. Әлеге әсәрдәге балалар җибәргән хаталарны истә тотып, хезмәт дәресендә сыерчык оясы ясау планлаштырыла. Әлбәттә сыерчыклар турында биология укытучысы күбрәк мәгълүмат бирә ала. Бу дәреснең хезмәт тәрбиясе ягыннан да. халык педагогикасы ягыннан да тәрбияви көче зур.

Әдәбиятны тарих, җәмгыять белеме фәннәре белән бәйләп, дөнья, яшәү, кешелек җәмгыяте турында күаллау формалаштырыла. Тарих фәне белән бәйләнеш, бер яктан, әдәбиятны тарихи үсештә өйрәнүдә күренә. Моннан тыш, һәр әдип, язучы – билгеле бер чорда яшәгән, иҗат иткән кеше. Телиме-теләмиме, аның иҗатында тарихи чорда булган вакыйгалар, заман кешеләрен борчыган мәсьәләләр күпмедер күләмдә чагылыш таба. Гадел Кутуйның “Рәссам” әсәрен карап китик. Әлеге әсәрдә сугыш, аның кешеләргә алып килгән фаҗигасе тетрәндергеч итеп сурәтләнә. Күз алдында булган вакыйгаларга нигезләнеп “Гитлерга мең нәләт” картинасын иҗат итә. Бары тик матурлык тудыручы рәссам Макс Латисны да сугыш кулына да корал алырга мәҗбүр иткән. Әсәрдә төп герой – иҗат кешесе. Автор аларның дөньяга икенче күзлектән каравы, үз дөньясы белән яшәве турында искәртә. Бу урында рәсем укытучысы сугыш вакытында җиңүне якынай туга зур өлеш керткән иҗат кешеләре турында сөйли ала. Тарих укытучысы сугыш вакытындагы Мәскәү шәһәре турында, хәрби дәрәҗәләр, сугыш вакытында кулланган кораллар турында сөйли. Марк Латис ясаган картинаны укучыларга ничек күзаллауларын күрсәтү өчен буяулар ярдәмендә рәсем ясарга тәкъдим ителә. Аңа кадәр әсәрдән әлеге картина сурәтләнгән урын таптырып кабат укытыла һәм сүздән сурәт ясарга кушыла. Мондый эш төрләре кулланып уздырылган дәрес укучыларда әсәрне җанлы итеп истә калдырырга, өстәмә белемнәр алырга ярдәм итә. Әдәбият буенча йомгаклау дәресләрендә һәм дәрестән тыш картиналар буенча сочинение яздыруга, сорауларга язма рәвештә җаваплар бирүне оештыруга шулай ук зур әһәмият бирелә.

Картина буенча сочинение яздыру укучыларны матурлыкны күрә һәм аңлый белергә, мөстәкыйль фикер йөртергә өйрәтә, аларның хис тойгыларын баета. Балаларның хыялларын киңәйтергә, танып белү активлыкларын үстерергә булышучы бу төр сочинениеләрне язарга өйрәнү буенча башлангыч сыйныфларда укучыларга билгеле күнекмәләр бирелә. Татар әдәбиятын рус әдәбияты, башка халыклар әдәбияты белән бәйләп укытып, әдәбиятлар ара-

сындагы уртак проблемаларны, уртак кыйммәтләрне күрсәтү аша дөнья культурасы белән таныштыру тора.

Күптеллелек шартларында татар һәм рус әдәбияты дәресләрендә мәдәниятлар аралашуы технологиясен куллану да аерым игътибарга лаек. Теләсә кайсы милләт язмышы аның башка халыкларга булган мөнәсәбәтендә, карашында ачык чагыла. Укучыларда толерантлык сыйфатларын тәрбияләүнең иң матур үрнәге рус һәм татар әдәбиятын интеграцияләп укытканда күренә. Әдипләрнең тормыш һәм иҗат юлларын, әсәрләрен һәм анда күтәрелгән проблемаларны ике милләт әдәбиятын янәшә куеп анализлауны укучылар кызыксынып кабул итәләр. Бигрәк тә татар әдәбияты дәресләрендә Г. Тукай белән А.С. Пушкинның, М.Ю. Лермонтов белән Дәрдемәнднең, Г. Ибраһимов белән Островскийның, Ф. Әмирхан белән И.С. Тургеневның кайбер әсәрләренә чагыштырма анализ ясап була. Моннан кала, бер милли әдәбият кысаларында да ике дөнья, ике мәдәният тормышын, аның асылын ачып бирергә мөмкин. Рус һәм татар халкының фольклоры – авыз иҗаты мисалында да кешелекнең дөньяны күзаллавы, танып белүе, мәдәни һәм кешелеклелек кыйммәтләрен таптыру билингваль, толерантлы шәхес формалаштыруга этәргеч бирә. Әдәбият иң элек Кеше тәрбияли. Әлеге технологияне куллануның төп максаты – мәдәниятле, гомумкешелек һәм гомуммәдәният кыйммәтләрен үзләштергән, милләт язмышында үз урынын тапкан, файдалы шәхес тәрбияләү.

### ӘДӘБИЯТ ИСЕМЛЕГЕ

1. Заһидуллина Д.Ф. Мәктәптә татар әдәбиятын укыту методикасы / Д.Ф. Заһидуллина. – Казан: Мәгариф, 2004. – 36 б.

2. Камаева Р.Б. Федераль белем бирү стандартларын тормышка ашыруда татар теле һәм әдәбияты укытучысына фәнни-методик ярдәм / Р.Б. Камаева, А.Х. Мөхәммәтҗанова. – Казан: ТРМҮИ, 2015. – 34 б.

3. Поташник М.М. Современные требования к уроку / М.М. Поташник. – М., ЦПО, 2008. – 228 с.

4. Татар әдәбияты. Рус телендә төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен). 7 нче сыйныф 2 кисәктә. Беренче кисәк. Ф.Ф. Хәсәнова редакциясендә. – Казан: Мәгариф, 2005. – 124 б.

**Л. Ф. ГОБӘЙДУЛЛИНА**
*Казан федераль университеты, Россия*

# ТАТАР БЛОГОСФЕРАСЫНДА ФРАЗЕОЛОГИЯНЕҢ СТИЛИСТИК КУЛЛАНЫЛЫШЫ

Яңа медиаларның теле жаргонизм һәм чит телле сүзләр кулланып сөйләшү, нормадан чигенүләре белән әдәби телне үзенчә баета. Татар теленең нормалары үзгәрү процессы нәкъ менә блогосферада актив күзәтелә. Блогерларның теле, җәмгыятьтә барган үзгәрешләр белән тыгыз бәйләнештә. Шул сәбәпле ул тел белеме, социология, иҗтимагый психология чигендә булган процессларның тыгыз бәйләнеше аркасында, тел галимнәре, политологлар, психологлар тарафыннан зур кызыксыну тудыра.

Борынгыдан һәр халыкның җанлы сөйләмендә афоризмнар, канатлы сүзләр, фразеологизмнар, мәкальләр һәм әйтемнәр кулланылган. Алар барысы да кешенең дөнья турындагы күзаллаулар җыелмасы нәтиҗәсендә барлыкка килгән, аларның һәммәсен дә халык үзе иҗат иткән һәм аның күңел байлыгын күрсәткән. Шуңа күрә телдәге тотрыклы берәмлекләрне өйрәнү телнең милли характерын күрсәтә.

Фразеологизм төшенчәсенә аңлатма биреп үтик: телдәге төшенчәләр бер сүз белән генә түгел, ә үзгәртүләргә бирешмичә, таркалмый торган тотрыклы сүзтезмәләр белән дә белдереләләр. Телдәге мондый сүзтезмәләрне фразеологизмнар дип атыйлар. Тел берәмлекләре буларак, фразеологизмнар түбәндәге дифференциаль билгеләргә ия: 1) сүзләрнең аерым булуы (кимендә ике сүз булу); 2) компонентларның мәгънәви кушылуы; 3) мәгънәнең һәм аны белдерүче лексик-грамматик чараларның тотрыклылыгы; 4) сөйләмдә әзер килеш кулланылуы [1, 48-54 б].

Галимҗан Ахунҗанов фразеологик берәмлекләр рәтенә афоризмнарны, канатлы сүзләрне, мәкальләр һәм әйтемнәрне дә кертеп карый һәм шуның белән фразеология төшенчәсен шактый киңәйтә. Биредә шул әһәмиятле: мәкаль, әйтем һәм табышмаклар, халык авыз иҗатының иң таралган һәм шул ук вакытта иң эшкәртелгән төрләре буларак, фразеологизмнарга бик бай була.

Фразеологик әйтелмәләр дә – халык иҗаты. Аларда халыкның тапкырлыгы чагыла. Алар кыска һәм оста әйтеләләр, гадәттә үткен һәм образлы сүзләрдән торалар. Стилистик яктан фразеологик әйтелмәләр эмоциональ-экспрессив, төрле стилистик төсмерләргә, субъектив бәяләү элементларына ия булалар. Фразеологик берәмлекләр үзгәрмичә дә кулланылырга мөмкин. Бу

очракта фразеологик берәмлек үзенә хас булган мәгънәсендә генә кала. Әмма кайбер очракларда фразеологик берәмлекләр үзгәртелеп, яңа мәгънә, яңа төзелеш белән дә кулланылырга, яңа эстетик һәм сурәтләү сыйфатлары алып, яңа фразеологизмга әйләнергә мөмкин.

Гомумхалык фразеологизмнар фондын блогосферада түбәндәге юнәлешләрдә үзгәртеп куллануы күзәтелә:

1. Фразеологизмның лексик-грамматик ягы яңара, мәгънәсе һәм төзелеше шул килеш кала. Мәсәлән, татар телендә “ачуым йөземә чыкты” яисә “шатлыгым йөземә чыкты” дигән фразеологизмнар бар. Татар журналисты Эльмира Сиражи әлеге тезмәне “хисләрем күзләремә чыкты” формасында кулланган. Шул ук авторның блогында “ачуымны чыгара” тезмәсен “җенемне чыгара” формасында күзәтергә була һәм бу очракта ачу хисе тагы да көчәйтелеп бирелә.

“Камыр ризыкларына *үлеп китә*” (Миләүшә Сибгатуллина). “Бер *кәстрүль ашны тәмләп кенә каплап салырлык* чамага җиткән Ләйсән” (Ләйсән Хаматдинова).

2. Фразеологизм, лексик-грамматик бөтенлеген саклаган хәлдә, контекстта яңа мәгънә эчтәлегенә ия була. Мәсәлән, Эльмира Сиражи үзенең инстаграм битендә икетөрле мәгънәгә ия булган тотрыклы сүзтезмә куллана: “Тордым да, суыткычта әни пешереп җибәргән ярты авыл тавыгы бар иде, шуны тәмләп кенә *бөгеп салдым*.” Әлеге мисалда фразеологизм ашау процессын белдерә. Шундый ук бөтенне, ләкин башка мәгънәдә, сторисында да очратып булды: “Йокларга уйламый әле бу, ничек *бөгеп саласы* булыр”.

3. Сурәтләү чарасы буларак фразеологизм үзе түгел, ә аның гомуми сурәте һәм эчтәлеге кулланыла. Эльмира Сиражи блогыннан бер мисал: “Бер зур язучыбыз, халык шагыйре, әле дә хәтеремдә “Үзе баткан сазлыктан үзе чыксын”, дип баш тартты”. “Үзе баткан сазлыктан үзе чыксын” гыйбарәсе “Үзе егылган еламас” дигән тарихи әйтемгә нигезләнеп ясалган.

Фразеологизмнар телнең үзенчәлекле атау берәмлекләре буларак, төшенчәләрне белдерәләр. Аларны төп мәгънәләре белән өч типка бүләргә мөмкин:

1) Мәгънәсе атау характерында ирекле булган фразеологизмнар. Алар составында сүзләр логик яктан төрле була.

“Авызларында ана сөте кипмәгән” (Миләүшә Сибгатуллина). “Кара янып йөргән” (Ләйсән Хаматдинова).

2) Икенче төркем фразеологизмнарның башка сүзләргә бәйләнеше фразеологик бәйле була. Әлеге типтагы берәмлекләр үзара янәшә килгәндә генә фразеологизмны тәшкил итә алалар.

“Кирәк урында назлап, яратып, *күккә чөя,* кирәк урында *иманымны укытып, җиргә төшерә*!” (Динара Әхмәт-Миннекаева)

“Туган көнемә Әнисә заказга дүрт зуууур бәлеш пешерде, дүртесеннән дә хайт дигәнче *җилләр исте*.” (Алсу Исмәгыйлева). “Шүрәлегә бит инде хәзер кызны *кулга төшерергә кирәк*.” (Рәмис Латыпов)

3) Өченче төр фразеологизмнарның синтаксик бәйле мәгънәләре була. Ул мәгънәләр теге яки бу җөмлә кисәге (хәбәр) функциясендә генә реальләшә. “Мәһдиев әсәрләре *баш түбәсенә чүкеп тора*” (Рәмис Латыпов).

“Ирен *камыр урынына изә* Хатын” (Рәмис Латыпов). Әлеге фразеологизм татар хатын-кызының бер яктан аш-суга, камыр ризыкларын оста пешерүенә ишарә иткән кебек, икенче яктан, ир-атны да шулай оста итеп җайлый алуын белдерә. Ягъни татар хатын-кызының милли характерын күрсәтә. Татар хатыны камырны оста баскан кебек, ир-атны да шулай оста итеп юмалый, үзенә карата белә. Шуңа күрә дә ир – баш, хатын – муен, дигән әйтем бар татар халкында.

Фразеологик әйтелмәләр кешеләрнең эмоциональ-эстетик кичерешләрен сурәтләүгә хезмәт итәләр. Әйтик, утлы табада биетү, вакытыңны корбан итү, тәм табып яшәү (Эльмира Сираҗи).

“Тордым да, суыткычта әни пешереп җибәргән ярты авыл тавыгы бар иде, шуны тәмләп кенә *бөгеп салдым*.” (Эльмира Сираҗи).

Татар блогерлары язмаларында кулланылган фразеологизмнар халык сөйләме нигезендә ясалган, алар халыкчанлык өстиләр, укучыга аңлаешлы һәм кызыклы. Алар авторларның сүз кулланыш өлкәсендәге иҗади эзләнүләренең нәтиҗәсен күрсәтә.

**ӘДӘБИЯТ**

1. Әхәтов Г.Х. Татар теленең лексикасы / Г.Х. Әхәтов. – Казан: Таткитнәшр., 1995. – 136 б.

**ДИНАЭР ХХХ**

*Казанский федеральный университет, Россия*

## ФОРМИРОВАНИЕ ТАТАРСКОЙ КОММУНИКАТИВНОЙ ЛЕКСИКИ

**Аннотация.** Для татарского языкознания важно комплексное описание основных лексических разрядов татарской лексики с использованием современных методов семантического исследования.

В статье исследуется лексико-семантическая группа «Коммуникативная лексика» и дается выводы ее реализации в татарском языке.

**Abstract.** For Tatar linguistics, it is important to provide a comprehensive description of the main lexical categories of Tatar vocabulary using modern methods of semantic research.

The article examines the lexico-semantic group "Communicative vocabulary" and provides conclusions on its implementation in the Tatar language

**Ключевые слова:** татарский язык, коммуникативная лексика, лексико-семантическая группа, современный язык, история

**Keywords:** Tatar language, communicative vocabulary, lexico-semantic group, modern language, history

Коммуникативная лексика один из древнейших и многочисленных по своему составу пластов лексической системы татарского языка.

Лексемы входят в состав групп в коммуникативном значении, в остальных же значениях они являются принадлежностью других группировок татарского языка. Одна и та же лексическая единица в разных значениях может входить в состав нескольких групп. Видовые пары и лексемы, различающиеся по признаку однократности действия, тендерному признаку, рассматривается как одна лексема

Коммуникативная лексика в татарском языке представлена лексико-семантическом поле «Аралашу/Общение», которое является одним из самых больших полей в лексико-семантической подсистеме языка. Данное поле включает в себе слова разных частей речи и разветвленную структурную организацию. Ключевыми единицами, номинирующими поле коммуникативной лексики и фразеологии татарского языка, являются лексемы *аралашу* и *аралашырга.*

Коммуникативная лексика татарского языка – один из древнейших пластов языка, она широко представлена в толковых, диалектологических словарях татарского языка.

Тематические группы коммуникативной лексики и основные тенденции ее развития по данным разных словарей различаются несущественно.

Сопоставительный анализ семантических подгрупп коммуникативной лексики показывает динамику развития отдельных микрополей. При этом очевидно, что процесс развития коммуникативных значений и появления новых коммуникативных лексем в диахроническом рассмотрении преобладает над их утратой.

Лексико-семантическое поле «Общение» в современном татарском языке широко интегрирует лексику для дифференцированной номинации сферы общения, а также использует большой пласт паремиологических единиц.

Отличительными чертами *системной организации* коммуникативной лексики татарского языка являются следующие: четкая структура поля, выделение в нем отчетливого ядра и периферии.

В ядро поля входят лексемы с высокой частотностью, наиболее общие по значению, без ограничивающих стилистических, эмоциональных, экспрессивных, оценочных и темпоральных сем, в минимальной степени зависящие от контекста. В ядро входят как однозначные, так и многозначные лексемы. У многозначных лексем все или большинство значений относятся к полю «Общение».

Лексемы ближней периферии имеют меньшую по сравнению с ядром частотность, они не ограничены в употреблении, в минимальной степени зависят от контекста. Многозначные лексемы, входящие в состав ближней периферии, имеют сему "сөйләм" в большинстве своих значений.

Дальняя периферия включает в себя лексемы с невысокой частотностью. Большинство лексем, составляющих эту часть поля, хотя и не имеют ограничительных сем, являются малоупотребительными. Коммуникативное значение в структуре многозначных слов не является основным. В отличие от ядра и ближней периферии дальняя периферия включает лексемы со стилистической и эмоционально-экспрессивными семами.

Наличие или отсутствие в лексико-семантическом варианте слова стилистических или эмоционально-экспрессивных сем приводит к тому, что данное слово в разных значениях относится к разным зонам поля. Так, например, лексема *сөйләшү/разговор* в значении "словесный обмен мнениями, сведениями, беседа" имеет высокую частотность, не ограничена в употреблении и относится к ядру поля.

Рассматриваемое лексико-семантическое поле имеет разночастеречный характер, состоит из разных частей речи с точки зрения их функциональной эквивалентности той или иной части речи. Поле представлено в большей степени глаголами, глагольными фразеологическими единицами и существительными.

Основными *семантическими особенностями* татарской коммуникативной лексики являются следующие.

Преобладание однозначной лексики над многозначной и сверх многозначной.

Характерной чертой лексико-семантического поля «Аралашу/Общение» является высокая доля *внутреполевой многозначности* производные значения лексем в большинстве случаев остаются в рамках ЛФП «Общение».

Наблюдается существенное преобладание неоценочных языковых единиц над единицами с оценочным и эмоциональным компонентами значения.

Наблюдается преобладание межстилевой лексики над стилистически окрашенной. Основная часть коммуникативной лексики стилистически нейтральна. Среди лексем, имеющих ограничительную стилистическую сему, отмечено преобладание разговорных и просторечных единиц. Книжная лексика составляет малоую часть от общего количества лексических единиц поля.

Основную часть фразеологии поля составляют разговорные и просторечные фразеологические единицы.

Таким образом, характерная чертами поля являются:

– преобладание разговорной лексики над книжной, что объясняется употреблением коммуникативных лексических единиц преимущественно в устной речи;

– преобладание фразеологических единиц с ограничительными стилистическими, эмоциональными, оценочными семами над лексемами с той же коннотацией.

Основными *лингвокультурологическими особенностями* татарской коммуникативной лексики являются следующие:

– большая паремиологическая внешняя периферия, свидетельствующая о важности общения в русской лингвокультуре, тенденции татарского человека к образному обозначению коммуникативных явлений;

– слабые территориальные, тендерные и возрастные особенности семантики, отражающие общеизвестность исследуемых языковых единиц.

Коммуникативная лексика в татарском языке обладает высокой коммуникативной релевантностью, она представлена объемным лексико-семантическим, ассоциативным полями.

Большая часть языковых единиц, составляющих лексико-семантическое поле «Аралашу/Общение», входит в современный словарный состав татарского языка. Устаревшие слова составляют не большое число от общего количества единиц поля.

Коммуникативная лексика активно используется в современном тексте, причем у многозначных лексем актуализируются преимущественно коммуникативные значения.

Коммуникативная лексика татарского языка образует объемное ассоциативное поле. Наиболее яркими смысловыми зонами ассоциативного поля являются: «Общие наименования актов речи», «Выражаемые взаимоотношения», «Партнеры», «Сфера протекания», «Содержание общения».

Татарская коммуникативная лексика демонстрирует активную динамику развития на всем протяжении своего существования.

В целом, лингвистические методы исследования обеспечивает дополнительность описания языкового материала и позволяет представить описываемую языковую группировку с необходимой полнотой и разноаспектностыо.

Коммуникативная лексика татарского языка является важнейшей составной частью лексической системы татарского языка, активно развивающейся и демонстрирующей устойчивую тенденцию к постоянному пополнению.

**ЛИТЕРАТУРА**

1. Шаманова М.В. *Общение* как коммуникативная категория в русском языковом сознании / М.В. Шаманова. – Воронеж: ИПЦ ВГУ, 2008. – 227 с.

2. Татар лексикологиясе: өч томда / Закиев М.З., Ганиуллина Г.Р., Фаттахова Р.Ф., Булатова А.К., под ред. Г.Р. Галиуллиной; руков. проекта М.З. Закиев. – Казан: ТӘhСИ, 2015. – Т. I. – 352 с.

**Г.З. ЗАКИРҖАНОВА**

*Казан федераль университеты, Россия*

## XIX ГАСЫРНЫҢ ИКЕ ТЕЛЛЕ СҮЗЛЕКЛӘРЕНДӘ СӘЛАМӘТЛЕК ӨЛКӘСЕНӘ КАРАГАН СҮЗЛӘРНЕҢ КИЛЕП ЧЫГЫШЫ

**Аннотация.** Двуязычные татарско-русские и русско-татарские словари XIX века служат ценным источником для изучения развития и изменения медицинской терминологии в татарском языке на протяжении всего XIX века. Объемы словарей XIX века разнообразны, но они отражают в себе богатство татарского языка. Лексические единицы в составе переводческих словарей XIX в. способствуют формированию медицинских терминов той эпохи, исследованию состояния, развития терминологии, определению их происхождения и отношения к современному литературному языку и диалектам, а также лингвистическому анализу терминологии в целом.

**Ключевые слова**. медицинская терминология, заимствования, словари XIX века.

**Abstract.** the Tatar language throughout the XIX century. The volumes of dictionaries of the XIX century are diverse, but they reflect the richness of the Tatar language. Lexical units in the translation dictionaries of the XIX century, they contribute to the formation of medical terms of that era, the study of the state, the development of terminology, the determination of their origin and relation to the modern literary language and dialects, as well as linguistic analysis of terminology in general.

**Keywords:** medical terminology, borrowings, dictionaries of the XIX century.

Телебезнең сүзлек составы – зур тарихи үсеш нәтиҗәсе. Хәзерге татар әдәби теленең сүзлек составы бик борынгы чордан ук яшәп килгән, төрки халыкларның барысы өчен дә уртак булган төрки телгә барып тоташа. Бу телдәге сүзләрнең күпчелеге хәзер дә җәмгыятьтә, кеше тормышында, көнкүрешендә иң әһәмиятле, иң кирәкле төшенчәләрне белдерә. Бөтен төрки телләрдә сүзләр әйтелеше, язылышы ягыннан аерылып торсалар да, гомумтөрки сүзләрнең мәгънәләре күп очракларда уртак. Мәсәлән, кешенең тән төзелешенә караган сүзләр гомумтөрки чыгышлы: баш, аяк, маңгай, каш, күз, кул, сын, арка, теш, бавыр, бугаз, муен, чәч, колак, авыз һ.б.

Алда күрсәтелгән сүзләр, бик борынгы заманнарда барлыкка килеп, нигездә, төрки телләрнең күбесендә сакланып калганнар. Алар телнең төп сүзлек фондын тәшкил иткәннәр, шуларга нигезләнеп, телнең сүзлек составы үсә, үзгәрә, камилләшә, байый барган.

XIX гасырның ике телле сүзлекләрендә урын алган лексика татар телендә шул вакытта ук төрле телләрдән күчкән алынма сүзләр булганлыгын раслый. Ул алынмалар, гомумтатар теленең сүз байлыгы белән чагыштырганда, шактый зур урын алып тора.

Иҗтимагый-сәяси һәм мәдәни бәйләнешләр нәтиҗәсендә, гарәп-фарсы телләреннән татар теленә шактый күп алынма сүзләр килеп керә. Бу сүзләрнең күчүенә татарлар арасында таралган күп төрле дини китапларның да йогынтысы булмый калмый. Алынмалар телебездә ныклап урнашып калганнар, күп очракларда татарлашканнар, яңа сүзләр ясау өчен нигез булып хезмәт итә башлаганнар.

Әлеге алынмалар медицина терминологиясе өлкәсенә дә карый. Мәсәлән, XIX гасыр тәрҗемәи сүзлекләрендә түбәндәге сәламәтлек сүзләре гарәп теле берәмлекләре буларак теркәлгәннәр: дару ханясе [2, б.3] – аптека; даругярь башы [2, б.3.] – аптекарь; истиска [5, б.35] – водянка.

Бу берәмлекләрнең бер өлеше генә гарәп-фарсы алынмалары сүзлегендә теркәлгән. Алар түбәндәгеләр: сәламәт – исәнлек-саулык (здравость) (519); димаг – мозг (111); дәм – дыхание (114); шифа – лекарство (705); шифаханә – больница (705); табиб – врач (537); тыйб – медицина (549); бәдән – плоть, тело (39); истиска – водянка (болезнь) (179); әгъза – член, сустав (725); әл – рука (733); җәрахәт – рана (776); хәрарәт – горячка, воспаление, жар (681); хөмма – лихорадка, горячка (692); зиһен – разум (132); зикер – памятствование, воспоминание (129); тагун – мор, моровая язва, чума (538); мәрд – болезнь, недуг (320); нәзар – взор, взгляд (454); әҗәл – смерть (756); хәким – мудрец, медик (675); хатир – сердце (653); калеб – сердце (200); гыйлаҗ – лекарство (98);

вафат – смерть (52); хәббә − пилюля (669); җәррах – врач (776); мәҗнүн – сумасшедший, безумный (349); маддә − материал болезни (302); мәгъҗүнче – аптекарь (341) һ. б.

Димәк, гарәп теле үзе үк XIX гасырдан соң сизелерлек үзгәрешләр кичергән. Кайбер сүзләр юкка чыккан, кайберләре мәгънә киңәю, тараю күренешен кичергән. Тик шуны билгеләп үтәргә кирәк: татар теленең XIX гасыр лексикасында, шул исәптән сәламәтлек сүзләре арасында гарәп чыгышлы сүзләр зур урын алып торганнар.

Ләкин гарәп алынмалары турыдан-туры гарәп теленнән генә керми. Аларның күпчелек өлеше фарсы теле аша керә. Шуңа күрә андый сүзләр безгә семантик һәм фонетик яктан фарсы теле үзенчәлекләрен алып өстәп керәләр. XIX йөз тәрҗемәи сүзлекләрдә кулланылган фарсы чыгышлы медицина терминнарына түбәндәгеләр керә: пимаръ ханя [2, б.259.] – лазаретъ; тиръ [2, с. 432.] – потъ; тимар [2, б.372.] – лечение; димаг [4, б.536.] – мозгочек в виске.

М.И. Мәхмүдовның алынмалар сүзлегендә бу берәмлекләр түбәндәге мәгънәдә киләләр: тимар – лечение (546); димаг – мозгочек в виске, мозг (111); бәдфигыль – злокачественный, зловредный (38); тәб – жар, лихорадка, горячка (550); хәстә – болезнь, больной (685); дару – лекарство (107); дәрд – болезнь (116); мәгыз – мозг (297); сыркау – болезнь (513) һ. б.

Шуны әйтергә кирәк, гарәп-фарсы алынмаларның күп кенә сүзләре бүгенге көндә сәламәтлек термины буларак нормалашкан һәм актив кулланылышта йөри: дару (фарсы), даруханә (фарсы), яшь (фарсы), хаста (фарсы), сырхау (фарсы), тир (фарсы); зиһен (гарәп), шифаханә (гарәп), табиб (гарәп), җәрәхәт (гарәп), дәва (гарәп), тән (гарәп), сәламәтлек (гарәп), матдә (гарәп).

XIX гасыр сүзлекләрендә сәламәтлек терминнары рәтендә телдә актив кулланылган рус алынмалары да теркәлгән. Бу сүзләр, нигездә, фонетик яктан татар теленә яраклаштырылып бирелгән. Мәсәлән: ликар – лекарь, врач [5, б.100]; пластыр – пластырь [5, б. 202.]; пляш – плешивый [5., 203.]; фершал – фельдшер [5, б. 350.]; чакутка – чахотка [5., б. 358.] һ. б.

А. Воскресенский, Н. Остроумов үз хезмәтләрендә рус алынмаларын башка сүзлекләргә караганда күбрәк теркәгәннәр. Бу күренеш аларның төп эшчәнлекләре, миссионерлык хәрәкәте вәкилләре булу белән бәйле булырга мөмкин. И. Гиганов, Н. Юнысов сүзлекләрендә рус алынмаларның татар телендә үзләштерелгән, ныклап урнашкан берәмлекләре генә бирелгән.

Рус теленә кергән сүзләрнең хәрәкәте дә, мәгънәләре дә кызыклы. Аптека сүзе XVI гасырда поляк теленнән рус теленә кергән. Поляк теленә латин, ә ла-

тин теленә грек теленнән алынган. Беренчел мәгънәсе – “кладовая, склад”. Әйтик, сүзләрнең шундый ук рәвештә телдән телгә күчешен без Л. Будагов сүзлегеннән тикшереп, билгели алабыз. Мәсәлән, «госпиталь» сүзе итальян теленнән төрек теленә (испиталия) кергән. Төрек теленнән руслар тарафыннан үзләштерелгән булырга мөмкин. Шулай ук «элексир» сүзе грек теленнән зур күчеш ясап, гарәпләр тарафыннан үз ителә (әләксир) һәм гарәп теле аша татар теленә дә керә.

Ауропа медицина терминологиясенең үзләштерелүендә Каюм Насыйриның тәрҗемәи сүзлекләре аеруча әһәмияткә лаек. Галим үзенең 1892 нче елгы тәрҗемәи сүзлегендә «Иностранные слова» бүлеген тәкъдим итә. Әлеге бүлектә ул ауропа терминнарын саф татарчага тәрҗемә итә. Ләкин бу тәрҗемәләр аерым сүзләрдән түгел, ә аңлатма рәвешендәге гыйбарәләр һәм җөмләләрдән гыйбарәт. Автор адемония, азоогения, акразия, аконитин, акремония, анатомия, ангелика, апоплексия, гельминтология, гематопатия, диафрагма, катаракта, медикамент, оптика һәм башка шундый кебек 93 медицина берәмлегенә татарча аңлатма бирә. Мәсәлән: хлороформ – хисне ала торган бер дәвадыр [3, б. 261]; диафрагма – корсак белән күкрәк арасындагы бер пәрдә [3, б.238].

Алынма терминнарның шул рәвешле сүзлектә бирелүе аларның тиз арада таралу һәм үзләштерелү процессларына зур этәргеч була. Димәк, сүзлекләрдә теркәлгән һәм сәламәтлек өлкәсенә караган берәмлекләрнең зур өлешен алынма лексика тәшкил итә. Һәм алынма сүзләр еш кына татар теленең үз сүзләре белән синонимик рәтләрне барлыкка китерәләр. Мәсәлән:

1. пибмарханә, чирлеләр өе, шифаханә, авыруханә, табибханә, шпитал, испиталия – больница, лазарет;

2. сырхау, авыру, хаста, тимар, пибмар, кумар, тагун, чир, зәхмәт, мәрд, дәрд, рәнҗеү – болезнь; һ.б.

Күренгәнчә, шул чор татар телендә рус сүзләре , бүгенге телнең лексикасы белән чагыштырганда, күпкә азрак куллланылганнар. Ләкин XX гасырда иҗтимагый-икътисади шартларның үзгәрүе, фән һәм техника үсеше телдә кулланылышта йөргән рус алынмаларының күләмен арттыра. 1990 елга кадәр әлеге процесс интенсив рәвештә үсә. Бары тик Үзгәртеп кору чорыннан соң онытылган лексиканы кире кайтару һәм татар телен алынмалардан арындыру омтылышы көчәя.

XIX гасыр сүзлекләрендә тупланган рус теле чыгышлы терминнарның билгеле бер өлеше хәзерге татар телендә бөтенләй кулланылмый диярлек. Кайберләрнең мәгънәләре үзгәргән, ә бер төркем сүзләр әдәби телдә кулланылмыйлар, бары диалектларда гына саклананалар.

Гомумән алганда, авторлар иң кирәкле, кулланылышта актив булган алынмаларны гына теркәгәннәр, һәм бу сүзләр татар теленең лексик базасын үстерүгә зур өлеш кертәннәр.

**ӘДӘБИЯТ**

1. Воскресенский А. Полный русско-татарский словарь / А. Воскресенский. – Казань, 1894. – 370 с.

2. Гиганов И. Словарь российско-татарский, собранный в Тобольском народном училище учителем татарского языка, священником Иосифом Гигановым и муллами юртовскими свидетельствованные / И. Гиганов. – СПб.: Тип. АН, 1804. – 682 с.

3. Насыри К. Полный русско-татарский словарь, с дополнением из иностранных слов, употребляемых в русском языке как научные термины / К. Насыйри. – Казань, 1892. – 263 с.

4. Троянский А. Полный русско-татарский словарь: В 2 т. / А. Троянский. – Казань, 1833. – Т. 1. – 629 с.; 1835. – Т. 2. – 340 с.

5. Остроумов Н. Татарско-русский словарь / Н. Остроумов. – Казань: Тип. ун-та, 1892. – 246 с.

**А.Р. ЗАКИРОВА**

*Казан федераль университеты, Россия*

## “ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН” ГАЗЕТАСЫНДА СОҢГЫ ЕЛЛАРДА ЧЫККАН МӘКАЛӘ АТАМАЛАРЫНДА ҖӨМЛӘ КИСӘКЛӘРЕНЕҢ БИРЕЛЕШЕ

**Аннотация.** В статье расмотрены члены предложений в газетного заголовках.

**Abstract.** The article discusses the members of the proposals in the newspaper headline.

**Ключевые слова:** статья, газета, заголовок, члены предложения, синтаксис.

**Key words:** sports article, newspaper, sentence members, syntax.

Җөмлә төзелешен тикшергән вакытта, җөмләне кисәкләргә таркатып, аларның үзенчәлекләрен һәм үзара мөнәсәбәтләрен билгеләү аеруча әһәмиятле. Хәзерге көндә җөмләләрне кисәкләргә бүлүнең дүрт төрле принцибы бар: логик-грамматик, структур-семантик, синтагматик һәм актуальлек принциплары. Бу фәнни эшебездә без логик-грамматик принципка тукталырбыз. Әлеге бүлектә “Ватаным Татарстан” газетасының 2019 нчы һәм 2020 нче елда чыккан гыйнварь – май саннарындагы мәкалә атамаларында логик-грамматик җөмлә кисәкләренең бирелешен күзәтеребез, мисаллар белән дәлилләрбез.

Ике составлы җөмләләрдә гади ия һәм тезмә ия булырга мөмкин. Гади ия – бер сүз белән, тезмә ия – фразеологик сүзтезмә белән бирелә. “Ватаным

Татарстан” газетасының мәкалә атамаларында күп очракта гади ияләр кулланыла. Тезмә ия булган мисалларның саны бик аз, чөнки журналистлар күп очракта мәгълүматны туры мәгънәдә җиткерәләр. 2019 нчы елгы саннардан тезмә ияле мәкалә атамаларына мисаллар: “Яңа Тинчәле яңа чишмәле булды”, “Өч карыш” җир һәм җитмеш еллык тарткалаш”, “Вәгыйз абзый нәрсә дияр иде?” һ.б.

2020 нче елгы саннардан тезмә ияләргә мисаллар: “Әсир көндәлеге яки “Яралы язмышлар” тергезелә”, “Үги ана яфрагы юешрәк урынны сайлый яки..”, “Сукыр кычыткан – файдалы үсемлек”, “Мин татарча сөйләшәм” чарасы быел булачакмы?” һ.б.

Хәбәрләр ике төрле булалар: фигыль хәбәр һәм исем хәбәр. Мәкалә атамаларында фигыльләр иң күп кулланылган категория булып санала. Еш кулланылган хәбәрләр: гади фигыль хәбәр, кушма фигыль хәбәр һәм гади исем хәбәрләр. 2019 нчы елгы саннардан мисаллар: “Табигать бәла-казаларыннан килгән зыянны ничек киметәсе?” (гади фигыль хәбәр), “Тактаны укытучы сөртергә тиеш” (кушма фигыль хәбәр), “Кемгә – ял, кемгә – гөмбә” (гади исем хәбәр) һ.б.

2020 нче елгы саннардан мисаллар: “Халык өйдә вакытта шәһәр транспортларын үзгәртәчәкләр” (гади фигыль хәбәр), “Авыл янындагы сулыкка аккошлар кайтасы иде” (кушма фигыль хәбәр), “Телебез – татар, әдәбиятыбыз – татар әдәбияты” (гади исем хәбәр) һ.б.

Мәкалә атамаларында бер составлы җөмләләр дә кулланыла. Алар өч төрле: фигыль җөмлә, исем җөмлә, сүз җөмлә. Мисаллар күрсәткәнчә, сүз җөмләләрне мәкалә атамасына бик сирәк кулланалар, әлеге төргә мисаллар очрамады.

Иясез җөмләләр, ягъни фигыль җөмләләр саны, ике елгы газет саннарында да шактый күп, чөнки процессны үтәүче билгеле була. Ә билгесез үтәүчеле бер составлы җөмләләр саны бик сирәк. 2019 елгы саннардан билгеле үтәүчеле бер составлы җөмләләр: “Синең инде өйнекеннән соң кибетнекенә кызыгырга теләгең булмый”, “Җинүчегә зур авырлыкларны үтәргә туры килде”, “Күршеләрдән калышасы түгел иде!” һ.б.

2020 елгы мәкалә атамалары: “Бу сезонда кубок һәм медальләргә ирешәсе иде”, “Икенче елга безгә нәтиҗәләрне яхшыртырга”, “Тулы канлы эшләү, яшәү режимына кайтасы иде” һ.б.

Матур әдәбияттә атау җөмләләр һәрвакытта кулланылсалар да, газета атамаларында сирәк кулланылалар. “Ватаным Татарстан” газетасында атау җөмләләрне матур әдәбияттән мисаллар, шигырьләр, романтик рухлы язмалар

бастырганда файдаланалар. 2019 нчы елгы саннарда атау җөмләләр 2 тапкыр күбрәк кулланылган. Әлеге сизелерлек үзгәреш илдә барган вакыйгаларга бәйле булуы мөмкин. 2019 нчы елгы саннардан атау җөмләләргә мисаллар: “Урман. Матур алан”, “Циркач”, “Яктылык”, “Яңа ел”, “Могҗиза”, “Бардак”.

2020 нче елгы саннардан мисаллар: “Мөслим кырмыскасы”, “Үзизоляция”, “Кайту”.

Җөмләләрдә төгәлләүле һәм аныклаулы мөнәсәбәткә кергән сүзләрнең иярүчесе иярчен кисәк дип атала. Иярчен кисәк җөмләне күләме һәм мәгънәсе ягыннан тулыландыра, һәрвакыт җәенке итеп формалаштыра. Иярчен кисәкләр бер составлы һәм ике составлы җөмләләрдә дә кулланалар. Газета атамаларын иярчен кисәкләрдән башка күз алдына китереп булмый. Татар телендә булган һәр иярчен кисәкләргә күзәтү ясап мисаллар белән дәлилләрбез.

Аергыч – җөмләнең предмет төшенчәсен атаучы кисәгенә ияреп, шул предметларның билгесен, санын һәм кемгә каравын билгели. Мәкалә атамаларында сыйфатлар, рәвешләр, саннар белән бирелгән аергычлар еш кулланыла. Хәбәрлек сүзләр һәм фигыльләр белән бирелгән мәкалә атамаларына мисаллар бик сирәк.

2019 нче елгы саннардан мисаллар: “Гөрләвексез язлар узып бара”, “Янган үңәч урынына – яңасы...”, “Гади конфликт кынамы, атом-төш сугышымы?”, “Буаны мин зур шәһәр дип уйлый идем. Барып кергәч, кая эләктем икән мин, дип аптырадым” һ.б.

2020 нче елгы газет саннарыннан мисаллар: “Сәясәтче Руслан Айсин: “Милли элитаны үстерү өчен аерым бер программа кирәк”, “Үз авылың кешеләрен таныма инде!”, “Җиденче каттан караш…”, “Сталин бункеры… Икенче Бөтендөнья сугышы вакытында төзелгән иң тирән корылма нинди серләр яшерә?”, “Чаллы татар дәүләт театрына яңа сәнгать җитәкчесе билгеләнде” һ.б.

Тәмамлык процессның объектын, үтәүчене яки нинди дә булса бер хәл кичерүче әйберне белдерүче иярчен кисәк. Тәмамлык – җөмләнең процесс белдерүче сүз белән бирелгән теләсә кайсы кисәгенә иярә алганлыктан, мәкалә атамалырында иң актив кулланучы иярчен кисәк булып санала. Тәмамлыклар туры тәмамлык һәм кыек тәмамлык дигән төрләргә бүленәләр. Нәтиҗәләр күрсәткәнчә, мәкалә атамаларында кыек тәмамлыкка караганда, туры тәмамлыклар күбрәк кулланалар.

2019 нчы елгы саннардан мисаллар: “Суда үзегезне дөрес тота беләсезме?”, “Таң атканда. Әтнә сыерлары ничек итеп сөтне күбрәк бирә?”, “Китапларны кызыл чүпрәккә төреп йөрдек”. Социализмны сагынабызмы, әллә яшьлекнеме?” һ.б.

2020 нче елгы саннардан мисаллар: “Имтиханда кагыйдә бозучыларны яңача тикшерәчәкләр”, “Диетолог Луиза Шиһаповадан еллардан соң организмны чистарту буенча киңәшләр”, “Татар әдәбиятында иң күп укылган китапны атадылар”, “Республикада әзерләнгән дәреслекләрне Татарстанда тикшерәчәкләр” һ.б.

Хәл – шулай ук иң актив кулланыла торган иярчен җөмлә кисәге. Ул процессның яки билгенең билгесен, процессның үтәлү вакытын, урынын, рәвешен, сәбәбен, максатын, юнәлешен, шартын, күләм дәрәҗәсен белдерә. Мәгънә ягыннан хәлләр 8 төрле булганлыктан, җөмләләрдә алар еш кулланалар. 2019 нчы һәм 2020 нче елгы мәкалә атамаларында аларның саны үзгәрмәгән. Урын, вакыт, шарт, максат хәлләрен, калган хәлләргә караганда, язма исемнәрендә күбрәк очраттык. 2019 ел: “Төннәр буе йоклый алмый ятсаң...”, “Татарстанга сигез медаль кайтты. Җиңүләр тагын да күбрәк”, “Бензин җәйгә кадәр артамаячак. Аннары ни булыр?”, “Сала былтыр нишләде? Авыл хуҗалыгында чебеш саныйлар” һ.б.

2020 нче елгы мисаллар: “Ни өчен кунак киткәч тә өй җыештырырга ярамый?”, “Җиденче каттан караш… Армия тулысынча контрактка күчерме?”, “Хатын-кызлар белән ир-атларга мәҗлестә янәшә утыру ярыймы?”, “Акча түләргә өлгергәнче ялгыш төшереп ватылган товар өчен сатып алучы түгел, кибет җавап бирә” һ.б.

Эндәш һәм кереш сүзләр сөйләүченең чынбарлыкка, тыңлаучыга, җөмлә эчтәлегенә, төзелешенә мөнәсәбәтен белдерә торган кисәкләр. Кереш сүзләрне мәкалә исемнәрендә сирәк очратырга мөмкин. Алар күбрәк язмада укучының игътибарын җәлеп итү һәм кемгәдер мөрәҗәгать итү өчен кулланалар. Эндәш сүзләргә килгәндә, алар мәкалә атамаларында еш кулланалар. 2019 нче елгы мәкалә исемнәре: Әткәй-әнкәй, өйрәт давай!, “Китмә, китмә, сандугач..., “Хуш, Америка!”, “Улым, чыгып кит! Балалар әти-әнисе белән яшәргә тиешме?”, “Йөткермә, балам!” һ.б.

2020 нче елгы саннарда 1 генә кереш сүзле мәкалә атамасы табылды: “Үзең дә бит көтмәгәндә китеп бардың, Роберт абый!..”.

Йомгак ясап әйткәндә, “Ватаным Татарстан” газетасының мәкалә атамаларында җөмлә кисәкләренең бирелеше күптөрле. Мәкалә атамалары билгеле бер структура буена түгел, ә мәгълүматны укучыга аңлаешлы һәм кызыклы итеп тапшыру ниятеннән төзелгәннәр.

**ӘДӘБИЯТ**

1. Зәкиев М.З. Татар теленең синтаксик төзелеше. – Казан: Ихлас, 2013. – 392 б.

2. Кашапов М.Х. Татар теле синтаксисыннан лекцияләр. – Казан: Gumanitarya, 2003. – 168 б.

3. Мирзаһитов Р.Х. Татар теле (кагыйдәләр, методик киңәшләр, анализ үрнәкләре, биремнәр). Абитуриентлар, укытучылар, студентлар өчен // Р.Х. Мирзаһитов, Р.К. Сәгъдиева, Д.Х. Хөснетдинов. – Казан: “Мәгариф-Вакыт” нәшрияты, 2017. – 191 б.

**Ф.Ф. ЗАКИРЯНОВА**

*Казан федераль университеты, Россия*

## ХАЛЫК АВЫЗ ИҖАТЫНДА ЗООНИМНАРНЫҢ КУЛЛАНЫЛЫШЫ

**Аннотация.** Произведения устного народного творчества тесно связаны с бытом, языковыми-речевыми особенностями, прошлым и настоящим народа. В составе татарских народных пословиц часто встречаются зоонимы. Именно в них заложен метафорический смысл, который делает пословицу метафорой.

**Ключевые слова:** пословицы, зоонимы, образ лошади, коня, метафора, кошка, собака, гусь, утка, птицы, волк, лиса.

**Abstract.** The words of oral folk art are closely connected with the life of people, linguistic and speech features, past and present. Zoonyms are often found in Tatar folk proverbs. It is in them that the methaphorical meaming is embedded, which makes the proverb a metaphor.

**Keywords:** proverbs, zoonyms, image of a horse, horse, metaphor, cat, dog, goose, duck, birds, wolf, fox

Халык авыз иҗаты текстларындагы тел мәгълүматлары халыкларның рухи мәдәнияте тарихын өйрәнү һәм торгызу өчен киң кулланыла. Халык авыз иҗаты әсәрләре халыкның тормыш-көнкүреше, тарихы, шул исәптән, тел-сөйләм үзенчәлекләре белән тыгыз бәйләнештә тора.

Мәкальләр — теге яки бу халык теленең тарихи үсеше күрсәткече, шуңа күрә алар үзләрендә телдә берничә гасырда булган лексик, фонетик, морфологик, синтаксик үзгәрешләрне чагылдыралар. Еш кына мәкаль һәм әйтемнәр составында зоонимнар очрый. Нәкъ аларга бөтен мәкальне метафора итә торган метафорик мәгънә салынган. Төрле диалектларга һәм сөйләшләргә караган хайван һәм кош-корт атамалары мәкальләрдә күпчелекне тәшкил итә, чөнки татарлар хуҗалыгында гасырлар буе аучылык һәм терлекчелек зур әһәмияткә ия булган. Кошларны һәм хайваннарны аулау, хуҗалык эшчәнлегенең алыштыргысыз бер өлеше буларак, кешеләрнең рухи тормышында да чагылган.

Татарларның көнкүрешендә башка йорт хайваннары арасында һәрвакыт ат аерым хөрмәткә лаек урын ала. Атка карата шундый хөрмәт, аны күккә чөеп мактау күчмә халыкларның көнкүрешендә әйдәүче рольгә ия булуы белән аңла-

тыла. Татар халкы борын-борыннан атлар белән бәйләнгән, атлар асраган. Шул рәвешле, ат лексемасының татар аңында бүген дә нигез буларак ассоцияләнә торган мәгънәсе ерак борынгылыкка барып тоташа. Татар халкының милли бәйрәме – Сабан туе да ат чабышларыннан башланып киткән, һәм бу гореф-гадәт әлеге көнгәчә дәвам итә. Ат образы күп яктан чагыштырылып кеше тормышына да күчерелә.

Ат борынгыдан ук крестьянның беренче ярдәмчесе булып саналган, чөнки хуҗалыкта алыштыргысыз хезмәт коралы, транспорт, җитешлек һәм горурлык күрсәткече булган. Моны шулай ук төрле яктан тасвирланган мәкальләрдә дә күрергә мөмкин: Җирән атым кешнидер, үлән төбен тешлидер//Тимер ат җирне сөрә, ә ашарга сорамый //Алтмыш атка бер арба // Ишәк белән ат ярышмаячак. Фольклор текстларында ат, айгыр, алаша, аргамак, толпар, юртак/ юрга, бия, колын, тай, байтал дигән атамалар очрый. Аларның барысының да үз эмоциональ төсләре бар.

Мәсәлән, меринны тасвирлау өчен еш кына сыйфат картасы (алаша) кулланыла һәм ул текстларда айгырга антоним буларак очрый: Ашарга карт алаша, тартырга – тай. Мәкальләрдә атларга характеристика бирү өчен яхшы, житез, чыдам, юаш, яман/ начар, ялкау, тугры сыйфатлары кулланыла.

Мәкальләрдә урын алган барлык җәнлекләр һәм хайваннар аллегорик образлар булып торалар һәм кешегә хас булган билгеле бер сыйфатлар белән тасвирланалар. Текстларда бу образлар кеше кебек уйлый һәм тәэсир итә. Мәсәлән, төлке – хәйлә, куян – куркаклык, аю – игелеклелек һәм көч, сарык – ахмаклык, ишәк – үҗәтлек, арыслан – батырлык, тәвәккәллек, бүре – комсызлык, чукраклык һ. б. Мәсәлән, Аю сыртына ябышкан//Бүре бер эздән йөрер // Бүреләр берәр эз буйлап йөри // Үткәрелгән халык, төлке ятып кала //Бәйле арысланга куян да ташлана// Аюдан курыккан бүрегә юлыккан// Бүре бер күзе белән йоклый// Төлке төшендә дә тавык саный  һ.б.

Татар халык мәкальләрендә еш кына йорт хайваннары песи / мәче һәм эт искә алына. Энциклопедик билгеләмәләргә караганда, юлбарыс, песи һәм арыслан кебек хайваннар бер таксонга, ә атап әйткәндә - мәчеләргә карыйлар. Юлбарыс һәм арысланнан аермалы буларак, песиләр ялкау, назлы, яшерен хайваннар буларак характерлана: Мыштым мәче майны күбрәк ашый// Мәче, үзе йокласа да, күсене күрә // Песи сөт салып ала белмәсә дә, чүлмәкне аудара белә // Сыйпаганны песи дә ярата.

Этләр төрле була, бу хакта мәкальләрдә дә телгә алына. Этләрнең иң таралган бүленеше тире төсе: ак һәм кара. Алар еш кына бер-берсенә капма-каршы куела: Ак эт бәласе кара эткә // Ак эт урлаган, кара эт тамга алган.

Шулай ук түбәндәге сыйфатлар да кулланыла: яшь / карт, котырган, куркак, симез, усал, хуҗасыз, яман – яхшы. Усал эт арттан килеп өрми кабар // Котырган эт ай өстенә сикерә // Бәләкәй генә эт күккә карап тора өрә һ.б. Мисаллардан күренгәнчә, эт һәм мәчеләрнең гамәлләре, нигездә, аларга карата читтән, ягъни кешеләр мөнәсәбәтеннән тора. Шуңа күрә алар яхшы да, начар да булырга мөмкин.

Күп кенә мәкальләрдә йорт кошларының исемнәре очрый: тавык, әтәч, чеби, үрдәк, каз, күркә. Хайваннар кебек үк, алар да тышкы сыйфатларыннан һәм үз-үзләрен тотышының сыйфатыннан чыгып характерлана. Мәсәлән, тавык – надан, ләкин бик тырышып эшли торган гаилә учагын саклый торган кош-корт, әтәч – гаилә башлыгы, койрыклы, сагыш чукмары; үрдәк – әллә ни әһәмияте булмаган сазлыкны ярата торган йорт кошы; каз – ныклы гаилә символы; күркә – үзен ярата торган һ.б. Кеше тавыгы каз кебек, йомыркасы баш кебек// Тавык белгәнен кычкырыр// Күрше тавыгы күршегә күркә булып күренә //Кечкенә булсаң да, әтәч бул //Тумаган тавыкны ашыйлар// Йортым тулы ак тавык, уртасында кара тавык// Әтәч – үз чүплегендә патша// Әтәч белән сука сөрмиләр //Әтәчнең күрке – кикриге дә койрыгы// Балалы үрдәк күлдән китмәс// Ялгыз казның тавышы чыкмый// Кабарыну – күркә гадәте.

Башка кошларның исемнәренә килгәндә, еш кына мәкальләрдә карга, карлыгач, карчыга, сандугач, торна, чыпчык очрый. Шул ук вакытта барлык жанрларда да характеристика бер генә мәгънәгә ия: карга – бары тик зарар гына китерә; карлыгач – шатлык китерә торган язгы кош; карчыга – янау; сандугач – күңел җырчысы, азатлык турында сагыш символы. Сандугач – читлектә, карга – directed иректә // Козгын яу башлар, яуга иярер// Очканда карлыгач очар, сайраганда – сандугач //Карга күзе төшкән орлык шытмас // Бәләкәй генә чыпчык, Алтын челтәр, Бохар итәр Үзе кара – карга түгел.

Шулай итеп, татар халкының милли үзенчәлеге борынгы заманнардан ук югары сәнгатьле булган мәкальләр аша тапшырыла, бу исә лингвистик шагыйрьнең төрле чаралары һәм алымнары белән барлыкка килгән. Шулардан зоонимнар куллану зур әһәмияткә ия. Нәкъ аларга бөтен мәкальне метафора итә торган метафорик мәгънә салынган.

**ӘДӘБИЯТ**


1. Авзалова Л.Д. Әдәби әсәрләрдә ат образының семантик кулланылышы / Л.Д. Авзалова // Милли мәдәният. – №18. – 78 б.
2. Әхәтов Г.Х. Татар теленең фразеологик әйтелмәләр сүзлеге. / Г.Х. Әхәтов. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1982. – 174 б.

3. Борһанова Н.Б. Татар теленең фразеологиясе, мәкаль һәм әйтемнәре. / Н.Б. Борһанова, Л.Т. Мәхмүтова, Л.Җ. Җәләй. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1957.

4. Галиуллина Г.Р. Хәзерге татар теле лексикологиясе / Г.Р. Галиуллина. – Казан: КФУ, 2013. – 124 б.

5. Галиуллина Г.Р. Лексик берәмлекләрне лингвокультурологик аспектта тикшерү / Г.Р. Галиуллина. – Казан: КДУ, 2009. – 20 б.

6. Гаффарова Ф.Ф. Татар теленең сүзлек хәзинәсендә игенчелек, җир эшкәртү лексикасының тоткан урыны / Ф. Гаффарова // Фән һәм тел. – 2002. – №1. – 76 б. Җамалетдинов Р. Р. Татар теленең этнокультура лексикасы: сүзлек-белешмәлек / Р.Р. Җамалетдинов; ф. мөх-р А.Ә.Әминова. – Казан: Алма-Лит, 2003. – 143 б.

7. Җамалетдинов Р.Р. Тел һәм мәдәният: Татар лингвокультурологиясе нигезләре / Р.Р. Җамалетдинов. – Казан: Мәгариф, 2006. – 351 б.

8. Җамалиева Л.Ф. Халык җырларында урын алган ат образының үзенчәлекләре: (татар, башкорт, чуаш җырлары мисалында) // Яңа гасыр һәм татар әдәбияты: әдәби хәрәкәтне һәм әдәби әсәрләрне анализлау: студентлар өчен кулланма / Л.Ф. Җамалетдинова. – Казан: ТДГПУ, 2007. – 210 б.

9. Исәнбәт Н. С. Татар теленең фразеологик сүзлеге: 2 томда / Н. С. Исәнбәт. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1989.

10. Мәхмүтов Х. Ш. Канатлы сүз – хикмәтле сүз. / Х. Ш. Мәхмүтов. – Казан: Мәгариф, 1999.

11. Миңнуллин К.М. Һәр чорның үз җыры / К.М. Миңнуллин. – Казан: Мәгариф, 2003. – 400 б.

12. Мәхмүтов Х.Ш. Халык афоризмнары: икенче китап / Х.Ш. Мәхмүтов. – Казан: Мәгариф, 2002. – 191 б.

**Ф.Б. ИБРАҺИМОВА**

*Бөгелмә районы, Мостафа Өнҗәл исемендәге лицей-интернат, Россия*

## ТАТАР ҺӘМ ТӨРЕК ТЕЛЛӘРЕНДӘ СЫЙФАТ ДӘРӘҖӘЛӘРЕ

**Аннотация**. В данной статье рассматриваются степени прилагательных в татарском и турецком языках. Мы рассмотрели особенности степеней прилагательных в татарском языке и выделили сходства и различия с турецким языком. За основу статьи был взят материал из книги Ф.М. Хисамовой «Морфология татарского языка». Татарский и турецкий языки входят в одну языковую семью. В этих языках много общего. Прилагательное – одно из самых часто используемых частей речи, и мы поставили перед собой задачу изучить сравнительную, превосходную, уменьшительную степень.

**Abstract**. This article examines the degrees of adjectives in the Tatar and Turkish languages. We examined the features of the adjectives degrees in the Tatar language and highlighted the similarities and differences with the Turkish language. The article was based on material from the book by F.M. Khisamova "Morphology of the Tatar language". Tatar and Turkish languages belong to the same language family. These languages have a lot in common. The adjective is one of

the most frequently used parts of speech, and we set ourselves the task of studying the comparative, superlative, diminutive degree.

**Ключевые слова**: татарский язык, турецкий язык, морфология, прилагательное, степени сравнения, сравнительная степень, превосходная степень, уменьшительная степень.

**Key words**: Tatar language, Turkish language, morphology, adjective, comparative degree, superlative degree, diminutive degree.

Татар һәм төрек телләре – кардәш телләр. Аларның грамматик структураларында охшаш һәм аермалы яклар да бар. Сыйфат – сөйләмдә киң кулланыла торган сүз төркеме. Чит телне камил рәвештә белергә теләсәң, ул телнең грамматикасын да яхшы үзләштерергә тиешсең. Шул максаттан чыгып, без эзләнү эшебездә татар һәм төрек телләрнең үзенчәлекләрен истә тотып, сыйфат дәрәҗәләрен чагыштырып өйрәнергә үзебезгә максат куйдык.

Ф.М. Хисамова үзенең "Татар теле морфологиясе" китабында сыйфатка шундый аңлатма бирә: лексик – семантик мәгънәсе буенча сыйфат предмет билгесен белдерә. Яңа кием, кояшлы көн һ.б. Морфологик яктан сыйфат – төрләнми торган сүз төркеме. Аңа бары тик дәрәҗә категориясе генә хас.

Татар телендә дәрәҗә категориясе, башка төрки телләрдә кебек үк, билге чамасының һәртөрле үзгәрешен – уртача дәрәҗәсен, билгенең чагыштырмача артыграк яки уртача дәрәҗәдән кимрәк булуын, иң югары дәрәҗәсен, чиген белдерә. Татар телендә сыйфатларның дүрт дәрәҗәсе аерып өйрәнелә: гади дәрәҗә, чагыштыру дәрәҗәсе, артыклык дәрәҗәсе, кимлек дәрәҗәсе.

Төрек телендә исә Sıfat (Ön ad) сыйфат исемне ачыклап килгән сүз төркеме итеп билгеләнә. Төрек телендә дүрт сыйфат дәрәҗәсе билгеле:

1. Eşitlik derecesi (тигезлек дәрәҗәсе)
2. Üstünlük (karşılaştırma) derecesi (чагыштыру дәрәҗәсе)
3. Aşırılık Derecesi (артыклык дәрәҗәсе)
4. En üstünlük derecesi (өстенлек дәрәҗәсе)

Гади дәрәҗә. Сыйфат, бернинди өстәмә кушымча алмаган хәлдә, төп дәрәҗәдә була. Ул билге чамасының уртача бер халәтен (нормасын) белдерә: суык, җылы, кызыл, яшел һ.б

Төрек телендә дә төп юнәлеш кушымчасыз кулланыла. Мәсәлән, geniş yol (киң юл).

Татар телендә чагыштыру дәрәҗәсе предметтагы билгенең уртача дәрәҗәдән артыграк булуын белдерә: матуррак, җитезрәк, зуррак һ.б. Чагыштыру дәрәҗәсе сыйфат нигезендә -рак/-рәк кушымчасы ялганып ясала һәм контекстта чагыштырыла торган икенче бер предмет (шәхес) була, яки ул сүз

сөрешеннән аңлашыла: Агыйделдән киңрәк, диңгездән көчлерәк, аңардан яшьрәк һ.б.

Төрек телендә сыйфатларның чагыштыру дәрәҗәләре исемнәрнең билге дәрәҗәсен чагыштыру өчен сыйфат алдыннан daha (тагын да) сүзе ярдәмендә ясала. Мәсәлән: akıllı – akıllı öğrenci – **daha** akıllı öğrenci

Шулай ук сүзтезмәдә затны, предметны белдергән сыйфатланмышның чыгыш килешендә белдерелүе. Uçak tren**den** hızlıdır (Очкыч поездан тизрәк).

Татар телендә сыйфатларның артыклык дәрәҗәсе билгенең иң югары дәрәҗәсен, чиген белдерә. Артыклык дәрәҗәсендәге сыйфат предметлардагы билгене чагыштыру аша белдерә, мәсәлән, иң бәхетле (көн), иң яхшы (укучы), иң яңа (костюм); билгенең иң югар чиген чагыштырудан башка , абстракт рәвештә дә белдерергә мөмкин. Мәсәлән: дөм караңгы (төн), үтә усал (кеше), япа-ялгыз (хатын), тып-тын (урман) һ.б. Телебездә артыклык дәрәҗәсен белдерә торган универсаль чара булып иң кисәкчәсе санала, ул теләсә нинди сыйфат белән килә ала: иң яхшы, иң матур, иң зур, иң биек. Мисаллардан күренгәнчә, бу кисәкчә, нигезендә, артыклык дәрәҗәсен чагыштыру төсмере белән белдерә. Иң бөек максат безем: хөр мәмләкәт – хөр Русия! (Г.Тукай) Хәсрәтемнең иң ачысы син, әйе, син... (Ф.Яруллин)

Төрек телендә артыклык дәрәҗәсе **en** сүзе ярдәмендә ясала. Бу татар телендәге иң кисәкчәсесе белән берүк функцияне башкара (en-иң). Мәсәлән, Yaz **en** sıcak mevsimdir. (Җәй иң җылы ел фасылы). Төрек телендә сыйфатларның мәгънәләрен көчәйтү яки йомшарту өчен махсус ысул бар: әгәр дә асыл сыйфат сузык хәрефтән башланса, аңа мәгънәне көчәйтер өчен сүз башланган сузык аваз һәм m, p, r, s тартыкларының берсе ялгана. Әгәр сүз тартык хәрефтән башланса, префикс сүзнең беренче ике хәрефеннән һәм m, p, r, s хәрефләреннән барлыкка килә.Мәсәлән: beyaz – **bem**beyaz. Кайбер сыйфатлар бу кагыйдәгә буйсынмыйлар, ләкин көчәйтү дәрәҗәсен башка юл белән алалар. Мәсәлән: yanlız–yapayanlız, sağlam–sapasağlam. Төрек телендә сыйфатның көчәйтү дәрәҗәсе сүзне кабатлау ысулы белән дә барлыкка килә. Мәсәлән: yüce yüce dağlar (зур зур таулар), mini mini eller (кеп-кечкенә куллар).

Татар телендә кимлек дәрәҗәсе предметтагы билгенең уртача дәрәҗәдән кимрәк булуына күрсәтә. Мондый мәгънә төс белдерүче сыйфатларда морфологик юл белән, ягъни махсус кушымчалар ярдәмендә белдерелә. Мәсәлән: күк- күг-елҗем, күк- күк-сел; ак- ак-сыл, ал-ал-су, зәңгәр-зәңгәр-су; кайбер сыйфатларда нигез кыскара: яшел- яшь-келт, кызыл- кыз-гылт, сары- сар-гылт; -кылтым/-келтем кушымчасы күбрәк тәм белдергән сыйфатларга ялгана: әче-

әч-келтем, төче-төч-келтем. Эчкәрәк кергән саен, әрәмәлек каера барды, кызарып җитмәгән баланнар, саргылт яшел миләшләр ешрак очрады.

Төрек телендә сыйфатларның мәгънәләрен кечерәйтү (Sıfatlarda Küçültme (Anlam Daralması) күренеше дә бар. Сыйфатларның мәгънәләрен кечерәйтү өчен аффикслар рәте кулланыла.Ул рәткә –ce, -cik, -ımsı, -ımtrak дигән аффикслар керә. Мәсәлән: kısa**cık** yol(кечкенә генә юл).

Йомгак ясап шуны әйтәсе килә, без татар теленең «Сыйфат дәрәҗәләре» һәм төрек теленең «Sıfat dereceleri» категориясен тикшердек. Тугандаш халык теле булган татар һәм төрек телендәге сыйфат дәрәҗәләре арасында уртак яклар бик күп дигән нәтиҗәгә килдек.

**ӘДӘБИЯТ**

1. Эйюп Гениш. Грамматика турецкого языка. Том 1 / Гениш Эйюп. – М.: ЛКИ, 2008. – 232 с.

2. Сафиуллина Ф.С. Хәзерге татар әдәби теле: Югары һәм урта уку йортлары өчен дәреслек. – Тулыл. 2 басма / Ф.С. Сафиуллина, М.З. Зәкиев. – Казан: Мәгариф, 2002. – 407 б.

3. Хисамова Ф.М. Татар теле морфологиясе: Югары уку йортлары өчен дәреслек / Ф.М. Хисамова. – Казан: Мәгариф, 2006. – 335 б.

4. Щека Ю.В. Практическая грамматика турецкого языка / Ю.В. Щека. – М:АСТ: Восток-Запад, 2007. – 666 с.

**Э.И. ИБРАҺИМОВА**

*Казан федераль университеты, Россия*

## ТУГАН ТЕЛ ДӘРЕСЛЕКЛӘРЕНДӘ СӨЙЛӘМ ТЕЛЕ ЛЕКСИКАСЫНЫҢ БИРЕЛЕШЕ

**Аннотация.** Работа над развитием татарской разговорной речи ведется систематически от начальной школы до старших классов. В статье предлагается краткий обзор изучения лексики разговорной речи в учебниках родного языка, а также приводятся предложения для разнообразия коммуникативных ситуаций на уроках татарского языка.

**Abstract.** Work on the development of Tatar colloquial speech is carried out systematically from elementary school to high school. The article offers a brief overview of the study of the vocabulary of colloquial speech in textbooks of the native language, and also provides suggestions for the variety of communicative situations in the lessons of the Tatar language.

**Ключевые слова:** татарская разговорная речь, повседневная лексика, учебник.

**Key words:** Tatar colloquial speech, everyday vocabulary, textbook.

Сөйләм теле кешелек җәмгыятендә гаять әһәмиятле урын били. Аның төп вазифасы – кешеләрнең көндәлек аралашуын тәэмин итү. Кодификацияләнгән

әдәби телдән аермалы буларак, ул барлыккка килүе һәм кулланылышы ягыннан беренчел санала. Телдә барлыкка килгән үзгәреш, беренче чиратта, сөйләм телендә урын алуы билгеле [1, б. 28–29]. Кешеләр сөйләм ярдәмендә үзләренең уй-хисләрен җиткерәләр, аралашалар, аңлашалар. Акыл үсешендә сөйләм бик мөһим урын тота. Сөйләм теле, әдәби нормаларның тиешенчә сакланмавы һәм гомумкулланылыштагы сүзләрнең күп булуыннан тыш, үз эченә иҗтимагый һәм территориаль диалектларны, гади сөйләм элементларын алу белән аерылып тора [1, б. 29].

Аралашуның гадәти шартларында әзерлексез башкарылган, стильара лексикадан бераз түбән стильдә саналган сүзләр сөйләм теле лексикасын тәшкил итәләр. Тикшеренүләр раславынча, сөйләм телендә эмоциональ фактор төп рольне уйный. Шуңа бәйле, рәвештә күпчелек хезмәтләрдә сөйләм теленең эмотивлыгын тикшерү зур урын ала. Моның белән беррәттән, рациональлек тә төп сыйфат буларак атала.

Татар сөйләм телен үстерү өстендә эш башлангыч мәктәптән алып иң югары сыйныфка кадәр системалы рәвештә алып барыла. Татар телен укыту – аралашу чарасы, шулай ук укучыларны рухи һәм әхлакый яктан тәрбияләү, аларның аралашу культурасын формалаштыру ысулы да.

Дәреслекләрдә аралашу ситуацияләренә караган көндәлек лексиканы өйрәнү үзенчәлекләрен ачыклау өчен эшебездә рус мәктәпләренең татар төркемнәрендә белем алучыларга атап төзелгән дәреслекләр анализланды. Күзәтүебез шуны күрсәтте: Р.К.Сәгъдиева авторлыгындагы дәреслекләрдә аралашу ситуацияләрен тасвирлаган текстлар шактый еш тәкъдим ителә, әмма аларда биремнәрнең тәкъдим ителүендә бертөрлелек күзәтелә.

Бирем, гадәттә, түбәндәгедән гыйбарәт: “Укы, партадашыңа текст белән бәйле сораулар бир. Ул җавап бирсен. Рольләрне алмашырга онытмагыз”. Сирәгрәк очракта аерым сүзләрнең рус теленә тәрҗемәсе бирелә, кайбер очракларда бу сүзләр арасында гади сөйләм лексикасы да урын ала. Мәсәлән, җиденче сыйныфта “Батыр Хәбир” тексты нигезендә эшләгәннән соң, укучыларга *мыштым гына – исподтишка, незаметно* сүзенең мәгънәсенә тәрҗемә аша төшенәләр [5, б.187]. Шушы ук сыйныфта “Коймадагы кояш” тексты белән эшләгәннән соң *шапырынырга – хвастаться, каңгылдык – кричащий* сүзләренең мәгънәсенә тәрҗемә аша төшенәләр [5, б. 197].

Укучыларның аралашу ситуацияләре гадәттә мәктәп, гаилә, яшьтәшләр белән чикләнә. Шул ук автор җитәкчелегендәге дәреслектә гаилә аралашуы ситуациясенә караган кызыклы күнегү тугызынчы сыйныф укучыларына тәкъдим ителә: “Диалогны гади сөйләм теленә туры килерлек итеп үзгәртеп сөйләшегез”

[4, б. 97]. Укучыларга сүзлек белән эш тә тәкъдим ителә: “Татар теленең аңлатмалы сүзлеге”ндә гади сөйләм шартлы билге белән күрсәтелгән. Шуннан ун сүз сайлап ал һәм, аларны кулланып, сөйләмә стильгә караган текст төзе” [4, б. 97]. Әлеге эшне парларда башкару, безнең фикеребезчә, тагын да уңышлырак булыр иде. Укучылар, беренчедән, кирәкле сүзләрне тизрәк табачаклар, икенчедән, сөйләм сүзләрен гадәти шартларда – аралашу ситуациясендә кулланып, диалог төзи алалар.

Эшебездә Ф.Ф. Харисов редакциясендәге дәреслекләр дә тикшерелде. Алар да татар төркемнәрендә укучыларга атап язылса да, гади сөйләм лексикасының аралашу ситуацияләрендә өйрәнелү очраклары юк диярлек. Алда без Р.К. Сәгъдиева укыту-методик комплексы буенча төзелгән тугызынчы сыйныф дәреслегеннән мисаллар китергән идек. Ф.Ф. Харисов редакциясендә текстларда мондый мисаллар теркәлмәде, әмма укучыларның үзләренә төрле аралашу ситуацияләре тәкъдим ителә. Мәсәлән: “Казанның тарихи һәм истәлекле урыннары турында сөйләшү үткәрегез” [2, б.27].

Күренгәнчә, дәреслекләрдә сөйләм лесикасы түбәндәге юл белән өйрәнелә: рус теленә тәрҗемә аша мәгънәсен аңлату, гали сөйләм лексикасы кергән тектсларны уку, сүзлек белән эшләү, диалоглар кору.

Сөйләм теле лексикасын өйрәнүдә дәреслекләрдә аралашу ситуацияләренең төрлелеге һәм күләме җитенкерәми дигән нәтиҗә ясау безне аерым тәкъдимнәр кертүгә этәрде.

Беренчедән, сөйләм теле лексикасын китап теле яки башка төр лексика белән чагыштырма аспектта өйрәнү. Билгеле булганча, чагыштыру эзләнүтикшеренү күнекмәләренең берсе һәм әһәмиятлесе булып тора. Димәк, түбәндә тәкъдим ителәчәк бирем Федераль дәүләт белем бирү стандартлары таләпләренә дә җавап бирәчәк. Бирем түбәндәгечә яңгырый ала:

Текстны укыгыз. Текстның беренче һәм икенче өлешендә тасвирланган аралашу арасында аерма бармы? Коммуникантлар булып шул ук геройлар торамы, башкалармы? Аларның лексикасындагы аермалыклар нәрсә белән аңлатыла?

Уңышлы текст буларак Алмаз Гыймадиевның “Актерлар” хикәясе тәкъдим ителергә мөмкин.

Хикәядә җиденче сыйныф укучылары Фәрит белән Айсылуның мәктәптән өйгә кайтулары вакытындагы сөйләшүләре үзәккә алына. Биремнең уңышлы ягын ассызыклап китик: укучылар аралашуның бер үк кешеләр – сыйныфташлар Фәрит белән Айсылу арасында баруына ассызыклыйлар. Аларның беренче диалогын анализлап, анда сөйләм сүзләре урын алмаган булуын,

диалогның югары стильгә тартым булуын дәлиллиләр. Икенче очракта түбәндәге сөйләм сүзләрен табарга тиеш булалар: энем, вәссәлам. Укучылар аңлатма биреп китәләр: диалоглар арасындагы мондый төрлелек, хәтта капма-каршылык шуның белән аңлатыла: беренче диалог – Фәрит белән Айсылуның спектакль репетицияләре, алар ике гашыйк ролен кабатлыйлар, ә икенче аралашу ситуациясендә Айсылу Фәриткә аннан талантлырак, акыллырак сыйныфташ кыз буларак мөрәҗәгать итә.

Икенчедән, дәреслекләрне анализлау күрсәткәнчә, аларда аралашу ситуацияләре макроситуация күләмендә бирелә. Бер-ике репликадан торган микроситуацияләр рус балалары белән эшләгәндә урын алса да, татар төркемнәрендә сөйләм теле лексикасын өйрәнүдә кулланылмый дияргә була. Шуны истә тотып, мондый биремне тәкъдим итәбез.

Укыгыз. Диалогта сөйләм лексикасына караган сүзләр бармы? Фикерегезне дәлилләгез.

– Безнең як урманнарына да сугыл, тукран. Быел нарат, чыршы күркәләре бик уңды. Шулардан аваз итәрсең, кунак булырсың, – диде чукыр.

– Рәхмәт, сезнең урманга да килеп чыгармын әле (“Такылдавык тукран”)” [6, б.108].

Күтелгәнчә, укучылар беренче репликадагы *сугыл* сүзенә игътибар итәргә тиеш булалар, бу – башка функциональ стильләрдә дә синонимик парлары булган эш яки хәлне белдерә торган сөйләм теле сүзләре рәтендә карала торган сүз. Икенче төрле итеп аны *кил* дигән фигыль белән алмаштырып була, әмма *сугыл* вариантында эмоциональ-экспрессив төсмер ныграк сизелә.

Өченчедән, галимнәр ассызыклаганча, җирле сөйләм, гадәттә, персонаж телендә ишетелә, аның кайсы тарафтан булуын, тел культурасын тойдырырга, типиклаштырырга, индивидуальләштерергә булыша. Әмма дәреслекләрдә мондый лексика аралашу ситуацияләрендә бөтенләй дип әйтерлек тәкъдим ителми. Шуны истә тотып, мондый биремне тәкъдим итәбез.

Ассызыкланган сүзләргә тасвирлама бирегез. Сезнеңчә, әдәби әсәрдә алар нинди максат белән кулланылган?

– Бәрәч, техничканы күрмәдеңмени? (“Фронтовиклар”) [3, б.277].

Укучылар иң элек беренче сүзгә игътибар итәләр. Авырлык туган очракта, “Татар теленең зур диалектологик сүзлеге”нә мөрәҗәгать итеп, аңа тасвирлама бирәләр. Гаҗәпләнү хисен шушы ымлык аша белдереп, язучы авыл җирлегендә табигый, ясалма яңгырмаган сөйләшүгә ирешә, әсәрнең ышандыру көчен арттыра.

Икенче сүзгә килгәндә, *техничка* дип мәктәптәге җыештыручыны атыйлар, мондый кыска әйтелеш телнең экономияләү принцибына туры килә, әсәрдә гади сөйләм, гади аралашу атмосферасын тудыруга хезмәт итә.

Дүртенчедән, билгеле булганча, гади сөйләмдә, аралашу теге яки бу диалект, сөйләшне йөртүчеләр арасында барган очракта диалект сүзләре, шул исәптән фонетик диалектизмнар да очрый, мондый сүзләр әдәби телдәге сүздән авазлар составы белән аерыла. [ж] авазының [й] авазына тәңгәлләшүе нәтиҗәсендә хасил булган диалектизмнар кергән микроситуацияләргә нигезләнгән биремне тәкъдим итәбез.

Укыгыз. Аралашу ситуацияләрен фаразлагыз. Гади сөйләм лексикасына кайсы сүзләрне кертер идегез?

1. Йә, нигә җылыйсыз? – диде шлемлы кеше (“Бәхилләшү”) [3, б.71].

2. Йә, җүләрләнмә, анда ашарыңа кирәк булыр, – ди ул, пышылдап кына (“Бәхилләшү” ) [3, б.271].

Нәтиҗә ясап, шуны әйтергә кирәк: тәкъдимнәр дәреслектәге биремнәрне кабатламый, шуңа күрә өстәмә материал буларак укытучылар өчен кыйммәте бар, дип уйлыйбыз. Коммуникатив бурычны уңышлы хәл итү өчен, аралашу максаты һәм аның шартларына бәйле тел чараларын сайлау, укучыларның сөйләм телен үстерү хәзерге вакытта иң әһәмиятле мәсьәләләрдән санала.

## ӘДӘБИЯТ


1. Галиуллина Г.Р. Хәзерге татар сөйләм телендә лексик интерференция күренеше // Tatarica. – 2018. – № 1 (10). – 22–35 б.
2. Гайнуллина Г.Ф. Татар теле. Рус телендә урта гомуми белем бирү оешмалары өчен уку әсбабы (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен). 8 сыйныф / Г.Ф. Гайнуллина. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2015. – 182 б.
3. Мәһдиев М. Әсәрләр. Биш томда. 1т.: повесть, роман / М. Мәһдиев. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2009. – 480 б.
4. Сәгъдиева Р.К. Татар теле. Рус телендә урта гомуми белем бирү оешмалары өчен уку әсбабы (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен). 9 нчы сыйныф / Р.К. Сәгъдиева, Э.Х. Кадирова. – Казан: “Мәгариф-Вакыт” нәшрияты, 2017. – 143 б.
5. Сәгъдиева Р.К. Татар теле. Рус телендә урта гомуми белем бирү оешмалары өчен уку әсбабы (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен). 7 нче сыйныф / Р.К. Сәгъдиева, Г.Ф. Харисова. – Казан: “Мәгариф-Вакыт” нәшрияты, 2017. – 215 б.
6. Тәхау К. Өч әкият: балалар өчен әкиятләр / К. Тәхау – Казан: Татар. кит. нәшр., 2015. – 123 б.

**Р.К. КАМАЛЕТДИНОВА,**
*Лениногорск районы Зәй-Каратай төп гомуми белем бирү мәктәбе, Россия*

# СИСТЕМАЛЫ УКЫТУ ШАРТЛАРЫНДА ЗАМАН ТАЛӘПЛӘРЕНӘ ТУРЫ КИТЕРЕП, УКУЧЫЛАРНЫ РУХИ ЯКТАН ТӘРБИЯЛӘҮ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

**Аннотация.** В статье рассмотрены проблемы воспитания учащихся в условиях системного обучения.

**Ключевые слова:** средняя школа, воспитание, обучение

**Abstract.** The article deals with the problems of educating students in a systematic learning environment.

**Keywords:** secondary school, education, training.

Кешелек җәмгыяте һәрвакытта үз алдына игелекле максат, камиллеккә, матурлыкка ирешү максаты куеп яшәгән. Шул максатны гамәлгә ашыру нәтиҗәсендә кешеләрнең рухи дөньялары баеган, гүзәллекне күрә, аңлый һәм аны иҗат итүне чагылдыра торган сәнгать барлыкка килгән.

Кешеләрнең үзләрендә күркәм сыйфатлар тәрбияви мәдәнияткә, сәнгатькә ия булулары һәм, гомумән, тәртипле мул тормыш корулары тел дип атала торган гаҗәеп бер нәрсәдән башка мөмкин булмас иде. Тел ул – кешеләрне башка төр җан ияләреннән аерып тора торган могҗизалы бер күренеш. Ул – җәмгыятьне оештырып, кешеләрне үзара аралаштырып, аңлаштыра торган куәтле чара да, сәнгать әсәрләре иҗат итүнең әһәмиятле коралы да. Һәм, ниһаять, камил, дөрес, матур телнең үзен дә сәнгатьнең бер төре дип әйтеп булыр иде.

Милли әдәби тел дигән төшенчә астында бер конкрет мәгънәне телләр үсешенең бер этабы өчен характерлы философик-лингвистик категорияне – милләт телен күз алдында тотабыз.

Милли тел ул – милләт яшәешенең нигезе. Кеше һава суламыйча яши алмаган кебек, милләт телсез яши алмый. Телнең зәгыйфьләнә баруы – ул милләтнең юкка чыга баруының бер күрсәткече. Милләт ул – теле булган халык. Тел ул милләтнең иң беренче, иң әһәмиятле билгесе. Тел бетсә, ул телнең иясе булган халык та, милләт тә югала. Шуның өчен дә туган телен кадерләп саклау, үстерү, аның сафлыгы, матурлыгы өчен көрәшү – мәдәниятле, зыялы һәр кешенең бурычы. Матур әдәбият эстетик төркемгә керүче предметларның берсе. Музыка, рәсем сәнгате белән янәшә сүз сәнгате – әдәбият укытыла.

Әдәбият укытуның төп бурычларының берсе булып укучыларда милли рух, үз халкына, сәнгатенә, тарихына, мәдәниятенә ихтирам, горурлык хисләрен тәрбияләү тора.

Танылган әдип һәм фикер иясе Фатих Әмирхан 1910 нчы елда “Үз милләтеңне кирәгенчә сөяр һәм аның рухын аңларга, аның халәте руханиятендәге бик нечкә музыка тамырларын чиртеп, шуларның чыгарган тавышларын тыңлый белергә кирәктер. Шул вакытта гына кабык астына төренгән куж руханияне (рухи көчне) яратырга мөмкин буладыр. Бер кавемнең мәдәниятен, рухын аңлау фәкать аның әдәбияты аркылы гына мөмкиндер” дип язган иде. Олы методист Г. Ибраһимов исә татар әдәбиятының асыл бурычларыннан берсе “милли рухта, культурада тәрбияләү, үз халкының улы ясау” дип күрсәтте.

Әдәбият үзенә халыкның зирәк акылын, тәҗрибәсен, сәләтен, рухи хәзинәләрен, хыял – өметләрен, дөньяга карашын һәм тормышны аңлавын, яшәү рәвешен – барысын да җыйнап килгән. Шушы байлыкны күрсәтә белү, балаларда үз милләтенең мәдәнияте белән горурлану,аңа соклану аркылы алып барылырга тиеш. Әдәбият дәресләрендә бу бурычның алга чыгуы туган телгә, милли тарихка, сәнгатькә, милләткә мәхәббәт тәрбияләү дигән сүз дә. Ул әдәби әсәрләрдә чагылган милли үзенчәлекләргә, сыйфатларга, милләткә хас йола,гореф-гадәтләргә, яшәү рәвеше белән бәйле төшенчәләргә баланың игътибарын юнәлтүдән башлана. Үз халкыңның улы яки кызы булу өчен аның традицияләрен,гореф-гадәтләрен, җыр-моңнарын, күп гасырлы тарихын, әхлак, тәрбия-тәртипләрен ана сөте белән сеңдереп үсү кирәк.

Борын-борын заманнарда, әле язу барлыкка килгәнче үк, сәләтле кешеләр төрле мәкаль-әйтемнәр, җыр-бәетләр, әкиятләр чыгарганнар.Алар телдән-телгә күчеп, әдәби яктан камилләшкәннәр, шомарганнар һәм халыкның рухи хәзинәсенә әйләнгәннәр. Халык иҗаты әсәрләре халыкның тормышын, көнкүрешен, киләчәк турындагы якты хыялларын, туган илгә тирән мәхәббәтен чагылдыра. “Халык иҗатын белми торып, хезмәт халкының чын тарихын белеп булмый”, – дигән бөек әдип М.Горький.

Халык иҗатын өйрәнү бик әһәмиятле. Ул яшь буынның зиһенен баета, дөньяга карашын киңәйтә, тел байлыгын һәм белемне үстерә, рухи яктан формалаштыруга ярдәм итә.

Шуңа күрә мин үз алдыма әдәби уку,әдәбият дәресләрендә татар халык авыз иҗатын өйрәнүне һәм шуның нәтиҗәсендә балаларда туган телгә мәхәббәт, милли тарихка, сәнгатькә, милләткә мәхәббәт тәрбияләүне бурыч итеп куйдым.

Бөек шагыйребез Г.Тукай халык авыз иҗатына зур бәя биргән. “Халык җырлары – безнең бабаларыбыз тарафыннан калдырылган иң кадерле вә иң бәхетле бер мирастыр”, – дигән ул.

Җыр – халыкның иң киң таралган, иң хөрмәтле иҗат җимеше. Ул халык тормышының чагылышы, кеше күңелендәге хисләрнең матур яңгырашы, яктыртылышы да. Халкыбыз иҗатының сихерле көзгесенә бер карасаң, татар халык җырларының моңын күңелең белән тойсаң, милли уен- биюләрен күрсәң, бу көзгедән тиз генә аерылам димә.Язма барлыкка килгәнче, халыкның төп рухи чыганагы – шигъри сүз булган. Халык аны көйгә салган, батырларга дан җырлаган.

Әдәбият дәресләрендә шагыйрьнең шигыренә көй язылган икән, укучыларга кайбер җырларны җырлап күрсәтәм, бик авыр булмаганнарын бергәләп өйрәнәбез. Мәсәлән, Г. Тукайның “Туган тел”е, “Туган авыл”ы, М. Җәлилнең “Җырларым”, Г. Бәшировның “Җидегән чишмә”се ,Ф. Яруллинның “Иң гүзәл кеше икәнсез” һ.б. Төрле сыйныфтан тыш эшләр үткәргәндә дә мин халкыбызның моңлы җырларын, бәетләрен укучыларга җиткерергә тырышам. Аларны төрле аудио, видео, презентацияләр ярдәмендә кулланабыз, үзебез дә төзибез.

Татар хатын-кызларының кулыннан һичбервакыт эш төшмәгән. Җеп эрләгән, шәл бәйләгән ул, ашъяулык, сөлге чиккән, тула баскан, келәм, палас тукыган. Халкыбыз элек-электән төрле әйберләргә бизәкләр төшерү белән шөгыльләнгән.

Безнең милли үрнәкләребездә илаһи бер олылык, кеше хисләрен табигатькә, урман-кырларга, бормалы инеш-суларга, зәңгәрсу-яшел талтирәкләргә, алсу-кызыл гөлләргә юллаучы ниндидер бер сихри көч бар сыман.

Минемчә, бу бизәкләргә халкыбызның җыр, бәет һәм матурлык турындагы уй-хыяллары, якты хисләре салынган. Халкым тегү-чигүгә бик оста булган, шуңа күрә бизәкләрендә нәрсә генә юк. Аларда табигатьнең яшәү сулышы тасвирлана. Бизәкләр бер-берсен кабатламый, анда төрле җепләр кулланылган.

Әдәбият дәресләрендә мин милли үрнәкләр турында сөйлим, рәсемнәрен күрсәтәм. Хезмәт дәресләрендә безнең кызларыбыз кулъяулыклар, сөлгеләр, алъяпкычлар чигә, һәм чигү үрнәкләре итеп татар орнаментларын алалар. Татар бизәкләрен чигү аларга бик ошый!

Моннан тыш әдәбият дәресләрендә мин укучыларга татар халык ашлары турында сөйлим. Төрле рецептлар язабыз,ничек пешерергә икәнен аңлатам. Аннары каникул вакытларында түгәрәк өстәл артына чәй эчәргә җыелабыз. Һәм менә шунда инде кайсы укучының нәрсәгә сәләтле икәне күренә. Һәрбер укучы чәй табынына үзе пешергән ризыкны алып килә, шул ризык турында бел-

гәннәрен сөйли. Аннан соң бергәләп утырып чәй эчәбез. Чәйдән соң үзебезнең татар халык җырларын җырлыйбыз һәм татар биюләрен башкарабыз. Кичәдән һәркем канәгать булып, күңел күтәренкелеге алып өйләренә тарала.

Бишек җыры… анда газиз әниләрнең өметләре, ышанычлары, баласын рухи һәм физик яктан матур, игелекле, мәрхәмәтле, гадел итеп күрү теләге. Аналарның йөрәк түреннән чыккан моң чишмәсе- бишек җырларының төп вазыйфасы – бишек тирбәтү, баланы тынычландыру, йоклату.

Бишек җырлары бишек янына утырып та, баланы кулга тоткан килеш тә башкарыла. Әлеге җырлар аша сабый тәүге мәртәбә матурлык, ананың йөрәк җылысы, ата-ана мәхәббәте, үз халкының рухи, аһәңле теле белән, туган йорт, туган туфрак төшенчәләре белән очраша. Әдәбият дәресләрендә мин укучыларга бишек җырының күп вариантларын тәкъдим итәм, үзем дә башкарам. Ә арадан берсен – иң ошаганын бергәләп өйрәнәбез.

Кыз бала чибәр, зифа буйлы, акыллы булып үссен дә йөз кеше арасыннан бер генә кешегә насыйп булсын, ә ир бала исә батыр, кыю, якыннарына ышаныч, таяныч булып буй җитсен дип теләүләр халыкның биләүдә чакта ук балада әхлакый сыйфатлар, җаваплылык хисләре тәрбияли башлавы дип аңлашыла.Һәм менә бу без өйрәнгән бишек җырлары укучыларның рухи хәзинәсен баета дип уйлыйм мин.

Безнең мәктәп укытучылары язучылар һәм шагыйрьләр белән төрле очрашулар, конференция,семинарлар үткәрәбез. Мәсәлән, Факил Сафин, Алмаз Хәмзин, якташыбыз Альберт Хәсәнов,Таһир Шәмсуаров, авылдашларыбыз Әнвәр ага Шәрипов, Халисә апа Ширмәни,Туйкиннар нәселеннән Марат Нур улы Туйкин, тарихчы Альберт Әхмәтҗан улы Борһанов һ.б. белән булган очрашулар укытучыларның да, укучыларның да күңелләрендә тирән эз калдырды.Бу очрашулар һәрдаим район,республика күләмендәге газета журнал битләрендә урын алып басылып чыктылар.

Уку-укыту вакытында әдәплелек дәресләре үткәрүгә дә зур игътибар бирелә. Бу дәресләрдә без ата-анага булган кадер-хөрмәт, икмәккә хөрмәт, шәфкатьлелек, әдәплелек турында күп сөйләшәбез, фикер алышабыз. Бу дәресләргә әзерлекне мин инша яздырудан башлыйм. Ә инша язу өчен, билгеле, аларга бик күп эзләнергә, логик фикер йөртергә кирәк. Иншаларында халык авыз иҗаты әсәрләрен файдалануны бурыч итеп куям. Бүгенге көндә татар телендә чыгучы газета-журналларыбыз, җитәрлек. Алар белән интернет челтәрендә дә танышырга, укып кулланырга була. “Акчарлак”, “Юлдаш”, ”Көмеш кыңгырау”, районыбызның “Заман сулышы” газеталарында, “Ялкын” журналы әдәп-әхлак темасына бик күп мәкаләләр басыла. Менә шушы мәкаләләрне әдәбият

дәресләрендә урынлы файдалану үзенең нәтиҗәләрен бирә. Укучыларыбызның күбесе бу газета-журналларга язылды. Укыган мәкаләләре буенча үзләренең фикерләрен әйтергә өйрәнәләр,төрле шигырьләр,әкият,мәкаләләр дә язып карыйлар һәм төрле бәйгеләрдә катнашып призлы урыннар да алалар. Бу үткәрелгән әдәплелек дәресләре укучыларны рухи яктан формалаштыруга зур йогынты ясый. Бүгенге чор укучыларын рухи яктан тәрбияләү өчен әдәбият дәресләре зур этәргеч булып тора һәм нәтиҗәләре дә күз алдында.

**Д.И.КАМАЛОВА**

*Казан федераль университеты, Россия*

## В.Х. ХАКОВНЫҢ СТИЛИСТИКА ӨЛКӘСЕНДӘГЕ ЭШЧӘНЛЕГЕ

**Аннотация.** В данной статьи рассматриваются работы В.Хакова о татарской стилистике. Исследователь считается одним из основоположников татарской стилистики. В своих работах В.Хаков выделяет общественно-публицистический, научно-популярный литературный, официально-канцелярский и эпистолярный стили. Также автор изучал стили по «вертикали» и выделил высокий, средний и нижний стили.

**Abstract.** This article discusses the works of V.Khakov on the Tatar style. The researcher is considered one of the founders of the Tatar style. In his works, V.Khakov distinguishes social-journalistic, popular science literary, official-clerical and epistolary styles. Also, the author studied styles on the "vertical" and highlighted the high, middle and lower styles.

**Ключевые слова:** стилистика, функциональные стили, общественно-публицистический стиль, научно-популярный литературный стиль, официально-канцелярский стиль, эпистолярный стиль.

**Key words:** stylistics, functional styles, social and journalistic style, popular science literary style, official-clerical style, epistolary style.

Вахит Хөҗҗәт улы Хаков фәнни тикшеренүләр алып барган зур юнәлеш – татар теле стилистикасы. Ул – стилистика тарихына нигез салган галимнәрнең берсе. “Тел һәм стиль мәсьәләләре” (1961), “Татар теле стилистикасына кереш” (1963), “Матур әдәбият тел стиле” (1967), “Стилистика һәм сүз сәнгате” (1979), “Татар әдәби теле. Стилистика” (1999) хезмәтләрендә В.Х. Хаков беренче мәртәбә функциональ стильләрне системалы рәвештә өйрәнү эшчәнлеген башлап җибәрә.

В. Хаков фикеренчә, “стилистика – сүзләрнең мәгънә үзгәрешләре һәм сөйләм төзелеше белән бәйләнешле фән. Ул тел чараларының һәм сәнгатьчә сурәтләү алымнарының бер максатка ярашлы рәвештә кулланылу һәм алардан нәтиҗәле итеп файдалана белү юлларын өйрәнә. Тел фәненең бу тармагы

телдәге стильләрне, аларга хас үзенчәлекләрне, сөйләмнең сәнгатьчә чараларын, сүзлек хәзинәсендәге мәгънә үзгәрешләрен, фонетик, морфологик һәм синтаксис категорияләргә караган стиль күренешләрен үз эченә ала. Теге яки бу стильгә карап, сүзләрнең, әйтелмәләрнең, грамматик формаларның мәгънә үзгәлешләре барлыкка килә. Мондый үзгәрешләрнең стилистик категорияләр һәм телнең тарихи үсеше, андагы күренешләрнең эволюциясе белән турыдан-туры бәйле” [3, б.7].

1961 нче елда басылып чыккан “Тел һәм стиль мәсьәләләре” китабында автор стильләргә гомуми тукталып китсә дә (“Стильләр турында төшенчә”, “Татар әдәби телендә стильләрнең өйрәнелү дәрәҗәсе” темалары), публицистик стильне җентекләп өйрәнә. Шул уңайдан галим әлеге стильгә караган лексиканы “иҗтимагый-политик лексика” дип атый һәм публицистик стильне өйрәнү барышында тарихи-лингвистик классификацияне тикшерүгә зур урын бирә. Галим XX гасыр башында зур үсешкә ирешкән публицистик стильне җентекләп тикшерә. “Урал”, “Фикер”, “Әл-ислах”, “Казан мөхбире” газеталарын, “Яшен”, “Ялт-йолт”, “Карчыга”, “Чүкеч” журналларын, 1903-1907 нче елларда басылып чыккан прокламацияләрне, Г.Тукай, Ф.Әмирхан, Г.Камал, Г.Коләхмәтов, Ш.Мөхәммәдов әсәрләрен тел-стиль ягыннан тикшереп, автор публицистик стильдә сүзләрнең, төрле тәгъбирләрнең, фразеологик берәмлекләрнең кулланылышын, җөмлә төзелешендәге үзенчәлекләрне, сатираның тел-стиль алымнарын, аерым алганда, сүз уйнату, пародия, оксюморон, ирония кебек алымнарны, сурәтләү чараларын тикшерүгә зур урын бирә.

1963 нче елда галимнең “Татар теле стилистикасына кереш” хезмәте дөнья күрә. Китапта стильләр турында төшенчә, татар телендә стильләрне өйрәнү тарихына игътибар ителә. Галим иҗтимагый-публицистик стильдә сүзләрнең, төрле тәгъбирләрнең, фразеологик берәмлекләрнең кулланылышын, җөмлә төзелешендәге үзенчәлекләрне, стиль алымнарын, сәнгатьчә тасвирлау, сурәтләү чараларын өйрәнә. В.Хаков иҗтимагый-публицистик стильнең формалашу тарихын һәм формалашу шартларына да туктала. Әлеге монографиядә әдәби тел белән стильләр тарихының тыгыз бәйләнеше исбатлана. Автор һәр стильне татар әдәби теленең тарихи үсеше яссылыгында өйрәнә.

Галимнең 1971 елда Алма-Атада яклаган докторлык диссертациясенең исеме дә “Татар милли әдәби теленең барлыкка килүе һәм аның стильләре үсеше” дип атала. Р. Фәйзуллин фикеренчә, “бу – әдәби телнең эволюциясен чагылдырган хезмәт” [1, б.367-368]. Билгеле, болай колачлау өчен тикшеренүчеләрдән телне һәр яктан: лексик, фонетик, грамматик һәм стилистик яктан тирән белү сорала. Бу хезмәттә темага комплекслы килү сакланса да, барыбер

аның үзәк өлеше әдәби тел тарихына һәм аның стильләренең дифференциация мәсьәләләренә багышланган.

Әдәби телнең формалашуы һәм үсеше аеруча катлаулы, озак вакыт аралыгы таләп итә торган процесслардан санала. Беренче чиратта, бу аның киңкырлы иҗтимагый күренеш булуы белән аңлатыла. Әдәби телнең төп үзенчәлекләреннән саналган язма традицияләр һәм нормалар белән бергә, аның төрле иҗтимагый өлкәләрдә кулланылуы нәтиҗәсендә барлыкка килгән функциональ-стилистик төрлелекне – ягъни әдәби телнең функциональ стильләрен аерым атап үтәргә кирәктер. В.Х. Хаков фикеренчә, "теге яки бу телдә функциональ стильләрнең булуы – тел үсешенең иң төп шартларыннан берсе булып тора" [4, б.110]. Алга таба галим болай дип тә өсти: "Функциональ стильләр, тулаем алганда, телне саклаучы, тотрыклы итүче һәм баетучы төп компонентлар булып торалар" [3, б.297].

В.Хаковның берничә хезмәтендә рәсми канцелярия, матур әдәбият стиле, иҗтимагый-публицистика стиле, фәнни стиль, эпистоляр-хатлар стиленең функциональ үзенчәлекләре татар милли әдәби теленең барлыкка килүе һәм үсеше аспектында тикшерелә.

Галим функциональ стильләрне тел стильләре дип саный. Ул татар әдәби телендә түбәндәге тел (функциональ) стильләрен аерылып чыгара:

– иҗтимагый-публицистик тел стиле;

– фәнни-популяр әдәби тел стиле;

– эш кәгазьләре (рәсми-канцелярия) стиле;

– хатлар (эпистоляр) стиль.

"Кайбер тел белгечләре матур әдәбият әсәрләрендәге тел үзенчәлекләрен дә функциональ стильләр рәтендә карый, әмма матур әдәбият әсрләренең телен башка стильләр белән бер рәткә куеп булмый. Ул функциональ сөйләм стильләренә караганда, бик киң һәм үзендә телдәге барлык стильләрнең дә үзенчәлекләрен чагылдыра" [3, б.10].

"Стильләрнең үсеше һәм нормалашып җитүе – милли әдәби телнең закончалыклы күренешләреннән берсе," – дип яза галим [2, б. 89].

Шулай ук В.Х. Хаков телләрне "вертикаль" яктан да төрләргә бүлә. Алар – югары, урта, түбән стильләр.

Галим фикеренчә, татар теленең өч стиле турында XIX гасыр азагында ук язылган.

В.Х. Хаков күзәтүенчә, өч стиль үзенчәлекләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

1. Югары стиль. Моңа күп очракларда китап теле, язма тел белән бәйләнешле үзенчәлекләр керә.

2. Урта стиль. Гадәттә, бу стиль телнең нейтраль үзенчәлекләрен үз эченә алу белән характерлана. Анда югары һәм халык стиле элементлары да шактый урын били.

3. Түбән стиль (халык стиле). Моңа халыкның җанлы сөйләме белән бәйләнешле тел үзенчәлекләре керә.[2, б. 112].

Татар телендә стильләр тарихын өйрәнгән В.Х. Хаков "Вакытлар үтү белән, әдәби телнең халык сөйләменә нигезләнүе югары стильнең югала баруына китерә" дигән нәтиҗә ясый. Татар милли әдәби теле формалашкан вакытта өч стиль үзенең элекке функциясен югалта, ди ул [2, б.112].

Галим фикеренчә, "телнең стилистик чараларын һәм аларның кулланылышын белү әһәмияятле мәсьәләләрнең берсе булып санала. Телдән һәр кеше үзенчә файдалана, аны үз сөйләменә яраклаштыра" [3, б.297].

Хезмәтләрендә татар теле фонетикасы, морфологиясенә һәм лексика өлкәләренә караган стилистик үзенчәлекләр тикшерелә. Казан университеты студентларына укытырга махсус багышлап язылган программалар, күнегүләр җыентыклары чыгара.

В.Х. Хаковның стилистика өлкәсенә караган хезмәтләре фонетик, лексик, грамматик (морфологик, синтаксик) стилистиканы өйрәнү ягыннан да әһәмиятле. Аларда галим телдәге лексик-фразеологик, фонетик һәм грамматик чаралардан дөрес, нәтиҗәле файдалану юлларын ачыклый.

Нәтиҗә ясап, шуны әйтергә була: В.В. Хаков теле белеменең тарихы һәм стилистикасы өлкәсендә аеруча зур хезмәтләр яза. Әмма ул китапларны бусы бу эшчәнлеккә, бусы бу эшчәнлеккә аерып карарга мөмкин түгел, чөнки алар икесе бергә бәйләнеп, бер-берсен тулыландырып баралар.

## ӘДӘБИЯТ


1. Фәйзуллин Р.Г. Сайланма әсәрләр: 6 т. 4 т.: Әдәби-публицистик мәкаләләр / Р.Г. Фәйзуллин. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2005. – 415 б.

2. Хаков В. Х. Татар әдәби теле тарихы / В.Х. Хаков. – Казан: Казан ун-ты нәшр., 1993. – 328 б.

3. Хаков В.Х. Татар әдәби теле (стилистика) / В.Х. Хаков.– Казан: Татар. кит. нәшр., 1999. – 304 б.

4. Хаков В.Х. Татар милли әдәби теленең барлыкка килүе һәм үсеше / В.Х. Хаков. – Казан, 1972. – 224 б.

**М.М. КНИСАРИНА, А.Т. СИСЕНОВА, Г.С. ЖУМАЛИЕВА**
*НАО «Западно-Казахстанский медицинский университет имени Марата Оспанова», Казахстан*

# ИЗУЧЕНИЕ ТРЕВОЖНОСТИ СТАРШЕКЛАССНИКОВ В УСЛОВИЯХ ПАНДЕМИИ COVID-19

**Аннотация.** В статье представлены результаты исследования тревожного состояния старшеклассников в связи с пандемией COVID-19. Тревожность, как негативное психологическое состояние, уточняется в новом понимании в чрезвычайных условиях. Зарубежные исследования определили повышенное тревожное состояние людей, прямую взаимосвязь повышения тревожности у старшеклассников от условий пандемии. По результатам диагностики («Шкала тревожности в связи с пандемией COVID-19») был определен высокий уровень тревожности у старшеклассников – 71% клинически выраженной тревоги, тем самым доказывая негативное воздействие пандемии на личностное состояние.

**Abstract.** The article presents the results of a study of the anxiety state of high school students in connection with the COVID-19 pandemic. Anxiety, as a negative psychological state, is clarified in a new understanding in emergency conditions. Foreign studies have identified an increased anxiety state of people, a direct relationship between increased anxiety in high school students and the conditions of the pandemic. According to the results of the diagnosis ("The scale of anxiety in connection with the COVID-19 pandemic"), a high level of anxiety was determined in high school students – 71% of clinically expressed anxiety, thereby proving the negative impact of the pandemic on the personal state.

**Ключевые слова**: старшеклассник, чрезвычайная ситуация, коронавирус SARS-CoV-2, пандемия COVID-19, тревожность, «личностная тревожность», «ситуативная тревожность» шкала тревожности.

**Key words:** high school student, emergency, SARS-CoV-2 coronavirus, COVID-19 pandemic, anxiety, "personal anxiety", "situational anxiety" anxiety scale.

Повсеместно наблюдаемые у людей разных стран мира повышение уровня тревоги, депрессии, растерянности, безысходности вполне объяснимы в связи с происходящими в последнее время неожиданными и серьезными ограничительными мероприятиями в попытке остановить распространение вируса COVID-19. Вспышка нового коронавируса SARS-CoV-2, официально названное COVID-19, привела к мировой пандемии, расселяющей повсеместно страх и тревогу среди людей.

В действительности страх перед пандемией распространяется быстро и глубоко, проявляясь от крайностей паранойи и насилия до ксенофобии, закрытых границ, экономических ограничений и социального дистанцирования. Страх пронизывая все слои общества, вызывает эмоциональное напряжение,

оказывающий на людей биологическое воздействие. Неуверенность порождает страх, а хронический страх – это токсический стресс [1, с.2].

Тревога, сигнализирующая человеку об опасности, все же дезорганизует его личности, вызывая необоснованную порой панику и/или в крайних случаях суицидальные мысли. Поэтому нынешняя опасность, вызывает неадекватное восприятие людьми происходящих вокруг событий и явлений, поскольку в роли стрессора выступает невидимая угроза – это страх заразиться общеизвестным вирусом, заболеть и умереть. Первые научные исследования были направлены на изучение психологических нарушений у людей в связи с распространением COVID-19, благодаря которым были определены все симптомы тревоги – посттравматическое стрессовое расстройство, депрессия, и бессонница.

Тревожное состояние усугубляет также и периодически появляющиеся неуверенность и сомнения в своевременном полноценном и качественном медицинском обслуживании. Называются следующие основные факторы, способствующие развитию негативных эмоциональных состояний у населения: недостаток защитных средств; проблемы с адекватным лечением; отсутствие необходимых лекарственных препаратов в аптеках; профессиональное выгорание медицинского персонала в связи с жесткими условиями работы во время пандемии и т.п. [2, с.1732; 3, с.1513].

Пандемия COVID-19 привела к введению карантинных мер в большинстве стран, тем самым инициируя серьезные психологические проблемы, включая посттравматическое стрессовое расстройство (ПТСР), особенно для уязвимых критически развивающихся детей и подростков. Безусловно, непосредственным психологическим откликом людей на карантинный режим в связи с пандемией COVID-19 являются тревога, неопределенность, страх, беспокойство, в целом формирующих стрессовую реакцию.

Актуальность данного исследования связана с изучением психосоциальных последствий пандемии, в числе которых пристальное внимание требует тревожность старшеклассников, вызванная страхом перед вирусом COVID-19. Особо важным и своевременным является изучать различные изменения психологического состояния старшеклассников в виду их особого статуса, этапа взросления и периода профессионально самоопределения, что требует со стороны окружающих пристальное внимание и заботливое отношение к ним, тем более в такой чрезвычайный период пандемии COVID-19.

Поэтому наша исследовательская цель заключена в изучении тревожности старшеклассников в условиях пандемии COVID-19.

Понятие «личностная тревожность», как устойчивая черта личности, уточняется в рамках исследования следующим образом - психоэмоциональное напряжение в ожидании угрозы, выраженное в виде беспокойства, чувство страха, мнительности, напряженности, преувеличении значимости воспринимаемой информации, ожидании опасности. «Ситуативная тревожность», как реакция индивидуума на конкретную ситуацию, связано с внутренними переживаниями старшеклассников перед сдачей выпускных экзаменов, неизвестностью своего будущего, обязательного выбора профессии и карантинными условиями в связи с пандемией COVID-19 и т.п.

Научно-методологической основой исследования является взаимосвязь тревожности с негативными видами самооценки, с невыгодными соотношениями уровней притязаний и самооценки личности по А.М. Прихожан.

В качестве валидного и надежного исследовательского инструмента выступает «Шкала тревожности в связи с пандемией COVID-19», составленной по аналогии с HADS. По инструкции предлагалось ответить, не задумываясь, на 20 утверждений по различным аспектам переживания респондентом ситуации распространения коронавирусной инфекции (COVID-19) и ее последствий. Полученные ответы не интерпретировались как правильные/неправильные.

Организация урока с использованием интерактивных технологий помогает всесторонне развивать учащихся. В процессе такого обучения учащиеся с младшего школьного возраста учатся критически мыслить, на основе анализа информации решать сложные проблемы, взвешивать различные мнения, дискутировать и, конечно же вступать в коммуникацию с другими людьми, что позволяет им адаптироваться, а далее социализироваться в обществе.

Рассматривая сущность, особенности интерактивных технологий следует отметить, что многие ученые, исследователи в состав функций интерактивных технологий обучения включают формирование предметных знаний, умений, навыков, развитие творческих способностей учащихся, создание психологического климата и его улучшение, развитие дружеских отношений и организация взаимопомощи в коллективе и др. В связи с этим не стоит забывать и социализирующей составляющей интерактивных технологий, под которой понимается формирование у обучающихся умений, качеств и способностей, которые способствуют самореализации человека в том обществе, в котором о развивается.

Здесь стоит рассматривать всестороннее развитие личности на протяжении всей жизненной пути во взаимодействии с окружающей средой в процессе усвоения и воспроизводства социальных норм и культурных ценностей, а также саморазвития и самореализации в том числе, к которому он принадлежит (Переломова Н.А., 2008: 23)

Развитие личности не самостоятельный процесс, оно не происходит без каких-либо воздействий. Мы знаем, что учащиеся в большей степени социализируются в рамках образовательных учреждений, так как именно они играют ведущую роль в этой области. Поэтому педагогам очень важно целесообразно подойти к выбору интерактивных технологий обучения, необходимо учитывать их социализирующий аспект. Здесь под этим понимается те стороны технологий, которые способствуют социализации личности и его развитии.

**ЛИТЕРАТУРА**

1. Григорьева В.Е. Стандарты второго поколения в начальной школе // Герценовские чтения. Начальное образование. – 2010. – Т. 1. – С. 152–156.
2. Шкуричева Н.А. Дружеские взаимоотношения младших школьников // Начальная школа. – 2010. – №11. – С. 6–8.
3. Бордовская Н.В. Современные образовательные технологии [Текст]: учеб. Пособие / Н.В. Бордовская, Н.В. Бродская, И.М. Дандарова. – М.: Кно Рус, 2011. – 432 с.
4. Инновационные методы преподавания в начальной школе / Л.С. Виситова // Образование и воспитание. – 2016. – С. 16–19.
5. Суворова Н. Интерактивное обучение: новые подходы // Учитель. – №1. – С. 25–27.

**Л.Г.ТАГИРОВА**
*Казан федераль университеты, Россия*

## Ф. ӘМИРХАН МИРАСЫ

Яңа бистә татар тарихында аерым урын алып торган. Монда бик күп мәшһүр шәхесләр яшәгән: Каюм Насыйри, Гаяз Исхакый, Фатих Әмирхан, Муса Җәлил, Салих Сәйдәшев. Бар дөньяга мәгълүм булган шагыйрь Габдулла Тукай исеме дә Яңа бистә белән бәйле Хәзерге вакытта Казан шәһәре җитәкчелегендә Яңа бистәне төзекләндерү планы карала. Без Яңа бистәнең тарихи йөзен саклап калу максатыннан, туган ягыбыз тарихын җентекләп өйрәнәбез, шуңа күрә алынган теманы актуаль дип саныйбыз.

Теманың өйрәнелү дәрәҗәсе: Яңа бистә, тарихчы Р.Фәхретдинов тарафыннан шактый өйрәнелсә дә, бистәнең Ф. Әмирхан белән бәйләнешенә бүген-

ге көндә игътибар итүчеләр аз. Әлеге хезмәтебездә сүз Әмирханнар нәселенең Яңа бистә тарихында гына түгел, ә XX гасыр башы татар җәмәгатьчелегендәге тоткан урыны турында бара.

Эзләнү-тикшеренү эшенең объекты: Яңа бистә һәм Әмирханнар нәселе, аларның йорты; тикшеренү предметы – Яңа бистә тормышына бәйләп, Ф.Әмирханны өйрәнү.

Эшенең максаты: Яңа бистәне төзекләндерү программасына үзебезнең тәкъдимнәребезне җиткереп, бистәнең милли йөзен саклау; Казанның туристлар картасында Яңа бистәдә Ф.Әмирхан белән бәйле урыннар булдыру; Ф.Әмирхан исемен мәңгеләштерүгә өлеш кертү.

Эшнең төп бурычы: татар халкы тарихында Яңа бистәнең ролен ачыклау; татарлар тормышында Әмирханнар нәселенең әһәмияте; Ф.Әмирханның тормыш юлына күзәтү ясау.

Кулланылган методлар: фәнни, әдәби һәм матбугат материаллары белән эшләү; анализ, синтез алымы; эзләнү методы.

Фәнни эшнең гамәли әһәмияте: Яңа бистәне төзекләндерү программасында аның милли – тарихи йөзен чагылдыру, Яңа бистәдә Ф.Әмирханга бәйле урыннар булдыру. Ф.Әмирханны өйрәнү, туризм, татар әдәбияты, Казан тарихы белән кызыксынучыларга безнең хезмәтебез файдалы булыр дип өметләнәбез.

Фәнни эшне язганда, Р. Әмирханның "Әмирханнар" шәҗәрәсе, "Ф. Әмирхан турында истәлекләр", Ибраһим НУРУЛЛИНның "Фатих Әмирхан" Д. Заһидуллина, Т. Шакированың "Ф.Әмирхан", Р.Ф.Исламовның "Тукайны өйрәнүдә яңа чыганаклар" китабы, И.Г. Гомәров редакциясендә "Рухи мирас: эзләнүләр һәм ачышлар", интернет челтәре материаллары кулланылды.

Татар халкы тарихында Әмирханнар нәселе аерым урын алып тора. Бу нәселнең Мәрҗаниләр, Камаловлар, Бигиевләр, Аитовлар, Акчуриннар, Апанаевлар, Апаковлар, Исхакыйлар кебек татар дөньясының атаклы нәселләре белән тыгыз элемтәдә, туганлык мөнәсәбәтләрендә торуы да аларның милли тормышыбыз үзәк агымында баруын күрсәтә. Чыннан да, XX гасыр башы татар тормышында мондый зыялы, гарәп, төрек, хәтта инглиз телләрендә иркен аралашучы шәхесләр тәрбияләгән гаиләләр сирәк күренеш. Әлеге затлы нәселнең Казан чоры Әмирхан хәзрәттән башлана. Аның улы Мөхәммәтзариф, ата–бабаларының юлын дәвам итеп, мәгърифәт, дини тәрбия җирлегендә хезмәтләр дә иҗат иткән шәхес. Зариф хәзрәт 1913 елның апрелендә мәшһүр шагыйребез Тукайның җеназасын укыган кеше. Мондый зур вазифаны аңа ышанып тапшыру – татар җәмәгатьчелегенең Зариф муллага ышаныч, олы ихтирам билгесе. Тукай мәетен Клячкин шифаханәсеннән Юнысов мәйданына китергәч, "Зариф

хәзрәт Әмирхани тарафыннан җеназа укыла. Күмү эше тәмам булгач, Зариф хәзрәт “Тәбарәк” укып дога кыла. Димәк, халкыбызның бөек улы Тукайны җиргә иңдерү, мөселманча озату Зариф хәзрәт тарафыннан башкарыла.

Мөхәммәдзарифның өлкән улы Фатыйх Әмирхан. “Әмирханнар нәселенең таҗы, бу кавемнең данын бөтен төрки – татар дөньясын шаулаткан зат,” – дип саныйлар аны. Чыннан да, Ф.Әмирхан XX гасыр башы татар әдәбиятында, татар тормышына яңалык алып килүче классикларыбызның берсе. Ф.Әмирхан үз тирәсенә яшьләрне җыя белгән.

Без бу хезмәтебездә төп игътибарны Әмирханнар йортына юнәлдердек. Әмирханнар йорты Яңа бистәнең генә түгел, бөтен татар зыялыларының үзәге булып торган. Эзләнүләребез күрсәткәнчә, әдип янына бик күп язучылар килгән һәм аның бүлмәсендә бик озак утырганнар. Бөек драматург К.Тинчуринның да Әмирханнарда еш булуын З.Тинчурина истәлеге ассызыклый Исмәгыйль Һилалов истәлегендә мондый юллар бар: ”Ф. Әмирхан янына күп киләләр, ул үзе дә кешеләрдән башка тора алмый, ярата иде әдип кешеләрне! Артистлар, язучылар, матбугат эшчеләре, сәнгать әһелләре йөри иде аның янына”.

Ф.Әмирхан музыка сәнгатен дә бик яраткан, аяклары йөрмәсә дә концерт, опералларга еш барган.Татар артистларына үзенең фатихасын биргән. ”С. Гобәши белән Фатих абыйларга берничә мәртәбә бардык. Миңа: ”Сара сеңлем,табигать сиңа моңлы тавыш биргән. Син җырны ташлама”, – ди торган ие”, – дип язган Сара Садыйкова. Сара Садыйкова язучы өенә еш барган, татар музыкасын үстерү турында сөйләшүләр күп булган.

Ф. Әмирхан үзе белән танышырга килүче татар студентларына, курсисткаларга зур әһәмият бирде. Әдип татар яшьләре арасыннан врачлар, инженерлар, адвокатлар, сәнгать әһелләре чыгуын тели иде” дигән юллар бар. Чыннан да, Ф. Әмирхан бар кешегә дә җылы өләшкән. Күренекле галим Җамал Вәлиди Әмирханны “Гейне зур бер пайтәхетнең өстенә чыгып торган манараларның берсе булса, Ф. Әмирхан безнең бистәбезнең өстеннән күренеп торган һәм шул бистәнең үзенә чаклап ясалган манарасы”на тиңли.

Мөхәммәтзарифның кече улы Ибраһим – Согуд Гарәбстаны илчелегенең сәркатибе. Зариф хәзрәтнең кызы Бибисәгадәтбану да – әти-әнисе юлын дәвам итүчеләрнең берсе. Ул – “Әмирхания” кызлар мәктәбе мөгаллимәсе.

Яңа бистәдә Әмирханнар хәзерге М.Гафури урамы 35 нче йортта яшәгәннәр. ачык зәңгәр буяуга буялган матур йорт.. Ул вакытларда капкадан ишегалдына кергәндә,сул якта иске бер кечкенә йорт торган. Разия Әмирханова болай искә алган “Анда дәү әнием мөдирлек итә торган кызлар мәктәбе

урнашкан. дәү эти белән гомер итә башлаганда, алар шул йортта торганнар. Икенче йорт салып чыккач, искесен мәдрәсә иткәннәр. Ишегалдының түренә кертеп салынган зур тәрәзәле, бер катлы йорт булган. “Бу зур гына бер этажлы йорт биш бүлмәдән тора.

Ф. Әмирханнар йорты 1 нче гимназиягә каршы урнашкан. Әйтүләренчә, гимназия Зариф мулла сукмагына салынган. Зариф мулла өеннән мәчеткә шул сукмактан йөргән, күрәсең. Хәзерге вакытта гимназиядән чыгу юлы шул сукмакка туры килә дип фаразлана. Ф.Әмирханнар йорты 1990 нчы елларга кадәр үз урынында торды. Казанда иске йортларны бетерү сәясәте башлангач, М.Гафури урамындагы Әмирханнар йортын җир белән тигезләделәр. XX гасыр башында татар мәдәнияте, әдәбияты үзәге ролен үтәгән йорттан бүгенге Казан кешесе хәбәрдар түгел. Бу – татар халкының бөек шәхесләренә битарафлыгы. Әйе, татарның бөек язучысы Ф.Әмирханның йорт урынын саклап кала алмады милләтебез. Бу бик аяныч хәл.Татар халкы өчен җан аткан , милләт үсеше өчен ничә буын Әмирханнар көч куйган, һәр татар кешесе өчен киңәш-табыш итә торган изге урын Зариф хәзрәт йорты урынында бүген җилләр генә исә.

1912 нче елда язган “Бер хәрабәдә” хикәясендә Ф. Әмирхан “Фәтхулла хәзрәт”тәгечә 50 елдан соң әллә үз нигезен күрдеме икән – Ләгънәт сиңа, и тормыш! Әүвәл алдыйсың, аннан соң мыскыллыйсың!”

Бу сүзләр белән Ф. Әмирхан, әйтерсең лә, безгә, халкына мөрәҗәгать итә. XX гасыр башы татар халкы өчен белем-мәгърифәт өләшкән бу йорт озак еллар ташландык булып ятканнан соң, юкка чыгарылды. Ф. Әмирхан йорты урынында бүген 10 катлы торак йорт. «Бер хәрабәдә» әсәрендә сызлану фәлсәфәсе дип билгелиләр галимнәр. Әйе, монда сызлану. Ф. Әмирханның да, Зариф хәзрәтнең дә. Татар җәмәгатьчелеге йортны саклап калырга теләмәсә дә, бәлки йорт урынына элмә такта куяргадыр.

Гомеренең иң күп елларын шушы йортта үткәргән әдип туган нигезне татар халкы игътибарсыз калдырырга тиеш түгел иде.

Эшебездә түбәндәге нәтиҗәләргә килдек: Әмирханнар нәселе – XIX һәм XX гасыр башы татар дөньясының үзәге. Фатих Әмирханның ата-бабалары мәгърифәтчеләр булып, мәктәп-мәдрәсәләр ачып, халык арасында аң-белем таратканнар яки гомерләрен татар тарихын өйрәнүгә багышлаганар. Тукайны гүргә иңдергән Зариф Хәзрәтнең йорты рәсми булмаган мәгърифәт үзәген үтәгән. Бу йорт бөек кешеләрнең эзен саклый. Казаннан гына түгел, башка өлкәләрдә яшәүче татарлар да киңәш итәргә, очрашуларга даими килгәннәр.Бу йорт татар халкының танылган шәхесләре Г. Тукай, К. Тинчурин, С. Садыйкова, Вафа Бәхтияров, Габдрахман Мостафин, Фатих Сәйфи, Хөсәен

Ямашев, Мәхмүт – Дулат Али, С. Гобәши, Касыйм Шамил, Җамал Вәлиди кебек бөек акыл ияләрен үзенә җыйган. XX гасыр башы татар дөньясының милли-мәдәни үзәге булган Әмирханнар йорты тарихта эзсез югалырга тиеш түгел! Татар халкы моңа юл куймас!

**Д.А. ТЕМИРОВА**

*МГУ имени М.В. Ломоносова, Россия*

## ЛИЧНЫЕ И УКАЗАТЕЛЬНЫЕ МЕСТОИМЕНИЯ В SMS-СООБЩЕНИЯХ НА SINGLISH (НА ПРИМЕРЕ SMS-СООБЩЕНИЙ КОРПУСА SMS NUS)

**Аннотация.** Статья посвящена изучению языковой ситуации Сингапура и на ее основе рассмотрению особенностей употребления личных и указательных местоимений в SMS-сообщениях на сингапурском варианте английского языка. В процессе анализа были определены наиболее характерные местоимения, способы их выражения и прагматические связи с их коллокатами в сообщениях 2004 и 2012 гг. корпуса SMS NUS.

**Ключевые слова:** SMS-сообщение, корпус, личные и указательные местоимения, синглиш (Singlish).

**Abstract.** The article is devoted to the study of the language situation in Singapore and the peculiarities of personal and demonstrative pronouns in SMS. The most frequent pronouns, ways of their expression and pragmatic connections with their collocations were identified in SMS of 2004 and 2012 from the corpus SMS NUS.

**Key words:** SMS, corpus, personal and demonstrative pronouns, Singlish.

Английский язык служит основным языком социально-экономического развития в Сингапуре в связи с чем, государство делит население на четыре этнические категории (китайцы, малайцы, индийцы и другие), чтобы сделать его этнолингвистическое разнообразие более управляемым. Помимо этого английский язык служит языком лингва франка, который необходим для обеспечения содействия межэтническому общению и объединению различных этнических групп. Государство Сингапура активно поощряет владение английским языком, однако делается акцент на восприятии его как этнически нейтрального, чтобы распределение экономических преимуществ не увеличивалось в пользу какой-либо конкретной этнической группы, так как данное обстоятельство может способствовать развитию межэтнической напряженности. В результате принимаемых мер большинство жителей считают английский язык этнически нейтральным, но при этом он не является социально нейтральным.

Как показало исследование Синити Харада, посвященное языковой ситуации в Сингапуре, существует дихотомия в использовании стандартного английского языка и его сингапурского варианта – Singlish (синглиш). Singlish практикуют при разговоре с близкими людьми, в то время как стандартный английский язык является языком официального общения. В беседе автора исследования со знакомой из Сингапура на вопрос, почему сингапурцы используют синглиш при общении с друзьями, она ответила: «Если я буду общаться с моими друзьями на стандартном английском языке, а не на синглише, они подумают, что я сноб. Конечно, во время занятий в классе я говорю на стандартном английском» [Harada, 2009: 73–74]. Некоторые исследователи считают это нормальной речевой практикой. Как отмечает А.Ф. Гупта, опытный взрослый носитель английского языка в Сингапуре использует два совершенно различных вида английского языка в зависимости от обстоятельств [Gupta, 2007: 107].

Интерес для настоящего исследования представляют особенности употребления местоимений в сингапурском варианте английского языка (Singlish) с точки зрения прагматики SMS-сообщений в условиях ограниченного набора символов.

Материалом для анализа послужили SMS-сообщения 2004 и 2012 гг., взятые из корпуса SMS NUS, разработанного лингвистами при Национальном Университете Сингапура [Tao Ch., Min-Yen K., дата обращения: 20.02.21].

С помощью корпус-менеджера AntConc[1] нам удалось определить, что наиболее характерными для сообщений 2004 г. являются местоимения 1-го и 2-го лица (1169 и 1100 словоупотреблений соответственно):

*– Jos ask if* ***u*** *wana meet up?*

*– Aiyo... First time* ***u*** *reply so fast... Y so lucky not workin huh, got bao by ur sugardad ah...gee…*

Помимо количественного показателя форм местоимений программа AntConc позволила определить наиболее частотные, связанные с ними, коллокации[2]. Так, при анализе левых и правых коллокатов[3] для местоимения 1-го лица (***I***) характерным правым коллокатом являются сокращенные формы вспомогательного глагола ***be*** (в настоящем времени) и форма будущего времени (will):

---

[1] Корпус-менеджер, разработанный профессором факультета науки и техники в японском Университете Васэда Лоуренсом Энтони и предназначенный для обработки корпусов [Laurence A., дата обращения: 22.08.2021].

[2] **Коллокаты** – слова, с которыми часто вместе используется анализируемое слово.

[3] **Левые коллокаты** – слова, предшествующие анализируемому слову. **Правые коллокаты** – слова, следующие за анализируемым словом.

*– Wow… U did it all nite ah… Hmmm… I got somethin on until 3… Thk **i'll** msg u when **i'm** abt done k…*

*– Hey xin… So u wana go tmr rite…Cos **i'll** b bookin tmr morn, u 2 and 4pm oso can rite…*

Для местоимения 2-го лица (**you**) характерна связь с глаголом ***want*** (хотеть), который в текстах имеет формы ***wan/wana:***

*– **U wan** me call ur house or phone?*

*– Hmmm… But where **u wana** meet me first…*

Проведенный анализ дает нам основание полагать, что такое количество употреблений местоимений 1-го и 2-го лица доказывает ориентированность отправляемых сообщений на собеседника с целью понимания его намерений.

В сообщениях 2012 г. количество использований вышеупомянутых местоимений уменьшилось в 2 раза и составило 590 и 573 употребления для местоимений 1-го и 2-го лица соответственно.

Помимо изменений количественной характеристики употреблений этих слов, изменились также и коллокации, и теперь наиболее употребляемым стало сочетание **«местоимение + to be»** в формах ***I'm*** и ***I am***:

*– Oh sorry I dnt knw. I thaught **I am** angry*

*– Hi cumi…**I'm** gr8 n wht abt u… I missd u*

Следующую позицию в порядке убывания по частотности использования занимает коллокация «**местоимение + вспомогательный глагол do/have**». Однако следует отметить, что вспомогательный глагол приводится в большей степени в форме отрицания (в соотношении 139 словоформ к 21 в форме утверждения) и имеет следующие версии написания do – **don/dnt/didn/dint/dun** и have – **hvnt/haven/hvn**:

*– Oh sorry **I dnt** knw.i thaught i am angry*

*– Helw budy…I'm sunykriplani n **i hvnt** recievd d pr0dct yet…Plz chk whn i'l gt.*

Как и в сообщениях корпуса SMS NUS 2004 г., сочетание местоимения 2-го лица (**you**) с глаголом ***want*** (хотеть) стало характерным и для текстов 2012 г. Такая параллель между корпусами 2004 и 2012 гг. позволяет сделать вывод о том, что отправителю важно понимать коммуникативную интенцию адресата. С прагматической точки зрения данный факт подтверждает ориента- цию адресанта на собеседника.

Помимо личных местоимений интересными для анализа оказались указательные, которые в сообщениях 2004 и 2012 гг. корпуса SMS NUS представлены как в стандартном варианте написания, так и в форме близкой к звучанию,

но принятой нами за диалектную особенность. Так, указательные местоимения *this* и *that* выражены в формах ***dis*** и ***dat***:

*– Hmm… Dunno leh, mayb bag 4 going out* **dat** *is not small. Or jus anything except perfume, smth* **dat** *i can keep.*

*–* ***Dis*** *is yijue. I jus saw ur mail. In case huiming havent sent u my num.* ***Dis*** *is my num. I'm leaving my house now.*

Использование указательных местоимений в подобной форме мы относим к особенностям сингапурского варианта английского языка, т.к. проанализировав количественные показатели этих местоимений, мы пришли к выводу, что в сообщениях 2012 г. в большей степени они стали использоваться в стандартном для английского языка виде. Это основание дает нам возможность утверждать, что проводимая государством Сингапура языковая политика склонения населения к стандартному английскому языку с течением времени показывает положительные результаты.

**ЛИТЕРАТУРА**

1. Gupta, Anthea Fraser. 2007. "The language ecology of Singapore". In Angela Creese, Peter Martin and Nancy Hornberger, eds. *Encyclopedia of Language and Education.* Vol. 9*: Ecology of Language.*Dordrecht: Kluwer, 99–111.

2. Harada, Shinichi. "The Roles of Singapore Standard English and Singlish." Information and Communication Studies 40. 69–81, 2009. Print. Joo, Mary Tay Wan.

3. *Laurence A.* AntConc (Version 3.5. 9) [Computer Software]. Tokyo, Japan: Waseda University. URL: https://www.laurenceanthony.net/software (дата обращения: 22.08.2021).

4. Tao Ch., Min-Yen K. Creating a Live, Public Short Message Service Corpus: The NUS SMS Corpus https://www.comp.nus.edu.sg/~kanmy/papers/smsCorpus.pdf (дата обращения: 20.02.21)

**С.О-Ф. УЗУМ**

*Мостафа Өнҗәл исемендәге лицей-интернат,*

*Бөгелмә, Татарстан Республикасы, Россия*

## ТАТАР ҺӘМ ТӨРЕК ТЕЛЛӘРЕНДӘ ИСЕМ СҮЗ ТӨРКЕМЕН ЧАГЫШТЫРУ

**Аннотация.** В этой статье говорится о сравнении имен существительных татарского и турецкого языка. Был проведен анализ грамматических категорий имен существительных, таких как: род, число, падеж, категория принадлежность. А также было проведено сравнение образования слов в татарском и турецком языках.

**Abstract:** The article refers to the comparison of nouns in Tatar and Turkish languages. We analyzed grammatical categories of nouns such as: genus, number and case. In addition, a comparison of the word formation in the Tatar and Turkish languages was carried out.

**Ключевые слова.** Род, число, падеж, категория принадлежности, словообразование, татарский язык, турецкий язык.

**Key words:** genus, number, case, word formation, Tatar language, Turkish language.

Татарстан – күп милләтле республика, анда төрле милләт вәкилләре, Тукайча әйткәндә, "тел, лөгать һәм әхлак алмашып" яши. Мин Бөгелмә районы Мостафа Өнҗәл исемендәге лицей-интернатның 10 нчы сыйныф укучысы. Лицейда рус, татар, инглиз телләре белән бергә, төрек һәм француз телләрен дә өйрәнәбез. Бүгенге эшемнең темасы итеп мин: «Татар һәм төрек телендә исем сүз төркемен чагыштыру»ны алдым.

Татар һәм төрек телләре – иң киң таралган төрки телләр. Бу телләр икесе дә, башка барлык төрки телләр кебек, агглютинатив (тагылмалы) телләргә керә. Сүзнең тамырына аффикслар (кушымчалар) билгеле бер тәртиптә ялгана (мәсәлән: өстәл-ләр-ем-дә, araba-lar-ımız-da). Татар теленә иң якын торган телләр – башкорт, нугай, казах, каракалпак, карачай, болкар, комык телләре. Шулай ук төрек, гагауз, азәрбайҗан, үзбәк, төрекмән, кыргыз телләре дә татар теленә бик якын торалар.

Әгәр исем сүз төркемен карасак, татар һәм төрек телләрендә охшашлык шунда: аларда **род** категориясе юк. Татар телендә кем? соравы кешеләргә генә куела. [1: 67]

Төрек телендә дә, нәкъ татар телендәге кебек, kim? (кем?) кешеләргә карата гына кулланыла. Хайваннар, бөҗәкләр, балык, кошларга барысына да ике телдә дә нәрсә? (ne?) соравы куела.

Исемнәрнең күплек сан формасын карасак, татар телендә күплек сан кушымчалары –лар//-ләр, -нар//-нәр белән ясала. Татар телендә,-м,-н,-ң хәрефләреннән соң, -нар//-нәр аффикслары ялган. Мәсәлән, урындыклар, кешеләр, урманнар, идәннәр. [1: 67] Ә төрек телендә исемнәрнең күплек сан формасы -lar//-ler, аффиксы ярдәмендә ясала. Мәсәлән: masalar, kişiler, orma**n**lar, anneler,babalar. Төрек телендә – н хәрефеннән соң, -lar кушымчасы ялгануы аермалы як, чөнки төрек телендә – нар кушымчасы юк. [2: 91]

Татар һәм төрек телләрендә тартым аффикслары күплек сан кушымчасыннан сон килә. Мәсәлән: дәфтәр, дәфтәрләр, дәфтәрләрем; ev (өй), evler (өйләр), evlerim (минем өйләрем), söz (сүз) sözler (сүзләр) sözleriniz (сезнең сүзләрегез). [2: 96]

Һәр ике телдә дә 6 килеш бар. Баш килешнең генә кушымчасы юк, кыек килешләрнең аффикслары бар.Татар телендә, башка төрки телләрдәге кебек үк, барлык исемнәр бер типта төрләнә, килеш белән төрләнешнең морфологик вариантлары юк. Килеш кушымчалары фонетик яктан аерымланалар. Килеш кушымчалары барысы ды тартык авазга башлана (кыпчак телләренең үзенчәлеге), һәм аларның ике, дүрт, алты фонетик варианты бар. Сонор тартыкка башланган иялек килеше (-ның/-нең) һәм төшем килеше (-ны/-не) кушымчалары ике вариантлы (рәт гармониясе), ә шаулы тартыкка башланган калган кушымчалар дүрт (-га/-гә,-ка/-кә) һәм алты (-дан/-дән,-тан/-дән,-нан/-нән) вариантлары килә (рәт гармониясе һәм тартыклар охшашлану). [1:74]

Ә төрек телендә түбәндәгечә:

| № | Килешләр | Кушымчалар | Сораулары |
|---|---|---|---|
| 1 | Yalın durum, yalın hal (основной падеж) | - | Bu ne?Bu kim? |
| 2 | Tamlayan durumu, ilgi hali (родительный падеж) | -in/ -ın/ -un/ -ün или -nin/ -nın/ -nun/ -nün | Kimin?Neyin? |
| 3 | Belirtme durumu,belirtme hali (винительный падеж) | -yi/ -yı/ -yu/ -yü ı/ -i/ -u/ -ü | Kimi? Neyi? |
| 4 | Yönelme durumu, yönelme hali (дательный) | -a/ -e -ya/ -ye | Kime? Neye? Nereye? |
| 5 | Kalma durumu,bulunma hali (местный) | -da/ -de,-ta/te | Nerede? Kimde? |
| 6 | Çıkma durumu, ayrılma halı (исходный) | -dan//-den, -tan//-ten. | Nereden? Kimden? Neden? |

Тартым – төрки телләр өчен хас үзенчәлекле грамматик категория. Аның грамматик мәънәсе – предметның кайсы затка караганлыгын белдерү, димәк, тартым предмет һәм аның иясе, хуҗасы арасында мөнәсәбәтне белдерә. Грамматик формасы–исемгә ялганып килгән тартым кушымчалары. [1:100]

Нәтиҗә: тартым категориясенең татар һәм төрек телләрендә кушымча белән ясалуында уртаклык бар.

| зат | Төрекчә | | Татарча | |
|---|---|---|---|---|
| | Берлек сан | Күплек сан | Берлек сан | Күплек сан |
| I | Benım-kitabım | Bizim-kitabımız | Минем китабым | Безнең китабыбыз |
| II | Senin-kitabın | Sizin-kitabınız | Синең китабың | Сезнең китабыгыз |
| III | Onun-kitabı | Onların-kitapları | Аның китабы | Аларның китаплары |

Татар телендә сорау җөмләләр сорау сүзләре яки сорау кисәкчәләре ярдәмендә ясала. Татар телендә сорау кисәкчәләре –мы//-ме җөмлә ахырындагы сүзгә кушылып языла. Мәсәлән, Син укучы кыз<u>мы</u>? Бүген дүшәмбе<u>ме</u>? Төрек телендә дә сорау җөмләдә сорау сүзләре яки сорау кисәкчәләре булырга мөмкин. Сорау кисәкчәләре –mı//-mi, -mu//-mü, гадәттә, хәбәрдән соң килә. Алар аерым язылалар. Мәсәлән: Bugün çarşamba mı?; bugün Cumartesi mi?; Pazara gidecek misin?; Bana elbise alacak mısın?

Исемнәрнең ясалышын чагыштырып карасак, сүз ясалыш ысулларында да охшашалыклар күрербез.

Морфологик (кушымчалау) ысулы белән сүз ясалу 2 телдә дә бар.

Татар телендә сүз ясагыч кушымча -чы/-че кушымчасы төрек телендәге – cu/ - cü, -cı/-**çi,** çı/-çi,- çu/-çü белән туры килә. Мәсьәлән: төрекчә, yol(дорога)-yolcu(пассажир),balık (рыба)-balık**çı** (рыболов), demir (железо) - demirci (кузнец), av(добыча)-avcı (охотник) [2:60]. Татар теленә мисал итеп, язучы, җырчы, җыештыручы, эшче, тәрбияче сүзләрен китерергә мөмкин.[1:107]

Төрек телендә дә татар телендәге кебек сүзләрне кушу ысулы белән ясалган сүзләр бар. Мәсәлән, татар телендә ташкүмер, тукранбаш, кулъяулык, аккош [1:110] сүзләре, ә төрекчәдән tamirhane, yatakhane, Eskişehir, imambayıldı сүзләре 2 сүздән тора.

Кыскартылма юл белән ясалган сүзләрне дә күзәтергә була. Мисалга К(П)ФУ, БМЗ (Бөгелмә механика заводы), КамАЗ, төрекчәдән ABD (Amerika Birleşik Devletleri), TD (Türk dili), TK(Türk kültürü) китерергә мөмкин[2:40].

Алынма сүзләрдә һәр ике телдә дә сингармонизм законы сакланмый. Мәсәлән, гаеп, вазифа, мисал, галим; төрек теленнән мисал китереп, сүземне дәлиллим: insan (человек), tarih (история), kitap(книга), hakikat (истина) [2:40].

Йомгак ясап шуны әйтәсе килә, без татар теленең «Исем» һәм төрек теленең «İsim» сүз төркеменең тикшердек. Тугандаш халык теле булган татар һәм төрек телендәге исем сүз төркеме арасында уртак яклар бик күп дигән нәтиҗәгә килдек.

**ӘДӘБИЯТ**

1. Хисамова Ф.М. Татар теле морфологиясе: югары уку йортлары өчен д-лек / Ф.М. Хисамова. – 2 нче басма. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2015.– 335 б.

2. Щека Ю.В. Практическая грамматика турецкого языка. – АСТ: Восток- Запад, 2007. – 666 с.

3.https://www.dilbilgisi.dilbydil.com/%D0%BF%D0%B0%D0%B4%D0%B5%D0%B6%D0%B8-%D0%B2-%D1%82%D1%83%D1%80%D0%B5%D1%86%D0%BA%D0%BE%D0%BC-%D1%8F%D0%B7%D1%8B%D0%BA%D0%B5/

**И.Ф. ФАТТАХОВ**

*“Мәдәни җомга” атналык газетасы (газета “Культурная пятница”), Россия*

# ОСТАЗ ХАКЫНДА

**Аннотация**. В статье автор анализирует жизненный путь и научную деятельность доктора филологических наук, профессора Вахита Хакова и значение его трудов для развития тюркологии, в том числе и для развития татарского языка. Ученый В. Хаков глубоко и многранно исследовал историю татарского литературного языка и стилистику, выявил стилистические особенности родного (татарского) языка. Об этом четко свидельствуют его труды: “Вопросы языка и стиля” (1961), “Введение в стилистику татарского языка” (1963), “Стилистика и словесное исскуство” (1980), “Развитие татарского литературного языка в советский период” (1985), “Татарский литературный язык (Стилистика)” (1999) и т. д.

**Ключевые слова:** Вахит Хаков, татарский язык, стилистика, студент, дипломная работа, радиопередача.

**Abstract**. In the article, the author analyzes the life path and scientific activity of Doctor of Philology, Professor Vakhit Khakov and the significance of his works for the development of Turkology, including the development of the Tatar language. The scientist V. Khakov deeply and many-sidedly researched the history of the Tatar literary language and stylistics, revealed the stylistic features of the native (Tatar) language. This is clearly evidenced by his works: "Questions of language and style" (1961), "Introduction to the stylistics of the Tatar language" (1963), "Stylistics and verbal art" (1980), "Development of the Tatar literary language in the Soviet period" (1985), “Tatar literary language (Stylistics)” (1999), etc.

**Key words:** Vakhit Khakov, Tatar language, style, student, thesis, radio broadcast.

Ана телебезнең стилистик серләрен фәнни өйрәнгән мөхтәрәм галим Вахит Хөҗҗәт улы Хаковның татар тел белеме дөньясында абруйлы исеме, лаеклы урыны бар. Бу өлкәдә ул зур гыйлем иясе – филология фәннәре докторы, профессор иде. Галимҗан Ибраһимов, Җамалетдин Вәлиди, Латыйф Җәләйләр башлаган изге гамәлнең дәвамчысы. Татар әдәби теле тарихын һәм стилистика фәннәрен күпьяклы тикшергән, телебезнең стилистик үзенчәлекләрен тапкан галим булуын аның “Тел һәм стиль мәсьәләләре” (1961), “Татар теле стилистикасына кереш” (1963), “Стилистика һәм сүз сәнгате” (1980), “Татар әдәби теленең совет чорында үсеше” (1985), “Татар әдәби теле (Стилистика)” (1999) кебек һ. б. хезмәтләре дәлилләп тора.

Вахит агага яшәешнең шатлыгын да, михнәтен дә күрергә туры килгән. Ул – 18 яшьтән сугыш ачысын татыган, бу афәтнең авырлыгын үз җилкәсендә күтәргән фронтовик, үлем тырнагыннан исән-сау котылган Бөек Ватан сугышы ветераны. Шуңа күрә язмышына гел рәхмәт укып, Аллаһка шөкер дип яшәгән.

1992 елда КДУның татар филологиясе, тарихы һәм көнчыгыш телләре факультетына укырга кергәч, декан Т.Н. Галиуллин безне – 136 студентны фа-

культет мөгаллимнәре һәм кафедра мөдирләре белән очраштырды. Шунда Тәлгат Нәби улының чал чәчле, тыйнаклыгы йөзенә чыккан татар теле кафедрасы мөдире, профессор Вахит Хаков белән таныштырып, аны фронтовик дип атавы хәтеремдә уелып калган. Бу олпат зат бераздан безгә үзе дә "Татар әдәби теле тарихы" курсыннан лекцияләр укый башлады.

Вахит абый Хаков – шулкадәр тыйнак, әдәпле, җайлы, ипле, намуслы, югары культуралы, тәрбияле, сабыр кеше иде. Аның белән сөйләшергә уңайлы, аралашу күңелгә рәхәтлек бирә иде. Һәрчак акрын тавыш белән теманы аңлатыр иде, студент халкына беркайчан да тавышын күтәргәнен ишетмәдем. Сорауларга һәрчак төпле, дәлилле җавап бирә иде. Лекцияне йомшак, бәрхет тавыш илә сөйләр иде. Фронтовик Вахит агага хөрмәт зур иде, хезмәттәшләре дә, студентлар да аны бик ихластан ихтирам итәләр иде.

Вахит ага һәрвакыт ыспай киенгән булыр иде: үзенә килешеп торган костюм-чалбар, матур күлмәк, зәңгәр галстук, кышын башында мех бүрек, өстендә кайры тун иде.

2–5 нче курсларда ул минем гыйльми җитәкче булды. Аның кул астында фәнни эшкә өйрәнүдән күңелемдә матур тәэсирләр калды. Ул мине студент чагымда ук "Татарстан" дәүләт телерадиокомпаниясенә эшкә урнаштырды. Рөстәм Акъегет (Фәйзуллин) җитәкләгән әдәби-драматик тапшырулар редакциясенә менә Вахит абый тыйнак кына килеп керә, йомшак тавышы белән исәнләшә, без елмаеп аны каршы алабыз. Аннары ул: "Рөстәм, "Тел күрке – сүз" тапшыруына килгән хатларны укып, аларга җавап әзерләгән идем, материалларны карап чыгарсыз әле", – ди.

Вахит ага минем биредә журналист эшенә өйрәнүемә, үзенең 50 елдан артык радиоэфирда яңгырый торган "Тел күрке – сүз" авторлык тапшыруын турыдан-туры әзерләүдә катнашуыма, XX гасырның 90 еллары башында татар теленең дәүләти дәрәҗәдә гамәлгә керә башлавына чын күңеленнән сөенде, шәкертенең ана теле һәм әдәбият укытучылары, милли мәгариф буенча директор урынбасарлары белән әңгәмәләр үткәрүенә, туган телебезгә карата халкыбызның уңай мөнәсәбәтен өйрәнүенә гаять шатланды. Аның милләттәшләр өчен гамәли әһәмияткә ия бу тапшыруын кечкенәдән тыңлап үскәнгә күрә җаныма якын, кадерле иде ул. Айрат һәм Мәрьям Арслановларның бәрхет тавышы да "Тел күрке – сүз" тапшыруын танытуда, минемчә, зур урын тотты. Вахит ага узган йөзнең 90 елларында татар телен кирилл язуыннан латин графикасына күчерү өчен җан атып йөрде. "Тел күрке – сүз" тапшыруы аша да бу күчешнең өстенлеген, уңай ягын радиотыңлаучыларга күп тапкыр аңлатты, шушы темага байтак мәгълүмат сөйләде.

Минем диплом эше җитәкчесе иде Вахит ага. Фәнни җитәкчем булгач, аңа консультациягә еш йөрдем. Билгеләнгән бер көнне, билгеле бер сәгатьтә унберенче этаждагы татар теле кафедрасында әйбәт консультация бирә иде. Университетның фәнни китапханәсендә дә Вахит аганы даими күрергә була иде, 11 нче уку залына яки каталогка керә иде ул.

Вахит абый миңа диплом эше итеп, мәрхүм хезмәттәшенә хөрмәт йөзеннән, "М. Мәһдиев иҗатында юмор стиле" темасын тәкъдим итте. Бик теләп ризалаштым, аның карамагында нәтиҗәле эшләп, тәүге фәнни хезмәтемне бик уңышлы якладым. Биредә аның эш стиленә игътибар иттем: М. Мәһдиевнең "Без – 41 нче ел балалары", "Ачы тәҗрибә" әсәрләреннән шактый мисаллар җыйдырды, диплом эшенең һәр бүлеген укып чыкты, караламасын карандаш белән төзәтте, шул рәвешле ел буе эшләтте.

В. Хаков гомере буе ана телебезгә тугъры калды. Бу гүзәл сыйфатын ул үзенең 80 яшьлеге уңаеннан Казан дәүләт университетының тарихи Актлар залында уздырылган хөрмәтләү җыелышында тагын бер кат раслаган иде. Беренчедән, хезмәте аша үзенә хөрмәт яуласа, икенчедән, бирегә килгән җәмәгатьчелек аның аркылы туган телебезгә ихтирамын белдерде. Казан университетында Тукай теленең тантанасы сыман тоелган иде миңа шул җыелыш. Ул ямьле көнне галимне КДУ ректоры М.Х. Сәлахов ихластан тәбрик итеп, аңа "Казан дәүләт университетының атказанган профессоры" дигән шәрәфле исем бирде, махсус билгесен тапшырды. Аннан соң хезмәттәшләре, шәкертләре саф күңелдән эчкерсез котлап, Вахит агага берсеннән-берсе матур чәчәк бәйләмнәре, бүләкләр бирделәр. Вахит Хаков – туган телебез сакчысы иде!

Латин графикасына күчәбез дип нык шаулашкан идек узган гасыр ахырында. Татфакта шушы эксперимент буенча хәтта фәнни комиссия төзеделәр, аның рәисе декан Т. Галиуллин, 30 нчы елларда ук татар совет мәктәбендә яңалифне өйрәнгән В. Хаков әлеге комиссия әгъзасы иде. Радиотапшыру өчен материал әзерләү максатыннан, шул комиссиянең бер утырышында катнашырга туры килде миңа да (ул вакытта "Татарстан" радиосында эшли идем). Вахит абыйның кара тактага латин хәрефләрен яза-яза аңлатканы хәзер дә күз алдында тора әле.

Шулай итеп, галим Вахит Хаков татар әдәби теле тарихын һәм стилистикасын тирәнтен тикшергән, туган телебезнең стилистик үзенчәлекләрен ачыклаган. Бу хакта аның югарыда телгә алынган хезмәтләре раслый.

**Р.Н. ФАХРТДИНОВА**
*Казан федераль университеты, Россия*

# «ЯҢА МӘХӘЛЛӘ ХӘБӘРЛӘРЕ» ТУРЫНДА

**Аннотация.** «Yaña Mähallä habärläre» – это религиозный журнал, целевой аудиторией которой являются татары. В журнале максимально полно освещаются новости из жизни финских татар. На страницах журнала вы можете прочитать статьи про межнациональные собрания, про религию и спорт. Привлекают внимание и игры, кроссворды, логические задачи, направленные на развитие мышления и внимания ребенка. В статьях вы можете познакомиться с обычаями, традициями, кулинарией, языком и вероисповеданием татарского народа.

**Abstract.** «Mahalla News» is a religious magazine whose target audience is tatars. The magazine covers news from the life of finnish tatars as fully as possible. On the pages of the magazine, they can read articles about interethnic relations, religion and sports. Games, crosswords, logical tasks aimed at developing the child's thinking and attention also attract attention. In the articles they can get acquainted with the customs, traditions, cooking, language and religion of the tatar people.

**Ключевые слова**: религия, спорт, национальные блюда, известные личности, языковые особенности.

**Key words:** religion, sports, national dishes, famous personalities, language features.

Дин, тел, гореф-гадәтләр – татар халкын бердәм итеп, милләтебезне күп гасырлар буена саклап килүче төп нигезләр булып тора. Татар халкы бик күп тормыш сынаулары үтеп, кайчандыр югалуга дучар ителгән туган телен, динен саклап, алга таба атлаган. Гасырлардан-гасырга, буыннан-буынга кешеләрнең яшәү рәвешләрен, үз-үзләрен тоту кагыйдәләрен, карашларын, зәвыкларын сакларга омтылган.

Бүгенге көндә татарлар Польша, Румыния, Кытай, Финляндия, АКШ һәм Австралия, шулай ук Латин Америкасы һәм гарәп илләрендә яшиләр. Мондый территориаль киң таралуына карамастан, һәр илдә татарлар үзләренең мәдәни кыйммәтләрен, телен һәм гореф-гадәтләрен саклап, берләшергә тырыша.

Хәзерге татарларның ата-бабалары Финляндиягә 1870–1920 нче еллар уртасына кадәр килә. XIX–XX гасырлар чигендә биредә зур булмаган татар общинасы формалаша башлый. 1925 елда Хельсинкида беренче ислам общинасына нигез салына, ә ун елдан соң Татар мәдәни җәмгыяте барлыкка килә, ул дини бәйрәмнәр һәм йолалар, спектакльләр, халык музыкасы һәм биюләре, шигырьләр декламациясе белән мәдәни чаралар оештыра башлый.

Финляндиянең ислам общинасы 1949–1963 елларда «Мәхәллә хәбәрләре» җыентык-бюллетенен чыгара башлый. Ул елына ике тапкыр чыгарыла. Барлыгы күрсәтелгән чорда 60 номер нәшер ителә. Төрле елларда газета мөхәррирләре О. Али, З. Таһир һ. б. була. Җыентыкны 1964 нче елда нәшер итүдән туктатуның сәбәпләре төгәл билгеләнмәгән. Экспертлар уйлавынча, бу фин татарларың тормышында «тынлык» чоры белән дә, кадрлар җитмәү белән дә бәйле булырга мөмкин. «Мәхәллә хәбәрләре» чыгарылышы бары тик 2004 елда газета форматында гына яңартыла. Ә 2012 нче елда исә мөселман бәйрәмнәренең берсе алдыннан корбан гаетендә Финляндиядә яшәүче милләттәшләребез татар телендә «Yaña Mähallä habärläre» (Яңа мәхаллә хабәрләре) журналын чыгара башлый. Аның баш мөхәррире Рамиль Беляев була. Чит ил татар диаспорасының барлык басмаларыннан ул бары тик үзе генә татар телендә латин графикасыннан файдаланып, нәшер итә һәм аның оригинальлеге дә шунда чагыла.

«Яңа Мәхәллә хәбәрләре» журналының берничә номерын анализлагач, әлеге басма фин татарлары тормышы турында шактый тулы мәгълүмат бирә дигән фикергә килергә мөмкин. Журналда дин, демография, мәдәният һ.б., проблемаларга зур игътибар бирелә. Мәкаләләрдә без милләтара дини утырышлар турында укып беләбез, анда күтәрелгән төп мәсьәләләр белән, дин тормышы белән танышып, үзебез өчен нәтиҗә чыгара алабыз. Шундый дини утырышларның берсендә Финляндия президенты Саули Нийнистё диннәр арасында тынычлык булса иде дигән теләк белән чыгыш ясый һәм һәр динне хөрмәт итүгә чакыра. Шулай ук дин тематикасындагы мәкаләләрдә яңа мәчетләр ачылу, китаплар басылу, дини документаль фильмнар төшерелү турында мәгълүматлар шактый, милләттәшләребезнең һәр җыелышта намаз укулары, мәхәлләне коручы әгзаларның рухларына дога кылулары турында мәгълүмат очратып була. Күп кешеләрне кызыксындырган дини сорауларга җавапларны да моннан эзләп таба алабыз.

Дини журнал буларак «Яңа Мәхәллә хәбәрләре» төрле яшьтәге укучылар өчен нәшер ителә. Олы кешеләр дә, урта яшьтәгеләр дә, хәтта кечкенә балалар да бу журналны көтеп алалар. Балалар өчен бу журналда әкиятләр, буяулар, кызыклы башваткычлар, хәтер өчен бик күп уеннар, гыйбрәтле хикәяләр тәкъдим ителә. Җәнлекләр, бөҗәкләр атамаларының рәсемнәр белән бирелеше, татар әлифбасының журнал битләрендә урын алуы шулай ук игътибар казана. Гомумән, татар мөхите, татар халкының мәдәнияте белән сабый чактан ук таныштырып, балаларны тәрбиягә, әхлакка, дингә өйрәтергә теләүче әти-әниләр өчен «Яңа Мәхәллә хәбәрләре» журналы отышлы вариант булып тора.

Журнал укучыларны татар милли ризыклары белән дә таныштырып бара. Татар милли ризыклары – татар халкының тарихтан килгән милли ашамлыклары. Татар халкы үз милли ашлары белән бик бай, һәм бөтен дөньяга үз ризыклары белән мәшһүр. Күп гасырларга сузылган тарих дәвамында милли оригиналь ашлар барлыкка килгән, алар үзләренә генә хас сыйфатларны әлегә кадәр саклаганнар. Шушы оригинальлекне күрсәтеп, ризыкка беркүпме тасвирлама, аның ингредиентлары, пешерү ысуллары турында журналда мәгълүматлар бирелә. Ризык белән бәйле тагын бер кызыклы үзенчәлек ул - хәләл продукцияне рекламалау. Тикшерелгән ике журналда да бу реклама урнаштырылган. Минемчә, хәләл ашамлыкларны тәкъдим итү татар халкына файдалы мәгълүмат бирү белән бергә күпмедер дәрәҗәдә динебезне һәм милләтебезнең гадәтләрен саклап калуга да тәэсир итә.

Спорт яратучылар өчен дә «Мәхәллә хәбәрләре» кызыклы, чөнки журнал һәр чыгарылышында «Йолдыз» спортклубы белән, аның активистлары белән таныштырып бара. Оста уйнаучы спортчылар турында мәкаләләр бастырыла. Мәсәлән, 2014 елда нәшер ителгән журналда Гөлтен Бәдретдин яшь футболчы кызлар: Аида һәм Тара белән таныштырып үтә. Монда журналист аларның ничә яшьтә булуларын, әти-әниләренең исемнәрен, кайчан һәм ничек уйный башлауларын, хәтта ничә гол кертүләрен язмасында төгәл күрсәтә. Шулай ук журналларда активистларның төрле спорт уеннары: теннис, волейбол, баскетбол уеннарында катнашулары, тауларга менүләре турында кызыклы язмалар басыла.

Журнал безне дин, милли тормыш, мәдәният һәм сәнгать өлкәсендә тирән эзләр калдырган күренекле шәхесләребез белән дә таныштыра. Без монда Габдулла Тукайның «Эш», «Бәхетле бала» шигырьләрен укый алабыз, Шамиль Закиров, Туфан Миннуллин, Флера Сафиуллина кебек шәхесләрнең тормышлары турында, эшчәнлекләре турында укып белә алабыз.

Журналның теле һәм стиле дә уникаль. Мәкаләләр бары тик фин татарларына гына хас булган диалектта, үзенчәлекле итеп язылган. Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк, алар татар әдәби теленә хас «гъ» авазыннан файдаланмыйлар. Бу мәкаләләрдә «дога» сүзе «доа», «җәмәгать» – «җәмәать», «әгъза» – «аза», «гадәттәгечә» – «адәттәгечә» кебек язылган.

Шулай ук татар теле диалектларын өйрәнүгә дә урын бирелә. 2014 нче елда чыккан журналда мишәр сөйләме белән әдәби телебез арасындагы аерымлыклар күрсәтелә. Анда бирелгән сүзләр ул: “төнә” – “кичә”, “аруга”-“бөтенләй” һ.б. «Тел – серле чишмә» башисемен алган язмада татар теленең сүзләре тикшерелә, мәсәлән: 2014 нче елда чыккан журналда парлы сүзләр, аларның ясалу ысуллары күрсәтелә.

«Яңа Мәхәллә хәбәрләре» журналы дөрестән дә, безгә фин татарлары тормышы турында шактый күп мәгълүмат бирә. Сан буенча Финляндиядә милләттәшләребез аз булса да, аларга берничә гасырдан соң да югалу куркынычы янамый дип уйлыйм, чөнки татарлар бердәм булып, үз диннәре, үз телләре, татар мәдәнияте турында газета-журналлар чыгарганда, яңа буынга татар халкының гореф-гадәтләрен мирас итеп тапшырганда, татарлар әле яшәячәк. Шуны да әйтергә кирәк, тикшерелгән ике журнал арасында эчтәлеге ягынннан беркүпме аерма бар. 2014 елда чыккан журнал 2012 нче елгыга караганда материалга байрак, тулырак һәм кызыклырак. Ә бу исә шатландыра, чөнки татар вакытлы матбугатының үсеше күзәтелә. Киләчәктә дә татар халкының динен, телен, гореф-гадәтләрен саклап, милләттәшләребез эшләрен уңышлы дәвам итсәләр иде!

## ӘДӘБИЯТ


1. Беляев Р.Ф. Yaña Mähallä habärläre. – 2012. – № 1. – 24 бит.
2. Беляев Р.Ф. Mähallä habärläre – 2014. №1. – 28 бит.
3. Беляев Р.Ф. Татарская диаспора Финляндии: вопросы интеграции и сохранения идентичности: дис. … докт.филос.наук. Хельсинки, 2017. – 310 с.
4. Шлыгина Н. В. Традиционные меньшинства Финляндии: формирование и современный статус // Исследования по прикладной и неотложной этнологии. – М.: ИЭАРАН, 2010. – Вып. 221. – 43 с.



**А.Р. ХӘБИБУЛЛИНА**

*Казан федераль университеты, Россия*


# Ф.ӘМИРХАН ДРАМАТУРГИЯСЕНЕҢ ТЕЛ ЧАРАЛАРЫ ҺӘМ АЛЫМНАРЫ


**Аннотация.** В данной статье рассматривается язык персонажа как средство формирования культурной идентичности в творчестве Ф. Амирхана. Материалом послужили эпические и драматические произведения писателя.

**Abstract.** This article examines the language of a character as a means of forming cultural identity in the works of F. Amirkhan. The epic and dramatic works of the writer served as the material



**Ключевые слова:** поэтический язык, литературный язык, диалектизм, арабизм, русизм, интеллигентный человек, характер героя.

**Key words:** poetic language, literary language, dialecticism, Arabism, Russianism, intelligent person, character of the hero.

Әдәби стиль башка стильләрдән тел материалы белән аерыла. Әдәби әсәр фикерләрне, хисләрне, сәнгати образларны белдерә торган чаралардан, ягъни әдәби телдән башка була алмый. Әдәби тел чараларына сүзләр, сүзформалар, грамматик конструкцияләр кирә. Шуның белән берләттән, язучылар диалектизм, жаргонизм, вульгаризм һ.б. әдәби тел нормаларынан чит чараларны да кулланалар. Әмма поэтик тел эстетик функция башкаруы белән аерыла.

Әдәби стиль кешегә эмоциональ тәэсир максатын куя. Л.Н.Папакин "Әдәби текстларның стиль үзенчәлекәре" хезмәтендә: "Әдәби стиль башка функциональ стильләрдән эстетик (поэтик) функциясе белән аерыла. Язучы чынбарлык күренешләрен һәм предметларын образ формасында бирә. Нәкъ менә эстетик (поэтик) функция сүз образларын – әдәби текстның төп категориясен аерырга мөмкинлек бирә"- дип билгели.

Әдәбият нәзариятендә тасвири алымнар һәм чаралар дип стилистик тропларны, лексик чараларны һәм стилистик фигураларны атыйлар. Нәзәрият поэтик чара һәм алымнарны предметлы сурәтләү чарасы, образлылык дөньясын төзү принцибы буларак өйрәнә. Троплар яки күчерелмә мәгънәле сүзләр ассоциатив сурәтләү чаралары дип тә йөртелә. Аларның төрләре шактый күп.

Галимнәр поэтик стильгә түбәндәге сыйфатлар хас дип билгелиләр: авторның һәм сөйләүченең тәңгәл килүе, авторның "минлеге"нең үзенчәекле чагылуы; тел сурәтләү чараларының сәнгати образны, сөйләүченең эмоциональ халәтен, кәефен яктыртуы; метафора, чагыштыру, метонимия һ.б. стилистик фигуралар, фразеологизмнар, эмоционально-экспрессив лексика кулланылу; стильләр төрлелеге, ягъни сәнгати идеяне башкару өчен бүтән стильләрдән (сөйләм, публицистик) файдалану; сүзләр ярдәмендә образлар тудыру, аларга яшерен мәгънә кетү; әдәби стильнең максаты – авторның хисләрен тапшыру, укучыларда кәеф, эмоциональ омтылыш барлыкка китерү.

Ф. Әмирханның "Яшьләр" драмасын укырга керешкәч үк әсәрнең теле чуар икәнлеген аңлашыла. Персонажларның телендә рус, гарәп-фарсы сүзләре һәм гыйбарәләре, ягъни варваризмнар бик күп файдаланыла. Нәкъ менә шул алынмаларның күп булуы сәхнә әсәрен укуны кыенлаштыра, кабул итүдә авырлыклар тудыра. Гарәп-фарсы алынмалары XX гасыр башы татар әдәбияты өчен гадәти күренеш, әмма "Яшьләр"дә рус варваризымыннан башка бер генә җөмлә булмавы сәер тоелырга мөмкин. Шул ук вакытта, бу күренеш авторның кимчелеген түгел, ә образларны тасвирларга ярдәм итә торган лексик чара. Мисал, өчен Газизнең һәм Йосыфның, гомумән, "яшьләр" төркеменә кергән персонажлар теле рус сүзләренә бай. Сүзләрне әйтелештә хаталар һәм хилафлыкар юк. Мәсәлән, *выставка, скандал, замечательно, напрасн, штиблет* һ.б. сүзләр.

Алынмаларның күп булуы “яшьләр”нең рус телен белүләрен, дөньви белемнәргә ия булуын таныта. Рус сүзләренең төрле өлкәләргә каравы да моны кабат дәлилли. Ә аларның эти-әниләренең сөйләмендә гарәп-фарсы алынмалары күбрәк. Мәсәлән, *ләфзы (сүз), тәгъзыйм (олылау), тәхкыйрь (хурлау,мыскыллау)*. Олылар рус сүзләрен куллану очрагында, гыйбарәләрне яраклаштырып, татарчалаштырып әйтәләр: *абразауный, первой сорт, ыстудиннар, ни признют* һ.б. алынмалар. “Фәтхулла хәзрәт” комедиясенең төп герое Фәтхулланың да рус телендә хаталы итеп сөйләшүе ассызыклана. Аның русча сөйләшүе комедияне җанландырып җибәрә, көлке тудыра: “Думуй надо, думуй, тяперче здурув (Әмирхан,1985: 380).

Рус сүзләрен күп куллану тенденциясе Ф.Әмирханның иҗат башында гына күренә, алга таба язучы әсәрләрендәге рус алынмаларын киметә. “Тигезсезләр” психологик драмасында рус алынмалары төп геройларда сирәк кенә очрый. Аларның алынмалары тарихи сүзләр буларак кабул ителә. Тарихи сүзләр аша билгеле бер чор, заман, иҗтимагый тормыш белән бәйле күренешләр ачыла. Мисал өчен *мануфактура магазины, вершок, приказчик, вечер (кичке җыен), дворян-помещик, миссионер* гыйбарәләрен геройлардан ишетергә туры килә.

Рус сүзләре ярдәмче геройлар телендә күп. “Тигезсезләр” драмасындагы Габдулланың, Галиевның рус алынмаларын кулланулары, образларны тискәре яктан күрсәтә. Габдулла туган телен белмәгәнгә, татар телен кимсеткәнгә русча сөйләшә. Аның авызыннан еш кына *татарка, националистка, оканчивающая гимназию* кебек сүзләр ишетелә. Ул татар милләтенең бары тик тискәре итеп тасвирлый. Галиев та башкалар белән: “*Здравствуйте, господа*!” дип исәнләшә, котлауларны русча сөйли: “*Позвольте*, Рөкыя туташ, сезне *поздравить* итеп, шушы *букетны подносить* итргә, *желаю вам, всего наилучшего на жизненном пути*!” (Әмирхан,1986: 346).

Әсәрдә үткен телле Йосыфның сөйләме үзенчәлекле. Ул үзен “аталардан” өстен хис итә, һәр җөмләсендә ирония бар. Моңа басым ясау, әлбәттә, драманың текстында урын ала. Мисал өчен рус теленең авырлыгы турында ул: ”Әгәр телләр выставкасы булып, анда иң авыр телләргә хосусый наградалар бирелә торган булса, минемчә рус теле гран-при алыр иде” (Әмирхан,1985: 262) - ди. Искелек тарафдарларыннан астыртын рәвештә үткен көлә. Фәхерниса апасының эсседә кат-кат киенүенә түбәндәгечә җавап бирә: “Шәлең белән чапаның өстеннән бер кат тун да бөркәнгән булсаң, эсселәмәгән булыр идең” (Әмирхан,1985:268). Өшкертеп дәвалануның акылсызлык икәне: “Бикмөхәммәт хәзрәт зате шәрифнең икенче килүендә, Маһи җиңгәләрең мышаяк өшкертеп

калсыннар. Тычканнар үтерергә замечательный файдалы нәрсә”- җөмләсеннән аңлашыла. Йосыфның сөйләмендә мәзәкләр дә кертелә. Апасының бер генә репликасын да комментарийсыз калдырмый. Ирونияле җавап кайтарып, ул үзенчә искелек вәкилләре белән көрәшә. Аларга сүз ярдәмендә ташлана.

“Фәтхулла хәзрәт” комедиясе гротескка корылып эшләнә. Сәхнә әсәрендә кырык ике ел элек үлгән Фәтхулла хәзрәт терелтелә. Хәзрәткә хас сыйфатлар күпертелеп бирелә. Ул нинди дә булса комик ситуациягә куела һәм кылган эшгамәлләре, сөйләгәннәре белән укучыларда көлке дә, нәфрәт тә тудыра. Фәтхулла хәзрәт ул – сатирик җыелма образ. Ул җәмәгать урыннарында хатын-кыз киемнәреннән чыга, телефонны вата, канат кигән кешеләрдән курка, өшкереп кеше дәваламакчы була һ.б. – болар барысы да арттырылып, күпертелеп бирелә. Ф.Әмирхан әлеге образ аша барлык кадимче, иске фикерлеләрдән явыз итеп көлә.

Язучы антитеза алымы белән Фәтхулла хәзрәтнең тискәре, ә яңа буынның уңай гына сыйфатларга ия булуын чагылдыра. Мисал өчен Ләйлә прогрессны, ирләрнең һәм хатын-кызларның тигез хокуклы булуын яклый. Хәзрәтнең кызларга мутланып бәйләнүен, хатын-кызның ирдән яшеренергә тиеш дип әйтүен кискен рәвештә кире кага. Ләйлә бабасының бәласе динсезлектә, ди (Әмирхан,1985: 396).

Фәтхулла хәзрәтнең, Миңлесылуның һәм яңа чор татарларның капама-каршылыгы персонажларның теленнән, сөйләменнән дә ачыла. Фәтхулла хәзрәткә, Миңлесылуга дорфа сүзләр куллану, сүгенү хас. Алар бер гаепсезгә кешене орышалар. Мәсәлән, бер күренештә Фәтхулла хәзрәт Каюм Насыйриның һәм Риза Фәхретдиновның рәсемнәренә йодрыгы белән һөҗүм итеп, сөйләнә:” Ә шул каһәр сукканнар икән: бусы сукыр Каюм, тегесе Риза казый икән. Ул бәдбәхетләрне голәма миссионерлар дип уйлый иде. Шул, бушка түгел икән” (Әмирхан,1985: 381). Телефоннан шалтыратучыны:” Ах, күзең чыккан нәрсә! Ах, җибрит! Мин, мәсәлән, кеше булмый, нәрсә соң? Атаң башымыни соң? Тукта әле мәлгунь. Мин кызның атасын яшеп китерим монда. Ярсын әле ул кабырганы, пулисәйский чакырып, биреп җибәрсен әле ул син мәлгуньне” – дип ачулана (Әмирхан,1985: 392). Миңлесылу да Нәфисәне, Ләйләне рус кызлары дип уйлап, “бетле маржалар”, “тиле маржалар” дип атый.

“Тигезсезләр” психологик драмасы импрессионизм үрнәге дип алдарак әйтеп үттек. Әсәрдә хис-кичерешләр төрлелеге, монологлар, табигать күренешләре, музыка, тавышлар, төрле төсләр, ягъни импрессионистик алымнар урын алуы моны дәлилли. Биредә вакыйгалыкка бик аз урын бирелә, үзәккә геройларның үзара мөнәсәбәтләрен, хис-тойгылар үзгәрешен сурәтләү алымы куела.

Пәрдәләрдәге вакыйгалар әкрен генә бара. Ремаркаларда табигать күренешләре оста, укучыга тәэсир итерлек итеп тасвирлана. Музыка, әдәбият, сәнгать, табигать авазлары драманың лириклыгын арттыра, психологизмын тирәнәйтә [2, с. 105].

"Тигезсезләр"дә Рөкыянең һәм Сөләйманның сөйләме образлы сүрәтләү чараларына бай булуы белән аерылып тора. Бу күренеш образларның романтик булу белән бәйле. Алар бер-берсе белән хисләре, милләт, сәнгать, әдәбият турында гапләшәләр. Әңгәмәләре аркылы аларның рус һәм татар әдәбияты белән таныш булуын, рәсем белән кызыксынуларын күрәбез.

Ф.Әмирхан әсәрләренең теле бай. Язучы аларны образлылыкны арттыру, тәэсир көчен тирәнәйтү өчен яратып куллана. Тикшерү нәтиҗәсендә драмаларда чагыштырулар, метафоралар, синекдоха, гипербола, эпитетлар барлыгы ачыкланды. Эпитетлар: "*мәхәббәтсез* апа", "*сөекле* сеңлең", "*акылсыз* нәмәрсә", "*кадерле* кызы " һ.б. Әдәби әсәрдә эпитетлар логик сыйфатлау белән генә чикләмиләр, алар экспрессив төсмерле, хисле, күренешкә яки кешегә мөнәсәбәт белдерәләр. "Тигезсезләр" драмасында Рөкыя апасына "мәхәббәтсе апа" дип эндәшә. Шушы атамадан Рөкыя белән Сәлимәнең бер-берсенә каршылыклы мөнәсәбәте ачыла. Чагыштырулар: "*сөт имеп туйган кәҗә бәрәне шикелле*", *"токымнары аз очрый торган орангутан маймылларына караган шикелле*". Ф.Әмирхан әсәрләендә чагыштыру образлары үзенчәлекле. Чагыштыру укучыда нинди дә булса күргәзмәлелек тудыру өчен файдаланыла. Рөкыянең тиктормас, хәрәкәтчән икәнен Гомәрнең "*сөт имеп туйган кәҗә бәрәне шикелле*" чагыштыруы аша күз алдыбызга китерәбез. "Монда яшьләр дә, *ак чәчләр* дә бар" метонимиясе аша "Яшьләр" дә геройлар олылар турында сөйләшәләр.

Гиперболалар "Тигезсезләр"дәге мактанчык, күп сөйләргә яратучы Закир сөйләмендә күп очрый. Ул төрле төрле хикәяләрне арттырып, булмаганнарны өстәп сөйләргә ярата. Һәр хикәясенә "*күз яше белән елый", "туташым чүт еламый гына"* дигән гыйбарәсен кыстырып вакыйганы арттырып җибәрә.

Ф.Әмирхан һәр өч драмасында да геройларының сөйләменә фразеологизмнар да кертә. Фразеологизмнар аша геройның тапкырлыгы, җор теллелеге ачыла. Мисал өчен "*кровь с молоком*", "*ике кулсыз итәсең*", "*кәеф китү" "телгә салыну*", *эч пошу, авыз күтәреп калу һ.б.*

Тикшеренүләргә нигезләнеп, Ф.Әмирханның драматургиясендә урын алган стилистик чаралар, алымнар, троплар, стилистик фигуралар әсәрләрнең поэтик эшләнешенең камиллеген күрсәтә. Язучы төрле алмнар һәм чаралар ярдәмендә әсәрләрнең укучыга тәэсирен көчәйтә. Драмалар аша чорның иҗтимагый халәте, татар теленең торышы күренә.

**ӘДӘБИЯТ**

1. Әмирхан Ф. Әсәрләр. Дүрт томда: 2 т.: Повестьлар роман һәм драма әсәрләре / Ф. Әмирхан. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1985. – 488 б.

2. Ганиева Р. Фатих Әмирхан (1886-1926) // Татар әдәбияты тарихы: сигез томда / [төз. Р.Ф. Рахмани; фәнни мөх. Р.К. Ганиева]. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2016. – Б. 93–107.

3. Папакин Л.Н. Особенности художественного стиля в литературных текстах // Актуальные проблемы гуманитарных и естественных наук. – 2015. – №1–3. – С. 308–311.

4. Язык художественной литературы //Литературная энциклопедия терминов и понятий/ Под ред. А.Н. Николюкина. Институт науч. информации по общественным наукам РАН. Москва: НПК “Интелвак”, 2003. – С. 1257–1263.

**А.А. ХӘМЗИНА**

*Казан федераль университеты, Россия*

## ТАТАР ТЕЛЕ ДӘРЕСЛӘРЕНДӘ МӘДӘНИЯТАРА КОМПЕТЕНЦИЯ ФОРМАЛАШТЫРУ

**Аннотация.** В статье рассмотрена актуальность самой межкультурной компетенции на сегодняшний день, понятие межкультурной компетенции. Также представлен анализ упражнений из учебников, с помощью которых можно сформировать это явление. Вдобавок отображены свои собственные методы и способы для образовния межкультурной компетенции на уроках татарского языка.

**Ключевые слова:** межкультурная компетенция, формирование, культура.

**Abstract.** The article considers the relevance of the intercultural competence today, the concept of intercultural competence. Also is presented an analysis of exercises from textbooks, which this phenomenon can be formed. In addition, are displayed own methods for the formation of intercultural competence in the lessons of the Tatar language.

**Key words:** intercultural competence, formation, culture

Хәзерге вакытта җәмгыять һәм мәгариф өлкәсе үсеше тенденцияләре кеше тормышында мәдәниятара бәйләнешләр көчәюгә юл ача. Мондый шартларда без башка тел вәкилләре белән үзара яхшы элемтә булдырырга тиешбез. Ләкин һәрвакытта да моны уңышлы башкарып чыгып булмый. Шуңа күрә яшь вакыттан ук мәдәниятара компетенция булдыру бик мөһим. Мәктәп укучыларында әлеге компетенцияне формалаштыру хәзерге көндә педагогик теория һәм практиканың актуаль соравы булып тора.

Мәдәниятара компетенция мәсьәләсе татар, рус һәм чит ил галимнәренең күпчелек тикшеренүләрендә өйрәнү предметы булып тора. И.И. Халеева, Н.В. Черняк, Н.М. Громова, Н.Д. Гальскова, Ю. Рот, Р.Д. Льиюс хезмәтләрендә,

И.А. Зимняя, И.Л. Бим, А.А. Леонтьев, Е.С. Полат һ.б. тикшеренүләрендә мәдәниятара компетенцияне оештыру сорауларын, эчтәлек, форма, метод һәм технологияләрне өйрәнүе чагылыш таба.

Мәдәниятара компетенцияне өйрәнү Америка кушма штатларында 1950 елларда башлангыч ала [4, с. 7]. Чит ил мәдәният вәкилләре белән аралашканда барлыкка килгән коммуникатив уңышсызлыклар америка галимнәрендә мәдәниятара компетенцияне өйрәнү өчен сәбәп булып тора [4, с. 7]. Алга таба бу өлкәдә эшләү прогрессив рәвештә бара. 1957 елда Тьюксбери тарафыннан мәдәниятара компетенция термин буларак гамәлгә кертелә [4, с. 8]. 1960–70 елларда аны үлчәү чараларын, методлары һәм формалашканлык дәрәҗәсен бәяләүдә актив эшләнә. 1984 елда Б. Шпицберг һәм У. Кьюпач компетенцияне беренче тапкыр эффектив һәм яраклы тотыш дигән караштан тасвирлыйлар һәм аралашуда катнашкан ике якны да исәпкә алалар. 2010 елга хәтле мәдәниятара компетенция чит тел мәдәниятенә кергәч, үзеннән үзе үсә дигән карашлар яшәгән. Ләкин П. Педерсен бу процесс белән генә компетенцияне формалаштырып булмый дигән карашын эксперимент белән дәлилли [4, с. 12]. 1990 елларда мәдәниятара компетенция чит телләргә өйрәтү методикасында мөһим урын ала башлый [4, с. 14]. 2000 еллар башында бөтен илләр буенча университетларда мәдәниятара аралашу проблемаларына багышланган курслар ачыла [4, с. 16]. Шушы ук елларда мәдәниятара компетенция безнең илдә дә актив өйрәнелә башлый.

Мәдәниятара компетенция булган белемнәрне, күнекмәләрне, күрсәтмәләрне һәм мәдәниятара бәйләнешләр нәтиҗәләрен эффектив (макстака ирешү күзлегеннән) һәм яраклы (коммуникация буенча партнерның өметләрен аклау күзлегеннән) рәвештә үз-үзеңне тоту [4, с. 37].

Мәдәниятара компетенцияне формалаштыру һәм үстерү мәсьәләләре Федераль дәүләт белем бирү стандартларында да урын ала. Мәсәлән, шәхси нәтиҗәләргә “башка кешегә карата, аның фикеренә, дөньяви карашына, мәдәниятенә, теленә, гражданлык позициясенә, Россия һәм башка халыклар тарихына, мәдәниятенә, диненә, традицияләренә, телләренә, кыйммәтләренә аңлы, ихтирамлы һәм изгелекле мөнәсәбәтен; башка кешеләр белән диалог төзү әзерлеген һәм сәләтен формалаштыру һәм анда үзара аңлашуга ирешү”. Стандартта укучыларда дөньяга тулы караш тәрбияләү һәм формалаштыру кирәклеге ассызыклана. Ул үз чиратында заманча дөнья үсешен, аның социокультур күптөрлелеген аңлауга нигезләнгән.

Татар теле дәреслекләрендә мәдәниятара компетенцияне формалаштыру һәм үстерү өчен күнегүләр шактый аз күләмдә бирелгән. Шуны да әйтергә

мөмкин, турыдан-туры мәдәниятара компетенцияне булдыру өчен аерым күнегүләр юк диярлек, ә бары тик кайбер биремнәр белән үрелеп китерелә. Шуңа күрә кутучы күнегүләргә үзе билгеле бер өстәмә биремнәр кертергә дә мөмкин.

Рус телендә урта гомуми белем бирү мәктәпләрендә татар телен туган тел буларак өйрәнүче балалар өчен дәреслекләрдә әлеге компетенцияне формалаштыруга төрле күнегүләр һәм биремнәр бирелгән. Мәсәлән, 9 сыйныф дәреслегендә 19 нчы күнегүдә “Татар халкының нинди милли уен кораллары булган? Синең дәү этиең, карт бабаң берәр уен коралында уйный белгәнме? Синең курайны, гармунны тотып караганың бармы?” дигән сорау куела. Бу рус балаларында татар халкының сәнгатенә кызыксыну уятырга тиеш. Шул рәвешле укучылар телне генә түгел, мәдәниятне дә өйрәнәләр [3, б. 13]. Шулай ук текстлар тәрҗемә итү, башка халыкның танылган вәкилләренең фикерләрен уку, картиналары буенча сочинение язу да чит мәдәниятне өйрәнер өчен ярдәмгә килә [3, б. 9, 70, 136].

Уку әсбапларында башка халыкларның холкын, тәрбия моментларын, мәдәниятен чагылдырган текстларны очратырга мөмкин. Бу укучы балаларда чит ил вәкилләре белән яхшырак элемтә корырга этәргеч бирә [3, с. 41].

“Татарстан” нәшриятында басылган 7 нче сыйныф дәреслегендә 229 нчы күнегү укучыларга толирантлык турында текст бирелә. Биредә телләрнең тигезлеге, милләтара ихтирамлылык турында сүз бара. Тексттан соң балаларга “Үзара татулык, ихтирам нәрсәдән башлана?” дигән темага әңгәмә оештырырга тәкъдим ителә [2, б. 126].

Ләкин мәдәниятара компетенцияне үстерү өчен бу күнегүләр генә җитми. Шуңа күрә укытучы үзлектән биремнәр, төрле грамматик уеннар уйларга мәҗбүр.

Укытучы дата белән бәйле шул көнне берәр төрле халыкта нинди бәйрәм үткәнен сөйләп китергә мөмкин. Мәсәлән, 23 апрельдә Төркиядә Балалар яклау һәм милли бәйсезлек көне билгеләп үтелә. Бу көнне балалар дәүләт хезмәткәрләрен эш урыннарында алмаштыралар. Шул рәвешле укучылар төрекләрнең генә түгел, башка халыкларның милли бәйрәмнәре белән танышырга мөмкин.

Балаларга мәдәниятара компетенцияне формалаштырыр өчен грамматик уеннар бигрәк тә ныграк тәэсир итәргә мөмкин. Бу очракта мондый уеннар тәкъдим итеп була. Төрле милләт исемнәрен һәм уен коралларын карточка формасында эшләп, укучыларга таратырга кирәк. Аларның максаты – кайсы

уен коралы нинди халыкка туры килгәнлеген билгеләү. Шундый ук биремне тарихи истәлекләр, танылган кешеләр белән дә башкарырга мөмкин.

Компетенцияне үстерү өчен диалог та мөһим роль уйный. Туристлар, чит ил кешеләре, башка халык вәкилләре белән әңгәмә корырга, итәгатьлелек, ихтирамлык белдерергә өйрәтүне шулай ук читләп узмаска кирәк.

Тагын бер мөһим момент: һәрбер халыкның үзенең ишарәләре бар. Бер мәдәнияттә кулланылган ишарә, башкасында гомумән бөтән мәгънә белдерергә мөмкин. Шул рәвешле аларны бераз булса да өйрәтү шулай ук комачауламас. Укучыларга видеоязмалар күрсәтү яки презентация форматында аңлату уңай нәтиҗәләр бирәчәк.

Шулай итеп мәдәниятара компетенцияне формалаштыру һәм үстерү укучыларда кызыксынучанлыкны үз милләтенә түгел, ә башка мәдәниятләргә дә уятуга нигез булып тора. Алар шул рәвешле чит халыкларның вәкилләре белән аралашырга, аларны хөрмәт итәргә өйрәнәләр.

### ӘДӘБИЯТ

1. Закиев М.З. Татарский язык. Учебник для общеобразовательных организаций с обучением на татарском языке 9 класс / М.З. Закиев, С.М. Ибрагимов. – Казань: Татарское книжное издательство, 2015. – 135 с.

2. Максимов Н.В. Татарский язык. Учебник для общеобразовательных организаций с обучением на татарском языке 7 класс / Н.В. Максимов, Г.А. Набиуллина. – Казань: Татарское книжное издательство, 2015. – 159 с.

3. Сагдиева Р.К. Татарский язык. Учебник для общеобразовательных организаций основного общего образования с обучением на русском языке (для изучающих татарский язык как родной) 7 класс / Р.К. Сагдиева, Э.Х. Кадирова. – Казань: Магариф-Вакыт, 2017. – 143 с.

4. Черняк Н.В. Межкультурная компетенция: история исследования, определение, модели и методы контроля / Н.В. Черняк. – М.: Флинта, 2016. – 264 с.

**Ф.Ф. ХАРИСОВ**

*Казан федераль университеты, Россия*

## ТЕЛГӘ ӨЙРӘТҮДӘ ИНТЕРНЕТ ТЕХНОЛОГИЯЛӘРЕНЕҢ РОЛЕ

**Аннотация.** В статье рассматриваются возможности использования интернет-технологий при обучении родному и неродному языкам.

**Ключевые слова:** интернет, технология, татарский язык, сайты

**Abstract.** Possibilities of using Internet technologies in teaching native and non-native languages are described in this study.

**Key words:** nternet, technology, Tatar language, sites

Ана телләр һәм чит телләр укыту методикасында аралашу, телне мәдәнияткә бәйләп интерактив формада өйрәнү соңгы елларда бик активлашты. Өйрәнелә торган телдә аралашу өчен, тормышчан вакыйгаларга туры килә торган ситуацияләр булмаса, кирәкле нәтиҗәгә ирешеп булмый. Бу уңайдан интернетны тиешенчә файдалану укытучыга һәм укучыга зур мөмкинлекләр ача.

Аксиома кебек: компьютер – интернеттан, интернет компьютердан башка яши алмый, чөнки интернет – компьютер челтәренең глобаль күләмдә берләшкән системасы. Ул мәгълүмати һәм аралашу вазифаларын үти. Анда төрле биремнәрне үтәү мөмкинлекләренең чиксез булуын һәр кеше аңлый. Тик шулай да чынбарлык шуны күрсәтә: яңа мәгълүмати чаралар булу барлык проблемаларны да хәл итеп бетерә алмый эле. Димәк, дидактик бурычларны, укучыларның танып белү үзенчәлекләрен, укыту-өйрәтүнең аерым максатларын да онытмаска кирәк. Интернет – шуларның барысын да тормышка ашыра ала торган бик кирәкле заманча чара. Ул өйрәнелә торган тел вәкилләре белән аралашу мөмкинлеген тудыра, тел белән кызыксынуны көчәйтә, укучыларның сөйләмен чарлый. Димәк, интернетны куллану алдыннан, аның кайсы дидактик мәсьәләне чишү өчен әһәмиятле булуы турында да ныклап уйларга кирәк. Моннан тыш интернет – аутентик текстларны өйрәнгәндә кирәкле булган табигый тел мохите барлыкка китерә торган чара да.

Укучы нинди генә юнәлештәге белем бирү оешмасында укуына карамастан, интернет – аңа төрле мәгълүматны эзләүдә һәм аны кулланырга өйрәнүдә беренче ярдәмче. Хәзер интернетта татар телендә язылган белешмәләр дә бик күп очрый. Димәк, кем белән булса да хезмәттәшлек итәсең килә икән, интернет белән дус булырга кирәк, ә бу, үз чиратында, төрле телләр өйрәнүне таләп итә. Әлеге чынбарлык белән, билгеле, килешергә туры килә, чөнки ЮНЕСКО бу гасырны «полиглотлар гасыры» дип игълан итте. Мәгълүматлаштыру чорында иң кыйммәтлесе – мәгълүматны табу һәм аны куллана алу, ә бу исә берничә телне белгәндә отышлырак була.

Чит телне өйрәтүнең үзенчәлеге шунда: аның нигезен сөйләм эшчәнлеге төрләренә – тыңлап аңлауга, сөйләүгә, уку һәм язуга өйрәтү тәшкил итә. Боларның барысына да эшләп карау нәтиҗәсендә ирешергә мөмкин. Аны тормышка ашыру өчен, укучыга үзе яхшырак үти алган сөйләм эшчәнлеге төренә караган биремнәр тәкъдим итәргә була. Тел өйрәнү ахыр чиктә сөйләшергә өйрәнү белән бәйле. Димәк, бу вакытта укучыга телдән үтәлә торган күнегүләрне күбрәк бирү максатка ярашлы була. Аларны үтәү өчен, әңгәмәдәш кирәк, чөнки чын-чынлап аралашырга өйрәнү фәкать җанлы сөйләм аша гына

үзләштерелә. Бу вазифаны өлешчә компьютер программасы үти ала, шулай ук аның ярдәмендә өйрәнелә торган телдә сөйләшә белгән башка берәү белән дә гамәлгә ашырыла. Моның өчен телне өйрәнүнең лингвокультурологик мөмкинлекләрен дә истә тоту зарур. Укучыга өйрәнелә торган телдә сөйләшүчеләрнең рухи байлыклары турында мәгълүмат бирү мөмкинлеге дә игътибардан читтә калмаска тиеш. Яшь буын халыклар арасындагы мәдәни багланышларның кирәклеген тоеп үссен һәм бу турыда белем алсын иде. Әлбәттә, әлеге бурычларны дәреслекләрдәге материаллар да өлешчә үти. Укытучы аларны тиешенчә сайлап алып, балаларга белем һәм тәрбия бирерлек итеп, кирәкле урында файдаланырга тиеш.

Татар телен өйрәнгәндә, интернеттан файдалану укытуны интерактив формада алып баруны таләп итә. Аралашуның максаты белән ахыргы нәтиҗәнең сөйләм чаралары ярдәмендә берләшүе, бер-берсенә җайлашуы һәм бер-берсен тулыландырып торуы «интерактивлык» дип атала. Телне чынбарлыктагыча өйрәтүдә, сөйләм теленә караган күнекмәләр алуда һәм осталыкка ирешүдә, шулай ук сүзләрне һәм грамматиканы үзләштерүдә интернетның әһәмияте зур: ул укучыларда табигый кызыксыну уята, шуның белән бергә укытуның нәтиҗәлелеген дә арттыра.

Интернет мөмкинлекләрен телне өйрәнгәндә куллануның максатлары түбәндәгеләр:

- ❖ интернет материалларын дәрес эчтәлегенә кертү;
- ❖ яңа материалны нәтиҗәле итеп өйрәнү;
- ❖ телне өйрәнгәндә үтелми калган темаларны кабатлау һәм ныгыту;
- ❖ проект эшләгәндә, кирәкле мәгълүматны мөстәкыйль рәвештә эзләп табу;
- ❖ укытучы җитәкчелегендә телне системалы итеп, дистанцион формада өйрәнү;
- ❖ имтиханга мөстәкыйль рәвештә әзерләнеп, аны экстернат формасында тапшыру һ. б.

Боларның барысы да телне өйрәнүнең аралашу максатын күзаллый, өйрәнү предметының – бу очракта телнең – үзенчәлекләрен истә тота, Интернет кайсы дидактик принципларны тормышка ашырганда нәтиҗәлерәк булуын ачыкларга ярдәм итә һәм аны файдалы итеп кулланырга мөмкинлек тудыра.

Хәзер интернетны укыту чарасы буларак куллану мөмкинлекләре турында да бераз мәгълүмат бирик.

Дәрес вакытында укытучы турыдан-туры интернетка керә алмаска да мөмкин, чөнки әлегә белем бирү оешмаларының барысы да дөнья челтәренә то-

таштырылып бетмәгән. Кайбер укытучылар татар теле һәм әдәбияты кабинетында бер компьютер булса да, аны уңышлы файдаланырга тырышалар. Шәһәрдә һәр гаиләдә дә интернетка керү мөмкинлеге бар. Укытучы, әлбәттә, үз эшендә әлеге мөмкинлекне истә тотарга тиеш. «Дәрестә аннан ничек файдаланып була?» дигән сорау туа. Аның җавабы катлаулы түгел кебек, бары тик тавыш җайланмаларының компьютерга тоташкан, кирәк булган очракта аралашучыларны күрү һәм видеоконференцияләр үткәрү өчен, видеокамераларның булуы шарт. Димәк, теоретик яктан караганда, телне белүчеләр белән аралашу өчен, компьютерны файдалану зур проблема тудырмый.

Татар сайтларының күп булуы *(http://www.tatknigafund.ru; http: //belem.ru; http://www.tatar-inform.ru; tazbash.ru; kitap.net.ru; anatele.ef.com; http://balarf.ru; http: //ggulnaz.jimdo.com; http://ras2203.narod.ru; /http://tatarz.ru; http://adiplar.narod.ru; http://tatarplanet.ru; tatarskii-yazyk; http://www.tatarmultfilm.ru; http://tatarschool.ru; http://xat.ru; http://suzlek.ru; http://minem.pochta.ru – татар телендә IT; http://tugan-tel.at.tt; http://www.ite.antat.ru; http://kitapxane.at.tt; http://tatar.com.ru; http://www.tatr.ksu.ru; http: //tatarinform.ru h. б.)* укытучы һәм укучылар өчен интернеттан төрле эчтәлектәге текстлар, язма һәм тавышлы мәгълүмат табу мөмкинлеген тудыра. Шулай ук интернеттан рус телендәге материалларны файдалану аеруча рус телендә сөйләшүче укучылар белән эшләгәндә уңышлы булачак. Чит телләр методикасында шушы мөмкинлекләрдән файдалану телне өйрәнүдә шактый отышлы булып санала, чөнки интернет челтәре белем бирүне нәтиҗәле оештыруда киң мөмкинлекләр ача. Алар түбәндәгеләр:

❖ кирәкле мәгълүматны төрле чыганаклардан тиз генә эзләп табу (тапкан мәгълүматны чагыштырып карау мөмкинлеге булу);

❖ укучыларның сөйләм телен үстерү өчен, үз компьютерында яки мәктәпнекендә аутентик материалны алдан әзерләп кую;

❖ компьютерда тавышны яздыру мөмкинлеге булган очракта, төрле кызыклы шәхесләрнең, язучыларның, сәнгать әһелләренең чыгышларын укучыларга алдан яздырып тыңлату;

❖ алынган хәбәрләр яки эшләнә торган проект турында укучыларны иптәшләре белән фикер алышуда электрон почта аша элемтәгә кертү;

❖ интернеттан алынган һәм бөтен сыйныф өчен кызыклы дип саналган мәгълүмат турында фикер алышу, әңгәмә оештыру;

❖ лингвокультурологик эчтәлеккә ия булган фразеологизмнар, мәкаль һәм әйтемнәр кергән өзекләр, шулай ук аерым шәхесләрнең телдән яки язмача текстлары белән танышу, аларга лингвистик анализ ясау;

❖ виртуаль китапханәләрдән алынган әсәрләрдән өзекләр укып, алар турында фикер алышу, төрле проектлар эшләү һәм дискуссияләр үткәрү;

❖ презентация, башка уку материалларын һәм ярдәмлекләрен күрсәтү;

❖ иптәшләре белән тиз генә, аз вакыт эчендә тапкан мәгълүмат турында фикер алышу.

Интернетны дәресләрдә файдалану мөмкинлекләре югарыда саналганнар белән генә чикләнми, әлбәттә. А.А. Леонтьев фикеренчә, педагогик технологияләрне ятлап бетерү мөмкин түгел. Шуңа күрә интернетны укучылар өчен ничек файдалы итү турында бары тик иҗади эзләнеп эшләүче һәм югары һөнәри осталыкка ия булган укытучылар гына тулырак итеп әйтә алыр.

Шунысын да ассызыкларга кирәк: интернетның уңай яклары күп булуына карамастан, кимчелекләре дә аз түгел:

❖ интернет челтәрендә тикшерелмәгән яки дөрес булмаган мәгълүматның күп булуы (фактик, орфографик һәм стиль хаталары һ. б. Шуңа күрә аларны файдаланганда сак булырга, башка чыганаклар аша тикшереп карарга кирәк);

❖ челтәрдә озак утыруның нәтиҗәсе – сәламәтлеккә зыян килү;

❖ дошманлык, бер-береңне күрә алмау, башкаларга нәфрәт уяту;

❖ кешеләр белән турыдан-туры аралашу мөмкинлеге булмау.

**ӘДӘБИЯТ**

1. Селевко Г.К. Современные образовательные технологии: Учебное пособие / Г.К. Селевко. – М.: Народное образование, 1998. – 186 с.

2. Сулейманов Д.Ш. Татарский язык и новые образовательные технологии // Языковая ситуация в РТ: Состояние и перспективы. – Казань, 1999. – Часть 1. – С. 138–143.

3. Харисов Ф.Ф. Татар теле: укыту теориясе һәми практикасы / Ф.Ф. Харисов. – Казан: Ак Бүре, 2018. – 448 с.

**Г.Ф. ХАРИСОВА**
*ОШИ «Лицей имени Н.И. Лобачевского» КФУ, Россия*

# РАЗВИТИЕ КРЕАТИВНОГО МЫШЛЕНИЯ НА УРОКАХ РОДНОГО ЯЗЫКА И РОДНОЙ ЛИТЕРАТУРЫ (ИЗ ОПЫТА РАБОТЫ ОШИ «ЛИЦЕЙ ИМЕНИ Н.И.ЛОБАЧЕВСКОГО» КФУ)

**Аннотация.** В статье изучается вопрос сущности креативного мышления в аспекте развития навыков функциональной грамотности обучающихся. Рассматриваются эффективные технологии, методы, приемы и формы работы по развитию креативного мышления обучающихся на уроках родного языка и родной литературы.

**Ключевые слова:** функциональная грамотность, креативность, креативное мышление, творческое мышление, родной язык, родная литература.

**Abstract.** The article examines the issue of the essence of creative thinking in the aspect of the development of functional literacy skills of students. Effective technologies, methods, techniques and forms of work on the development of creative thinking of students in the lessons of their native language and native literature are considered.

**Keywords:** functional literacy, creativity, creative thinking, creative thinking, native language, native literature.

В последние годы остро обозначилась потребность общества в воспитании и обучении творческих людей, имеющих нестандартный взгляд на проблемы, способных адекватно и своевременно реагировать на происходящие в мире изменения. В «Концепции модернизации Российского образования на период до 2020 года» акцентируется внимание на развитии креативных способностей учащихся, индивидуализацию их образования с учетом интересов и склонностей к творческой деятельности [1].

Креативное мышление – это способность продуктивно участвовать в процессе выработки, оценки и совершенствовании идей, направленных на получение инновационных и эффективных решений, и/или нового знания, и/или эффектного выражения воображения.

Задания на формирование креативного мышления условно можно разделить на такие два вида:

– задания на вербальное самовыражение (письменное или устное словесное самовыражение);

– задания на визуальное самовыражение (изобразительное и символическое самовыражение).

Задания на вербальное самовыражение (письменное самовыражение) предполагают: 1) создание свободных высказываний и текстов; 2) выдвижение идей для создания текстов на основе рассмотрения различных стимулов, таких как фантастические иллюстрации, рисованные мультфильмы без заголовков, или ряд абстрактных картинок; 3) оценку креативности приводимых высказываний, например, заголовков, историй, лозунгов, и т.п. 4) совершенствование собственных или чужих текстов.

Задания на визуальное самовыражение включают в себя: 1) выдвижение идей для своих проектов на основе заданного сценария и исходных установок (например, на тех деталях, которые должны быть включены в проект, или тех инструментах или способах, которые необходимо использовать); 2) оценку креативности собственных или чужих идей с позиций их ясности, привлекательности или новизны; 3) совершенствование изображений в соответствии с данными инструкциями или дополнительной информацией.

В структуру уроков родного языка и родной литературы необходимо включить все виды заданий по формированию креативного мышления. Родной язык, выполняя свои базовые функции общения и выражения мысли, обеспечивает межличностное и социальное взаимодействие людей, участвует в формировании сознания, самосознания и мировоззрения личности, Высокий уровень владения родным языком определяет способность аналитически мыслить, успешность в овладении способами интеллектуальной деятельности, умениями убедительно выражать свои мысли и точно понимать мысли других людей, извлекать и анализировать информацию из различных текстов, ориентироваться в ключевых проблемах современной жизни и в мире духовно-нравственных ценностей [2].

Как средство познания действительности, родной язык обеспечивает развитие интеллектуальных и творческих способностей ребенка, развивает его абстрактное мышление, память и воображение, формирует навыки самостоятельной учебной деятельности, самообразования и самореализации личности. Обучение родному языку совершенствует нравственную и коммуникативную культуру ученика [2].

Согласно учебному плану ОШИ «Лицей имени Н.И. Лобачевского» КФУ предметная область «Родной язык и родная литература» включает такие предметы: родной (русский) язык, родная (русская) литература, родной (татарский) язык, родная (татарская) литература. Преподавание данных предметов осуществляется на основании заявления родителей (законных представителей) (6–9 классы) или самих обучающихся (10–11 классы).

В федеральном государственном образовательном стандарте всех ступеней образования доминирующим компонентом организации образовательного процесса является практико-ориентированная, исследовательская и проектная деятельность, основанная на проявлении самостоятельности, активности, творчестве учащихся. Одним из приоритетных направлений работы с учащимися в данной системе является организация проектно-исследовательской деятельности, главная цель которой – активизировать обучение, придав ему исследовательский, творческий характер. Федеральный государственный образовательный стандарт основного общего образования указывает на необходимость формирования у учащихся навыков исследовательской работы, к которым относится «выдвижение гипотез, осуществление их проверки, владение приемами исследовательской деятельности, умениями прогноза, самостоятельного создания алгоритмов познавательной деятельности для решения задач творческого и поискового характера, формулирование полученных результатов» [3]. Опыт работы в данном направлении показал, что детские открытия возможны, учебное исследование, хотя отличается своей масштабностью от научных открытий, ценится как возможность развития творческого мышления учащихся. В центре исследований считаем необходимым давать задания учащимся, связанные, как правило, с программным материалом. Чтобы создать оптимальные условия для творческого самовыражения ребенка в исследовательской практике, мы вовлекаем учащихся в эту деятельность не только по желанию. В саму систему уроков по родному языку, развитию речи включаются элементы организованного индивидуального и группового поиска знаний, фрагменты микроисследований ребят.

Решением учебно-методического объединения учителей родного языка и литературы Лицея основной формой промежуточной аттестации обучающихся по предметам «Родной язык» и «Родная литература» является защита проектно-исследовательских работ. При этом оценивается как качество выполнения проектного задания, так и представление результатов проекта перед классом. Предпочтение отдается качественной доброжелательной оценке, позволяющей учащемуся учесть результаты предыдущей оценки для создания более качественного продукта.

В первой четверти учитель знакомит учащихся с тематикой научно-исследовательских работ (по программе), с основными требованиями к написанию и оформлению работ. В конце первого полугодия ученики сдают зачет по введению, т.е. научному аппарату исследования. Уже тогда можно выделить

наиболее успешные проекты, которые будут представлять свою работу на различных научно-практических конференциях учащихся.

*Примерные темы проектных работ в 2020–21 учебном году:*

*6-й класс*

1. Составьте “Поэтический орфоэпический словарь”: подберите фрагменты стихотворений, в которых ритм и рифма подсказывают правильное произношение трудных с точки зрения орфоэпии слов русского языка.
2. Подготовьте учебный проект на тему “Происхождение фамилий учеников нашего класса”.
3. Найдите русские пословицы и поговорки, включающие числительные. Какие числительные чаще всего в них упоминаются? Как вы думаете, почему? Подготовьте проект на тему “Имена числительные в русских пословицах и поговорках”.

*7-й класс*

1. Проведите опрос одноклассников и соберите информацию о паронимах, которые чаще всего приводят к смысловым ошибкам в их речи. Подготовьте памятки к этим словам (тема «Трудные случаи употребления паронимов).
2. Используя поэтические тексты русского языка, определите, какой образ – луны или месяца – чаще всего используется в русской поэзии. Какие поэты чаще обращались к этой теме?
3. Подготовьте проект об изменении названий русских городов. Используйте материалы словарей, Интернета и лингвистических заметок.

*8-й класс*

1. Проект на тему «Новые иностранные слова в дисплейных текстах».
2. Особенности обращения на «Ты» и «Вы» в русском языке, и история их формирования.
3. Русский этикет в пословицах и поговорках.

*9-й класс*

1. Образ березы как ключевой образ русской литературы.
2. Новые крылатые слова русского языка из современных мультфильмов (из современной рекламы, из современных теле- и радиопередач)».
3. Русский язык в Интернете.

Ежегодно ученики Лицея участвуют на научно-практических конференциях, учатся выступать перед аудиторией, принимать активное участие в работе конференций.

В 2020–21 учебном году на V Всеросcсийской (с международным участием) конференции Н.И. Лобачевского по дисциплине «Родной язык и родная ли-

тература» принимали участие ученицы 8-го класса Паткина Дарья и Яковлева Анастасия и стали победителями и призерами. На XVI Республиканских Кирилло-Мефодиевских научных чтениях принимали участие два ученика – Польский Марк (призер) и Зейналова Софья (победитель). На X Всероссийской научно-практической конференции «Татарский язык и литература: прошлое, настоящее и будущее» ученица 7В класса Хабибуллина Камиля стала победителем. В 8-м классе на уроках родной литературы особое внимание уделяется изучению истории своего рода, итогом этой работы является составление родословного дерева – Шәҗәрә. В этом учебном году самый успешный проект Шамсутдиновой Малики отправили на XI Межрегиональный конкурс творческих и проектных работ «Династии России», ее работа была удостоена Диплома II степени.

Для развития креативного мышления на уроках также используем творческие задания, например, нарисовать рисунок по прочитанному произведению. На уроке родной русской литературы в 6-м классе после изучения темы «Красота родного края в стихотворении Н. Языкова «Две картины» учащимся было предложено нарисовать две картины, которых они представили после прочтения и анализа стихотворения. На уроке родной татарской литературы в 7-м классе после изучения фольклорного произведения «Сак-Сок» учащиеся составили план произведения в виде рисунков: получилась образный план-картина произведения «Сак-Сок».

Процесс развития креативного мышления учеников идет непрерывно и систематически, на каждом уроке. Особую роль играют в этом уроки развития речи. Например, по предмету «Родная русская литература» в 6-м классе согласно календарно-тематическому плану проводятся уроки развития речи на следующие темы: Сочиняем сказку. «Два окошка! Мы ждем вас!» «Мы в ответе за тех, кого приручили». Сочинение на тему «Прости нас, Чучело!». История Великой Отечественной войны – наша история.

Уникальное средство развития креативности – детские творческие работы: сочинения, сказки, переводы текстов с одного языка на другой, инсценированные сказок. Например, в 6-м классе после изучения темы «Литературные сказки» каждый ученик сочинил сказку, и мы оформили ее в виде электронной книжки.

В прошлом учебном году в 7-м классе после изучения темы «Жизнь и творчество Мусы Джалиля» ученики перевели понравившиеся стихотворения поэта на русский язык. Самый удачный вариант отправили на Международный

конкурс «Звезда Джалиля». Ученица 8В класса Сеньчукова Агния стала победителем в номинации «Пусть звучит Джалиль на разных языках».

Следует отметить то, что ребята с удовольствием вовлекаются в процесс творчества, если тема сформулирована конкретно и оригинально, что позволяет каждому раскрыть свои представления о мире, найти более близкий и знакомый образ, то есть детям предоставляется свобода в отборе содержания. В постоянно меняющемся сложном мире очень важно формировать у учеников креативность, так как она является одной из основных функциональных компетенций будущего.

**ЛИТЕРАТУРА**

1. «Концепция модернизации Российского образования на период до 2020 года» [Электронный ресурс]. – http://static.government.ru/media/files/mlorxfXbbCk.pdf

2. Примерная программа по учебному предмету «Русский родной язык» для образовательных организаций, реализующих программы основного общего образования (протокол от 31 января 2018 года №2/18) [Электронный ресурс]. – https://nsportal.ru/sites/default/files/2019/01/12/primernaya_programma_po_uchebnomu_predmetu_russkiy_rodnoy_yazyk.pdf

3. Федеральный государственный образовательный стандарт основного общего образования [Электронный ресурс]. – https://fgos.ru/

**И.М. ХИСМӘТУЛЛИНА**

*Казан федераль университеты, Россия*

## ТАТАР ТЕЛЕНДӘ КИСӘКЧӘЛӘРНЕ ӨЙРӘНҮ ТАРИХЫ

**Аннотация.** Мәкалә татар телендә модаль-экспрессив төсмер өсти торган үзенчәлекле ярдәмлек сүз төркеме – кисәкчәләрне өйрәнүгә багышланган. Кисәкчәләрне өйрәнүгә бәйле лингвистикада һәм татар теле гыйлемендә бу өлкәдә эшләгән галимнәрнең хезмәтләренә күзәтү ясала. Хәзерге вакытта модаль сүз төркемнәре эчендә каралучы кисәкчәләрнең семантик төркемнәре хакындагы карашларга күзәтү бирелә.

**Ключевые слова:**модальлек, сүз төркеме, кисәкчә, семантика, төркемчә.

**Abstract.** The article is devoted to the study of particles - a special group of auxiliary words that give the Tatar language a modal expressive tone. In the field of linguistics and Tatar linguistics related to the study of particles, the work of scientists

working in this field is considered. The concepts of semantic groups of particles, which are currently considered in modal groups of words, are considered.

**Keywords:** modality, part of speech, particle, semantic group, division.

Татар теленең әдәби төзелешен, сүз төркемнәрен өйрәнү тел белемендә бай тарихка ия. Илленче елларда В. В. Виноградов тарафыннанөйрәнелә башлаган модальлекне белдерү юллары , модальлек категориясе турында тикшерүләр яңа юнәлеш булып тора. Лингвистикадамодальлекнең күләме һәм эчтәлеге, эмоциональ- экспрессив мөнәсәбәтләрне тәшкил иткән тел чараларын аерып чыгару, модаль мәгънәләрне дифференциацияләү, аларны белдерү юллары һәм башка мәсьәләләр турында фикер алышы башлана.

Модальлек проблемаларының мөһим теоретик нигезләмәләре А.М. Пешковский, П.Г. Зыков, В.З. Панфилов, Н.Ф. Шведова, Г.А. Золотова, Т.М. Ломтева, Ю.С. Степанов хезмәтләрендә урын алган.Тюркологиядә модальлекнең төрле аспектлары Н.К. Дмитриев, А.Н. Кононов, Н.А. Баскаков, Б.А. Серебренников, М.З. Закиев, Н.З. Гаджиева, Ф.А. Ангели, Р.Г. Сибагатов, Д.Г. Тумашева, Р.Г. Минниахметов һ.б. галимнәрнең хезмәтләрендә каралган.

Модальлек проблемасы буенча булган хезмәтләрне анализлау, гомумән алганда, телнең модальлек табигатенә берничә караш барлыгын күрсәтә. Төп бүленеш түбәндәгечә:

1. Модальлек – сөйләмнең реаль яки реаль булмавын тасвиралаган грамматик категория дигән фикер киң таралган. Шушы нигездә модальлек эчтәлекнең чынбарлыкка мөнәсәбәте буларак билгеләнә.

2. Башка карашлар буенча, модальлек сөйләүченең чынбарлыкка карата грамматик яктан мөнәсәбәтен чагылдырырга мөмкин. Шул ук вакытта чынбарлык сөйләмнең бөтен элементларын да үз эченә ала: автор, семантика, синтактика, адресат, сөйләм шартлары һ.б.

3. Кайвакыт модальлектабигате фикерләүгәбәйле карала. Бу очракта тел модальлегефикер модальлегетөшенчәсенә тигезләнә.

4. Модальлекпроблемасынлингвистика, мантыйк һәм фәлсәфә нигезләмәләренә таянып хәл итәргә кирәк дигән фикер дә бар.

Татар галимнәре хезмәтләрендә телдә модальлекнебелдерү чараларына: заман, зат кушымчалары, аерым җөмлә конструкцияләре, кисәкчәләр, ымлыклар, интонация, сүз тәртибе, кереш сүзләр кертеп карала. Модальлекне белдергән ярдәмлек сүз төркемнәре: модаль сүзләр һәм кисәкчәләр тюркологиядә шактый аз өйрәнелгән. Татар тел белемендә кисәкчәләр Г. Алпаров, Җ. Вәлиди, В.Н. Хангилдин, Ф.С. Сафиуллина, Ф.А. Ганиев, М.А. Сагитов, Э.М. Латыйпов,

Р.Г. Минниахметов тарафыннан өйрәнелеп, галимнәр әлеге сүз төркемнәренә бәйле төрле карашларын белдергән.

Шулай ук Ф.Ә. Ганиев фикере буенча кисәкчәләр тамыр һәм ясалма кисәкчәләргә бүленәләр. Ясалма кисәкчәләр конверсия ысулы белән рәвешләрдән, алмашлыклардан, фигыльләрдән һәм бәйлекләрдән ясалалар. Алар үзләренең структурасы һәм функцияләре буенча үзләре килеп чыккан сүзләрне бик нык хәтерләтәләр, шуңа күрә аларны бер-берсеннән аеру шактый кыен. Бу мәсьәләдә кисәкчәләрнең семантикасы, җөмләдәге урыны төп критерий булып тора.

Кисәкчәләрнең семантикасына килгәндә, "Татар грамматикасы"нда кисәкчәләр мәгънәләре буенча дүрт төркемгә бүленәләр: 1) логик-мәгънәви: *нәкъ, гына-генә/кына-кенә, бары, тик, фәкать, исә* һ.б.; 2) модаль һәм модаль ихтыяри: *һич, ни, мы/ме, мыни/мени, әллә, дыр-дер/тыр-тер, сана/сәнә, чы/че, әле, инде* һ.б.; 3) экспрессив: *да-дә/та-тә, ук/үк, хәтта; иң, чем, дөм, үтә* һ.б.; 4) эмоциональ кисәкчәләр: *бит, ич, лабаса/ләбаса, ла/лә* һ.б.

Кисәкчәләр һәм аларның татар телендәге синтаксик-семантик эквивалентларын унбер семантик төркемгә бүлеп була: 1) Күрсәтү кисәкчәләре: *әнә, менә, аны, бу, әлеге* һ.б.; 2) Чикләүче кисәкчәләр: *гына-генә/кына-кенә, бары, тик, фәкать, хетт, бары тик*һ.б.; 3) Билгесезлек кисәкчәләре: *-дыр/-дер, -тыр/-тер, -магае/-мәгәе, әллә* һ.б.; 4) Сорау кисәкчәләре: *-мы/-ме, -мыни/-мени, микән, микәнни, мәллә* һ.б.; 5)Инкяр итүче кисәкчәләр: *ни, -ма/-мә (-мый, -мы, -мас/-мәс)* һ.б.; 6) Үтенү-ялыну кисәкчәләре: *-чы/-че, -сана/-сәнә* һ.б.; 7)Көчәйтү-аныклау кисәкчәләре: *иң, дөм-, шыр, җете, чалт, үтә, ап-, кап-, зәп-* һ.б.; 8) Аныклаучы кисәкчәләр: *нәкъ,* диалекталь *хас, тач, кап, мисле, чат, әмән* һ.б.; 9) Билгене төрле яклап характерлаучы кисәкчәләр: *әле, алай, болай, шулай, чак* һ.б.; 10) акцент ясаучы кисәкчәләр: *ич, бит, бик, да-дә, та-тә, гел, бөтенләй, инде, ләбаса-лабаса* һ.б.; 11) Хәбәрнең чыганагы һәм хәбәрнең башка өлешләре белән төрле элемтәләр урнаштыра торган кисәкчәләр: *исә, тәки, булсын-булсын, дисеңме- дисеңме* һ.б.

Ә.Латыйпов фигыль төркемчәләренә ялганып килгән кисәкчәләрне, аларның мәгънәләренә шактый тулы күзәтү биргән. Мәсәлән, **-чы(-че)** кисәкчәсе боерык фигыльләргәялганып килеп, алардагы боеру мәгънәсен йомшарту функциясен үти, ягъни беору мәгънәсенә үтенү-ялыну төсмере өстәвен тикшергән. Галимнәрнең тикшерүләреннән күренгәнчә, кисәкчәләр белдергән модальлек мәгъләренең күләме киң һәм төрле. Аларның күбесе полисемантик характерда. Шуңа күрә кисәкчәләрне семантик төркемнәре сөйләм шартларына бәйле үзгәрү мөмкинлеген истә тотарга кирәк.

*Җөмләдә кисәкчәләр үтәгән функцияләр. Гына- генә, кына- кенә, да-дә, та-тә, тик, фәкать, хәтта, бары, бары тик* кисәкчәләре сөйләмдә өстәмә мәгълүмат тудырырга сәләтле. Кисәкчәләр тулы җөмләгә яки аерым сүзгә карый ала. Кисәкчәләрнең урыну үзгәрүгә бәйле, аның эчтәлеге үзгәрергә мөмкин.

Кисәкчәләр комбинациясе-татар теленә дә хас үзенчәлек. Галимнәр хезмәтләрендә сөйләмдә кисәкчәләр белән түбәндәге комбинацияләр барлыгы билгеләнгән:

1) Ике, өч, дүрт кисәкчәдән торган постпозицион комбинацияләр. Сөйләмдә комбинация кайвакыт биш, алты, җиде кисәкчәдән торырга мөмкин. Мәсәлән: Хәл белергә керүен**дер** *ич.* (М.Хуҗин); Обкомда эшләгәндә сүзләмәгәндә, хәзер сүзлим**ме** *соң инде.* (Ф.Садрыев); Шулай итеп аерылышабыз *дамыни инде.* (М.Хәсәнов).

2) Препозицион һәм постпозицион кисәкчәләрнең комбинациясе. Мәсәлән: *Соң бит,* әнкәй, ил йоласы шулай *бит инде* (Ф. Садрыев).

3) Ике, өч, дүрт кисәкчәдән торган препозицион комбинация. Мәсәлән: *Тик мен***ә** әҗәлдән котылу чарасын гына таба алмаган. (Ә.Еники); *Менә тик* ипи ашасаң иде. (М.Мәһдиев).

Комбинацияләнә торган кисәкчәләр модаль сүзләр, ымлыклар, фонетик чаралар белән тыгыз бәйләнештә торалар һәм җөмләнең модальлек характерын тагын да катлауландыралар. Мәсәлән: *Чынлап та,* ул безгә бөтенләй **үк** ят *түгел ич.* (М.Шәймарданов); *Бәлки ул хаклыдыр, хаклыдыр.* (Ә.Гаффар); *Инде* миңа юллар *ябык, ябык, ябык.* (А.Расих).

Хәзерге татар теле морфологиясендә модаль ярдәмлек сүз төркеменә кертеп карала торган кисәкчәләрне өйрәнү җанлы сөйләмдәге бай мәгънә төсмерләрен ачыкларга, сөйләмдә модальлекне белдерүнең башка чаралары белән үзара тәэсир итешеп, яңа төсмерләрен тудыруга сәләтле булуын күрсәтә.

**ӘДӘБИЯТ**

1. Татар грамматикасы: өч томда / проект җит. М.З. Зәкиев. – Тулыландырылган 2 нче басма. – Казан: ТӘһСИ, 2016. – Т. II. – 432 б.

2. Сафиуллина Ф.С., Зәкиев М.З. Хәзерге татар әдәби теле / Ф.С. Сафиуллина, М.З. Зәкиев. – Казан: Тат. кит. нәшр., 2006. – Б. 308–309.

3. Хисамова Ф.М. Татар теле морфологиясе / Ф.М. Хисамова. – Казан, “Мәгариф” нәшрияты, 2006. – Б. 308–309.

4. Ганиев Ф.Ә. Хәзерге татар әдәби теле. Сүзьясалышы / Ф.Ә. Ганиев. Казан: Тат. кит. нәшр., 2000. – Б. 246–247.

5. Латыйпов Ә. Үтенү-ялыну кисәкчәләре// Совет мәктәбе. –1987. – №7. – Б. 22–23.

**Г.М. ХӨСНЕТДИНОВА, А.М. ЗӘЙНУЛЛИНА**
*Казан шәһәре Советлар Союзы Герое А.С. Умеркин исемендәге 116 нчы лицей, Россия*
*Казан шәһәре "36 нчы гимназия" муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе, Россия*

# Ф.ӘМИРХАН ИҖАТЫНДА СИНОНИМНАРНЫҢ РОЛЕ

**Аннотация.** В данной статье рассматриваются особенности употребления синонимов в творчестве Ф. Амирхана. Произведения Ф. Амирхана очень богаты синонимами.

**Ключевые слова:** синонимы, лексика, слово, значение

**Abstract.** This article discusses the features of the use of synonyms in the works of F. Amirkhan. The works of F. Amirkhan are very rich in synonyms.

**Key words:** synonyms, vocabulary, word, meaning.

Һәрбер телдә дә бер үк төшенчәне белдереп, мәгънә ягыннан бер-берсенә якын, охшаш булган, ә семантик-стилистик төсмерләре белән бер-берсеннән аерылып торган бик күп сүзләр бар. Мондый төр сүзләрне без синонимнар дип атыйбыз, алар язылышлары белән төрле булсалар да, мәгънәләре (төп мәгънәләре) белән тәңгәл киләләр. «Гамәли-практик яктан синонимнар төшенчәсе астында сөйләмдә (ягъни контекстта) сүзләрнең, грамматик формаларның һәм төрле әйтелмәләр, тезмәләрнең бер-берсен алмаштыра алу мөмкинлекләре күздә тотыла». [1, б.108]

Синонимнар сөйләмнең төгәллегенә ирешүдә, эчтәлекне ачуда әһәмиятле урын тота. Һәркемгә билгеле: билгеле-бер мәгънәне белдерү өчен берничә мәртәбә бер үк сүзне кабатласак, сөйләмнең сыйфаты кими, яңгырашы камиллеген югалта. Кабатлауларга бай булган текст әңгәмәдәш, яки тыңлаучыда тискәре хис-тойгылар уятырга да мөмкин. Әдәби әсәрдә кабатлауларның еш кулланылуы әсәрнең матурлыгын, аһәңен югалттыра. Моннан котылуның бердәнбер чарасы – тел байлыгын, мәгънәдәш сүзләрне урынлы файдалану. Фатих Әмирханның без күзәтү ясаган һәр әсәре дә синонимнарга бай. Бу исә язучының тел байлыгын гаять оста кулланганлыгын дәлилли. «Кадерле минутлар», «Хәят», «Татар кызы», «Ул үксез бала шул» әсәрләренә күзәтү ясаганнан соң, без синонимнарның түбәндәге төркемчәләрен аерып чыгардык: абсолют синонимнар, идеографик синонимнар, экспрессив-стилистик синонимнар.

Абсолют синонимнар үзара семантик яки стилистик, шулай ук контекстуаль мәгънә ягыннан бернинди аермага ия түгел. Мондый синонимнарның берсе

еш кына язма әдәбиятта, татар халык авыз иҗатында, ә икенчесе гади (җанлы) сөйләмдә киң таралыш алган була. Мәсәлән, *аучы* сүзен Г.Тукай иҗатында күзәтә алабыз: «Әллә кайдан шунда килеп чыкты Аучы». Синонимы – сунарчы. Сунарчы шулай ук борынгы сүз, халык авыз иҗатында үз урынын алган.

«Аучы»дан аермалы буларак, икенчесе халык телендә ешрак очраган һәм «сунарчы» сүзенең кулланылыш өлкәсе киңрәк булган. Тик вакытлар узу белән, ситуация үзгәрергә синонимнар урыннары белән алмашырга мөмкин. «Аучы» һәм «сунарчы» мисаллары моңа дәлил булып тора. Бүгенге көндә «аучы» варианты көнкүрештә ешрак файдаланыла. Абсолют синонимнар Ф.Әмирхан иҗатында еш очрый. Мәсәлән, *«Җил бик ачы тавыш белән сызгыра, бик калын тавыш белән үкерә, әле ыжгыра башлый».* [2, б.195] мисалында автор каты җил тавышын сызгыра, үкерә, ыжгыра синонимнары белән сурәтли. Әлеге төр синонимнарны язучы иҗатында еш очратабыз:

*«Ул, әле күптән түгел генә укып чыккан русча бер романда, сөю, сөелү дигән сүзләрне күргән вә хәтта үзен шул романда язылган кызларның берсе итеп уйлап укыган булса да...»* [2, б. 165]

*«Малдан бәрәкәт, йорттан гафият җибәрәсез», ди торган иде».* [2, б. 174]

*«Хәят барып кергәндә, Рәхимовларның ялтырап яктыртылган йорты һәр вакыттагы шикелле шау-шулы, ыгы-зыгылы иде».* [2, б. 176]

*«Бөтен гомерегезне елап, сыхтап уздыра торган кешеләр сез! – дип, Рәшат өстәл яныннан торып китте».* [2, б. 391]

*«Аля бүген башка вакыттагыдан да матур, сөйкемле, җазибәле, әллә нәрсәле...»* [2, б. 393]

Ф.Әмирханның без күзәтү ясаган әсәрләрендә идеографик синонимнарны да табарга була. Мәгънә төсмерләре белән аерылып тора торган синонимнар мәгънәви яисә идеографик синонимнар дип атала (грек. Idea – мәгънә, төшенчә + grapho – язам). Әлеге төр сүзләр контекстта гына синонимнар булып киләләр. Шунысы мөһим: контекстан тыш аларда мәгънә якынлыгы югалырга, алар төрле мәгънә төсмерен йөртергә мөмкин. «Контекст мәгънәдәш сүзләрне бер ояга беркетүче үзәк ролен үти». [1, б.111]

*«Ул озын, куе вә үз-үзләреннән күпереп тора торган, кара ефәк көлтәсе шикелле чәчләрен тараганда, Лиза дача хәлләрен сөйли торды».* [2, б.151]

*«Артык ямьле, гаҗәеп аяз көннең якты, җылы, тыныч һәм хуш исле кичен мин Ботанический бакчадан ерак түгел бер җирдә каршы алдым».* [2, б. 392]

*«Бу китапны шәкерт тә, мөгаллимә дә ярым-йорты гына аңлап барсалар да, аңлаган кадәрлесеннән кирәкле нәтиҗәне чыгару Хәяткә артык читен булмады».* [2, б. 153]

*«...Мясниковларга катышып килеп, рус җәмгыятендәге гореф вә әдәпләрне яхшы ук өйрәнгән булуы да тәрбияләр арасындагы бу зур аерманы каплап тора иде».* [2, б. 153]

*«... соңыннан күңеле әллә нинди бер бушлык, бер эч пошу каплап ала иде».* [2, б. 173]

Экспрессив-стилистик синонимнар сөйләмнең сурәтлелеген, яңгырашын көчәйтүдә зур урын тоталар. Алар еш кына авторның индивидуаль стиль үзенчәлекләре белән бәйле рәвештә кулланыла. «Мондый сүзләрнең мәгънәсе контекстта гына ачылганга күрә, аларны контекстуаль синонимнар итеп карарга мөмкин. Мәсәлән, Ф.Хөснидә *баш* сүзенә синоним булып килгән *чүлмәк* сүзе шуның ачык мисалы: «Әйтә алган чаклысы шул: минем чүлмәк шулай ук буш түгел, анда да нәрсәдер кайный». [Хаков, 1999: 110]

*«Мин Мәскәүдә әллә ничә маржада күрдем шундыйны, – дип, теге кызның кофточкасын күрсәтте».* [2, б.179] Татар телендә җанлы сөйләмдә «маржа» сүз рус милләтеннән булган хатын-кызны билгеләү өчен файдаланыла.

*«Бу рәсем быел гына юридический факультет тәмам итеп, хатын-кыз таифәсеннән бөтен Европада үәвәле дәгъва вәкиле булган кызның рәсеме иде».* [2, б.179] «Дәгъва вәкиле» бүгенге көндә сөйләмнән төшеп калган, әмма XX йөз башында актив кулланылышта булган сүз, адвокат мәгънәсен белдерә.

*«Болай дигәч тә, сез тагы, господа, әллә нәрсә уйламагыз, миндә шул вакытта берәр хайвани тойгы булгандыр ди, фикерегезгә китерә күрсәгез».* [2, б. 394] «Тойгы» бирдә «хис» сүзенә синоним булып килгән дип фаразлый алабыз, ә «фикер» «уй» сүзенә алмаш булып килгән.

Шулай итеп, татар теленең бай сүзлек хәзинәсендә төрле-төрле мәгънә төсмерләре бирүдә, стиль үзенчәлекләре барлыкка китерүдә синонимнарның тоткан урыны гаять зур. Алар сөйләмнең төгәллегенә, нәфислегенә һәм сәнгатьчә яңгырашына ирешүдә әһәмиятле чара булып торалар, эчтәлекне төгәл һәм дөрес чагылдыруга ярдәм итәләр, телдән файдалану мөмкинлекләрен арттыралар.

**ӘДӘБИЯТ**

1. Хаков В.Х. Татар әдәби теле (стилистика) / В.Х. Хаков. – Казан: Тат. кит. нәшр, 1999. – 304 б.

2. Әмирхан Ф.З. Кадерле минутлар: повесть / Ф. Әмирхан. – Казан: Тат. кит. нәшр. – 1957.

**Э.Г. ШАКИРОВА**
*Муниципальное бюджетное общеобразовательное учреждение «Гимназия 5»*
*г. Казани, Россия*

# НАУЧНАЯ ДЕЯТЕЛЬНОСТЬ В.Х. ХАКОВА В СФЕРЕ ТЮРКОЛОГИИ

**Аннотация.** Статья посвящена описанию научной деятельности Заслуженного профессора Казанского университета Вахита Хозятовича Хакова в области тюркологии.

**Ключевые слова:** Вахит Хаков, история татарского литературного языка, стилистика

**Abstract**. The article is devoted to the description of the scientific activity of the Honored Professor of Kazan University Vahit Khozyatovich Khakov in the field of Turkology.

**Keywords**: Vahit Khakov, the history of Tatar literary language, stylistics

Вахит Хозятович Хаков родился 16 августа 1926 года в деревне Кузби Буинского района в обычной крестьянской семье. Начальные классы он обучался в школе, которая находится в его деревне. В свои 17 лет будучи юным парнем уходит служить на фронт. Ему рано пришлось повзрослеть, так как война сделала из него настоящего мужчину. После полученной травмы на фронте В.Х.Хаков — участник Великой Отечественной войны 1941–1945 гг., награжден орденом Великой Отечественной войны II степени и многими медалями: «За боевые заслуги», «За победу над Японией», «За доблестный труд», медаль Жукова и др. В.Х.Хаков вернулся и начал свою научную карьеру. С юного возраста он мечтал стать педагогом, как и его родители.

Вахит Хозятович – российский татарский филолог. Доктор филологических наук профессор Казанского университета. Заслуженный деятель Татарской науки. Лауреат Государственной премии Республики Татарстан в области науки и техники. Заслуженный профессор Казанского университета. Член ассоциации востоковедов Российской Федерации, член редакции Татарской энциклопедии словаря по языкознанию. Участник Великой Отечественной войны. Вахит Хозятовия Хаков был эрудированным и разносторонним человеком. Его талантами и достижениями восхищались многие.

В 1957 году окончил с отличием отделение татарского языка и литературы историко-филологического факультета Казанского государственного университета им. В. И. Ульянова-Ленина. Большую часть своей преподавательской карьеры он провел в Казанском университете. В.Х. Хаков добился таких званий как: доцент, профессор кафедры татарского языка, завкафедрой.

Татарский литературный язык как новая самостоятельная научная отрасль берет свое начало в 1960-х годах. Как относительно новая научная отрасль во всемирной системе образования она начинает стремительно развиваться. В этом есть заслуга профессора и доктора наук Вахита Хозятовича Хакова. 1971 году он защитил докторскую работу на тему «История развития татарского литературного языка и стилей» она является фундаментом в изучении литературного татарского языка. Так же его научная диссертация на тему «возникновение и становление татарского национального литературного языка» используется, в обучение студентов по сей день. Вахит Хозятович внёс огромный вклад в развитие тюркологии. Его научные труды являются основой преподавания в КФУ. Также огромным успехом пользуется созданные им спецкурсы на следующие темы: «Основные этапы развития татарского литературного языка», «Функциональные стили татарского языка», «Язык татарских художественных произведений», «Основы социолингвистики», «Татарская письменность на основе латинской графики».

Вахит Хозятович активно участвовал во многочисленных мировых, всесоюзных, международных конференциях, симпозиумах. Благодаря своей научной деятельности он побывал в таких городах как: Москва, Самарканд, Киев, Ташкент и др. Он является почетным участником международных тюркологических конференций, конгрессов, которые проходили в странах Европы, США, Турции и многих других.

Сохранение татарского языка является важной проблемой на данный момент. В.Х. Хаков успешно реализовал государственный закон «О языках РТ» и программы по сохранению и развитию татарского языка как государственного закона «О восстановлении татарского алфавита на основе латинской графики». Им были выпущены множество учебных пособий для реализации закона, также он один из авторов Татарской энциклопедии и многих других проектов и пособий. Действительная на данный момент радиопередача «Тел күрке – сүз» на протяжении 30 лет продолжала свою под его руководством и активном участии, это так же является большим плюсом в борьбе с проблемой сохранения татарского языка.

Успех в научной деятельности В.Х. Хакова подкрепляется его многочисленными почетными грамотами, письмами благодарности, важно отметить, что правительство РТ поддерживает идеи Хакова в сохранение татарского языка. Ему присвоены такие награды как «Заслуженный деятель науки ТАССР» врученный ему указом Президиума Верховного Совета ТАССР, нагрудный знак

Минвуза СССР « за отличные успехи в работе». Он получил университетскую премию и присвоение звания лауреата КГУ.

Ежегодно в честь В.Х. Хакова проводится научная конференция, где участники готовят свои доклады о достижениях этого ученого. Вахит Хозятович проделал огромную работу для развития тюркского языка. Он наблюдал за периодом появления, становления, а затем и за расцветом татарского языка как за самостоятельной научной отраслью. История появления и развития тюркских языков многогранна и увлекательна. В.Х. Хаков в своих научных трудах излагает обширную информацию на доступном языке для учащихся.

Таким образом, В.Х. Хаков, литератор с глубоким пониманием мира и окружающих проблем, идейный мыслитель. Научные работы Хакова путешествуют по миру, пересекая границы нашей страны. Его диссертации, доклады, статьи вызывают интерес у зарубежных представителей научной деятельности. Он внес большой вклад в развитие татарской литературы, татарской культуры.

**А.Р. ШАКИРОВА**

*Казанский федеральный университет, Россия*

## ЛЕКСИКОГРАФИЧЕСКОЕ ОПИСАНИЕ МИФОЛОГИЧЕСКОГО ПЕРСОНАЖА «АЛБАСТЫ»

**Аннотация**. В ходе нашего научного исследования мы изучили пять словарей: толковый словарь татарского языка, энциклопедический словарь татарской мифологии, словарь диалектов татарского языка, а также словари антонимов и синонимов. Также рассмотрели научные работы по поговоркам и пословицам.

**Ключевые слова:** миф, мифология, Албасты, лексикография, лексикографическое описание.

**Abstract**. In the course of our scientific research, we studied five dictionaries: an explanatory dictionary of the Tatar language, an encyclopedic dictionary of Tatar mythology, a dictionary of dialects of the Tatar language, as well as dictionaries of antonyms and synonyms. They also reviewed scientific works on sayings and proverbs.

**Keywords**: myth, mythology, Albasts, lexicography, lexicographic description.

Актуальность данной научной статьи обосновывается возрастающим интересом современной лингвистики к проявлению национального менталитета в языке, частотностью слов-мифологем в татарском фольклоре, художественной литературе, а также необходимостью комплексного изучения духовной культуры, что в свою очередь может существенно продвинуть нас в познании

различных сторон общественно-социальной жизни человека и языка в том числе. Также следует отметить, возрастающий интерес к мифологическим персонажам в татарской современной литературе. Здесь к примеру можно привести роман Галимзяна Гильманова «Албастылар».

Как известно, в научной лингвистической литературе понятие мифа и мифологии еще остается спорным, ведь нет общепризнанного, единого, удовлетворяющего всех исследователей термина, обозначающего единицы мифологической лексики. Мы в свою очередь взяли в основу определение С.А. Кузнецова: "Древнее народное сказание о богах и обожествлённых героях, о происхождении мироздания и жизни на Земле" [4]. Мифологический персонаж понимается как «пучок релевантных признаков и функций, скрепленных именем» [3: 99].

В мифологии Казанских, Крымских, Сибирских татар, мишарей, казахов, башкиров, киргизов, каракалпаков, нугайцев, мифологический персонаж «Албасты» является отрицательным героем.

По поверьям, Албасты может принять любой вид: начиная от человека, заканчивая разными предметами, например показаться стогом сена. Но в основном Албасты предстает перед людьми в облике уродливой, изучеченной, ленивой, грязной женщины с распущенными волосами. У нее такая большая грудь, что она иногда закидывает ее на спину. Некоторые считают, что у на спине нет мяса и костей, поэтому все её внутренние органы видны.

В Татарском толковом словаре слово "Албасты" рассматривается как в значении мифологического персонажа, так и в переносном значений. "Албасты – мифологический персонаж, который душит людей во время сна или мучает, наседая на грудь человека" [8: 127]. В переносных значениях слово «Албасты» может означать человека, который носит очень большую, неподходящюю для него по размеру одежду, либо что-то огромное, непонятный предмет. Также здесь приводится такое явление как «Албасты басу» - удушение Албасты, что означает увидеть страшный сон, проснуться от ощущения какого-то давления.

В Энциклопедическом словаре татарской мифологии Ф.И. Урманчеева "Абзар иясе" сопоставляется с такими мифологическими персонажами как Убырлы. По поверьям казанских татар, Албасты ночью запрыгивает на человека и сосет у него кровь. С этой точки зрения этот мифологический персонаж немного похож на Убырлы карчык (Бабу-ягу) [9: 76]

В Большом диалектологическом словаре татарского языка эквивалент "Албасты" не предоставлен [1].

В синонимическом словаре татарского языка [10] и в словаре антонимов татарского языка [6] эквиваленты слова "Албасты" не представлены.

В сборнике пословиц и поговорок "Татар халык иҗаты" примеры с мифонимом "Албасты" не обнаружены [5], но в Толковом словаре приводится такой пример как: «Албасты көчсезләрне баса» [8:127] – «Албасты душит слабых».

Таким образом, изучая лексикографическое описание мифонима "Албасты" можно прийти к выводу, что в татарской лексикографии этот мифологический персонаж достаточно изучен, но в то же время он настолько многоранен, что невозможно согласиться только с найденными в словарях данными. В связи с этим, тема описания мифологического персонажа Албасты остается актуальным, ведь подробный анализ слов-мифологем дает возможность выявить базовые оппозиции, характерные для татарской культуры и мировоззрения, культурные ценности общества, также описать наивные языковые представления носителей татарского языка, сложившиеся под воздействием национального мировидения.

**ЛИТЕРАТУРА**


1. Баязитова Ф.С. Татар теленең зур диалектологик сүзлеге / төз.: Ф.С. Баязитова, Д.Б. Рамазанова, З.Р. Садыйкова, Т.Х. Хәйретдинова. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2009. – 839 б.
2. Коблов Я.Д. Мифология казанских татар / Я.Д. Коблов. – Казань, 1910. – 49 с.
3. Левкиевская Е. Мифы русского народа / Е. Левкиевская. – М.: ООО «Издательство Астрель». – 528 с.
4. Кузнецов С.А. Новейший большой толковый словарь русского языка / гл. ред. С. А. Кузнецов. – СПб., М.: Норинт; Рипол классик, 2008. – 1534 с.
5. Мәхмүтов Х.Ш. Татар халык иҗаты. Мәкальләр һәм әйтемнәр / төз.: Мәхмүтов Х.Ш. – Казань: Татарское книжное издательство, 1987. – 591 б.
6. Сафиуллина Ф.С. Антонимнар сүзлеге / Ф.С. Сафиуллина. – Казан: Хәтер, 2005. – 235 б.
7. Татар мифлары: Ияләр, ышанулар, ырымнар, фаллар, им-томнар, сынамышлар, йолалар / Г. Гыйльманов хикәяләвендә. Казан: Тат. кит. нәшр, 1996. – 388 б.
8. Татар теленең аңлатмалы сүзлеге: I том: А-В. – Казан: ТӘһСИ, 2015. – 712 б.
9. Урманче Ф.И. Татар мифологиясе. Энциклопедик сүзлек: 3томда: 1 т. (А-Г) / Фатих Урманче. – Казан: Мәгариф, 2008. – 303 б.
10. Ханбикова Ш.С., Сафиуллина Ф.С. Синонимнар сүзлеге / Ш.С. Ханбикова, Ф.С. Сафиуллина. – Казан: "Хәтер" нәшрияты, 1999. – 255 б.
11. Мифы народов мира http://cult-lib.ru/doc/dictionary/myths-of-the-world/fc/slovar-192-4.htm#zag-122 (дата обращения: 3.10.21)
12. Онлайн - энциклопедия Tatarica https://tatarica.org/ru/razdely/narody/tatary/verovaniya-i-mifologiya/mifologicheskie-personazhi/albasty Дата обращения: 6.10.21

**Г.А. ШӘЙМАРДАНОВА**
*Муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе*
*"Хәрби-патриотик белем бирү үзәге А. И. Чехов исемендәге 67 нче мәктәп"*
*Казан, Россия*

# ТАТАР ТЕЛЕН ЧИТ ТЕЛ БУЛАРАК ӨЙРӘТКӘНДӘ КОМПЬЮТЕР ТЕХНОЛОГИЯЛӘРЕН КУЛЛАНУ

**Аннотация**. Основным результатом своей деятельности считаем получение детьми прочных знаний, умений, навыков по татарскому языку и литературе, умение их применять на практике. Обучение будет успешным, если знания, умения, навыки усваиваются учащимися в строгой последовательности, постепенно в порядке вырастающей трудности и сложности с ним, чтобы школьник поднимался по ступеням.

**Ключевые слова**: урок, методы, компьютерные технологии, процесс

**Annotation.** The main result of our activities we believe that children receive strong knowledge, skills in the Tatar language and literature, ability to apply them in practice. The teaching will be successful if the knowledge, skills are acquired by pupils in a strict sequence, gradually in the order of growing difficulty and complexity with it that the student climbed the stairs.

**Keywords**: lesson, methods, computer technology, process

Мәктәптә татар теле һәм әдәбият укытучысының эш шактый катлаулы һәм җаваплы. Һәр дәрес кызыклы үтсен өчен, укытучы төрле методлар һәм алымнар куллана. Дәрес барлык таләпләргә дә җавап бирсен өчен, иң элек укытучы балалар күңеленә юл табарга, дәресне күңелле, кызыклы үткәрергә, татар теленә мәхәббәт уятырга тиеш. Шуңа күрә, һәр дәрес аермалы булырга тиеш. Бүгенге көндә татар телен өйрәтүдә компьютер техналогияләре күп кулланыла. Без дә үзебезнең практикабызда дәреснең нәтиҗәлеген күрсәтүдә заманча технологияләр – компьютер технологиясен файдаланабыз. Компьютер технологиясе – компьютер мөмкинчелекләрен файдаланып, өйрәнүчегә информацияне әзерләү һәм тапшыру процессы ул. Компьютер технологиясеннән нәтиҗәле файдалану – укыту методикасының мөһим бурычы. Бүгенге көндә күп кенә мәктәпләрдә интрактив такта киң кулланыла. Шулай ук компьютер программасын файдаланып, төрле модель һәм таблицалар төзергә була. Интрактив такта укучыларга барлык мәгълүматны җиткерергә ярдәм итә, укучыларда татар теле дәресенә кызыксыну уята һәм дәреснең нәтиҗәлеген арттыра. Мәсәлән, татар теле дәресләрендә 6 сыйныфта “Алмашлык” темасын уткәндә компьютер технологиясен кулланырга мөмкин. Укучыларның мөстәкыйль фикерләү сәләтен

үстерүдә кулланыла торган алымнарның берсе – тестлар. Тестлар берничә төргә бүленәләр:

Тестларның төрләре:

– тәкъдим ителгән җавапларны сайлап алу;

– тест – схемалар;

– күп ноктала урынына төшереп калдырылган сүзләрне, кушымчаларны кую һ.б.

Без аларны гомумиләштерү дәресләрендә, катнаш дәресләрдә белемнәрне тикшерү өчен кулланабыз. Интерактив тактада тәгъдим иткән тестлар төрле авырлыкта була, чөнки класста барлык укучыларның да белем дәрәҗәсе бер үк түгел. Шуңа күрә, һәр укучыга дифферинциаль якын киләбез. Укучыларның эшләү темпына, зирәклегенә карап, тестлар төрле вариантта карала. Аннан соң укучылар, экранга карап, үз-үзләрен бәяли алалар. Информацион-белешмә программалар (сүзлекләр) кирәк булганда, сүзләрне интернет челтәре аша табарга була. Шулай ук дәресләрдә “Ана теле” онлайн ресурсын еш кулланабыз. Бу балаларга бик ошый һәм алар бик кызыксынып эшлиләр. Күргәзмә программалар (слайд һәм видео-фильмнар, презентаияләр) сөйләм теле үстерү дәресләрендә куллану өчен бик уңайлы. Мәсәлән, "Гаяз Исхакый иҗаты “Кәҗүл читек” хикәясенең бер өзегеннән алмашлыклар табарга" дигән бирем бирергә була.

1. **Шул** уйлар мине куркытканнан-куркыта бара.
2. **Бу** читек бөтенләй башка.
3. **Бер** иптәшемә серне сөйләдем.һ.б

Әлбәттә, укучылар мондый төр эшләрне бик яратып башкаралар. Дәрес уңышлы һәм нәтиҗәле булсын өчен барлык көчебезне куеп эшлибез. Шуңа күрә укучыларым да дәресләрдә актив катнашлар һәм теләп йөриләр. Дәрес укытучы һәм укучы бердәм – эзлекле эшләгәндә генә нәтиҗәле була.

**ӘДӘБИЯТ**

1. Вәлиев Ф.С. Урта мәктәп һәм гимназияләрдә татар телен укыту методикасы / Ф.С. Вәлиев, Г.Ф. Саттаров. – Казан: Раннур, 2000. – 330 б.

2. Вәлиев Ф.С. Татар теле дәресләрендә укучыларның сөйләү һәм язу телен үстерү мәсьәләләре / Ф.С. Вәлиев. – Казан, 1997. – 124 б.

3. Харисов Ф.Ф., Харисова Ч.М. Татар телен өйрәтүдә заманча технологияләр. – Мәгариф. – 2002. – №1. – Б. 35–36.

**А.А. ЯРУЛЛИН**

*А. Н. Туполев исемендәге Казан милли тикшеренү техник университеты, Россия*

# ФӘНГӘ БАГЫШЛАНГАН ГОМЕР

**Аннотация.** Статья посвящена описанию жизни и научной деятельности Заслуженного профессора Казанского университета Вахита Хозятовича Хакова.

**Ключевые слова:** Вахит Хаков, история татарского литературного языка, стилистика

**Abstract**. The article is devoted to the description of the life and scientific activity of the Honored Professor of Kazan University Vakhit Khakovich Khakov

**Keywords**: Vahit Khakov, the history of Tatar literary language, stylistics

Һәркемнең үзенә якын һәм кадерле туган ягы бар. Минем дә туган авылым бик матур урында урнашкан. Ул үзенең челтерәп аккан чишмәләре, калын, шомлы һәм серле урманнары, гореф-гадәтле, эшчән, акыллы кешеләре белән атаклы.

Моннан күп еллар элек, бөек Иделгә барып кушыла торган Зөя буена Ураз бабай килеп йорт салган, җирләрен эшкәрткән. Ару-талуны белмәүче Ураз бабай шушы урынга нигез салган йортны Ураз килде дип атаганнар. Тора-бара бу җирләрне Килдураз дип йөртә башлаганнар. Авыл үскән, зурайган, көннән көн матурайган. Тирә-якта даны арткан. Килдураз белән чиктәш авыллар: Өчмунча, Күзби, Бәбки, Үгез куагы, Кабалан халкы элек-электән дус, тату яшәгән. Балалары Килдураз мәктәбендә белем алганнар. Бу хәзер дә шулай дәвам итә. Хәзерге вакытта авылларны "Коммуна" күмәк хуҗалыгы берләштерә. Бу авыллардан күп кенә күренекле һәмданлыклы кешеләр чыккан: Ренат Харис, Шәриф Хөсәинов, Марс Әхмәтов, Шамил Нигъмәтуллин, Вахит Хаков, Җәләлетдинов Рәшит, Әюпов Ренат, Скиргайло Тамара һ.б., шулардан иң өлкәне – Вахит Хаков.

*В.Х. Хаковның туган төбәге, тормыш юлы*

Күренекле тел галиме, укытучы-педагог, Вахит Хөҗҗәт улы Хаков 1926 нчы елның 16 нчы августында Татарстанның матур урынында урнашкан Буа районының Күзби авылында дөньяга килә. Аның әтисе – Хөҗҗәтелислам акыллы, тырыш кеше була, бөтен гомерен балалар укытуга багышлый. Педагог әтисенә ияреп, малай да китап яратып үсә.

Башлангыч белемне Күзби авылында мөгаллимлек иткән әтисеннән ала. Бу мәктәпне "5"ле билгеләренә генә тәмамлап, Вахит ага укуын Килдураз мәктәбендә дәвам итә, 8 нче классны бетергәч, Бөек Ватан сугышы башлана.

Кечкенәдән укытучы булырга хыялланган малай чак кына еламый кала. “Ничек кенә авыр булмасын, укый күр, улым,” – дигән әтисенең сүзләре колагында яңгырый.

1943 нче елда 17 яше дә тулмаган Вахитны армиягә алалар. Җиде ел хәрби хезмәттә булып, яраланып, сугышчан медальләр, Верховный Командующийның рәхмәт кәгазьләре белән бүләкләнеп, 1949 нчы елда яшь солдат тыныч хезмәткә исән-имин әйләнеп кайта.

*Тел галиме  Вахит Хаков*

Вахит Хөҗҗәт улы туган якларына әйләнеп кайткач, ул төрле мәктәпләрдә балалар укыта, үз белемен күтәрү өстендә эшли.Тәтеш педагогия училищесын “бик яхшы” билгеләренә тәмамлый. Егет укуын дәвам итү өчен Казан дәүләт университына укырга керә, аны кызыл дипломга бетерә. Аспирантураны тәмамлап “Татар әдәби теленең барлыкка килүе, үсеше һәм аның стильләре” дигән докторлык диссертациясе яклап, филология фәннәре докторы дигән югары гыйльми дәрәҗә ала.Тагын өч елдан аңа профессор исеме бирелә. Менә нинди тырыш, үҗәт булган безнең якташыбыз.

Вахит ага, чыннан да, әтисенә биргән сүзендә тора. Зур уңышларга ирешә, тел галиме дәрәҗәсенә күтәрелә. Ул 40 ел дәвамында студентларга белем бирә.

Якташыбыз 40 елдан артык Татарстан радиосында “Тел күрке – сүз” тапшыруларының оештыручысы һәм алып баручысы булды, берничә буын бу тапшыруларны тыңлап, тәрбияләнеп үсте.

Галимнең 30 га якын монографиясе, дәреслекләре, уку-укыту әсбаплары 500дән артык фәнни һәм фәнни методик хезмәтләре басыла. Әле шулар янына төрле китапларны, җыентыкларны, шул җөмләдән чит ил басмаларын да мәсәлән, Төркиядә дөнья күргән 350 гә якын фәнни мәкаләләрне өстәргә кирәк.

Милләт язмышы, халык мәнфәгате турындагы уйлар китергәндер егетне бу юлга, эшлекле, булдыклы ир-егет гомерен татар телен өйрәнүгә, аны баетуга, пропагандалауга багышлый. “Мәктәптә, югары уку йортларында тел укытуны ничек тә саклап калырга, газиз туган телебезне өйдә генә сөйләшергә ярый торган тел итеп калдырмаска! Дәрәҗәсен төшермәскә! - ди галим. Халык туган телдән бизмәсен, сөйләшү-аралашуда, язуда күбрәк куллансын, матурлыгын, ләззәтен тойсын дип тырышты Вахит ага. Тел бит ул бер-берең белән аралашу коралы гына түгел, ул – фикерләү чарасы да. Тел кешенең фикерләвен, дөньяны танып белүен дә үстерә. Туган телгә мәхәббәт тәрбияләү, аны күз карасы кебек саклау – үз анаңны , илеңне хөрмәтләү дигән сүз.

Татар теле, катлаулы үсеш юлы үтеп, хәзерге көндә төрки телләр төркеменә керүче бай телләрнең берсе булып санала.

Татарстан Республикасы Буа районы Черки-Килдураз урта гомуми белем мәктәбендә Вахит Хөҗҗәт улы Хаковның туксан яшьлек юбилеена багышланган «Казан университеты профессоры Вахит Хөҗҗәт улы Хаковның фәнни-педагогик мирасы» дип исемләнгән республикакүләм фәнни-гамәли конференциясе үткәрелде. Бу конференциядә Вахит Хөҗҗәт улы Хаковның тормыш иптәше Хөррия ханым, кызы Ләлә Әхмәтвәлиева, бергә эшләгән хезмәттәшләре, галим-галимәләре, район җитәкчеләре, татар теле укытучылары һәм мәктәп укучылары актив катнашты.

В.Х. Хаковка Килдураз урта мәктәбенең татар теле һәм әдәбияты кабинетында аңа багышлап стендлар чыгарылды, почмак булдырылды. Аның гаиләсе шәхси әйберләрен, китапларын һәм фотоларын безнең мәктәпкә бүләк иттеләр.

Вахит Хаков тәҗрибәле педагог, филолог-тюрколог, филология фәннәре докторы, Казан дәүләт университеты, Татарстан Республикасының атказанган фән эшлеклесе, Бөек Ватан сугышы ветераны белән без чын йөрәктән горурланабыз. Безнең күңелләрдә ул һәрвакыт олы җанлы, сабыр, тирән белемле туган тел сагында торучы, хөрмәтле остазыбыз булып сакланыр.

Мин эзләнү эшемне тагын да тулыландыру өчен, күренекле тел галименең киленнәре, Хакова Солтания апа белән әңгәмә оештырдым, күп мәгълүмат тупладым. Бу эзләнүләр мине канатландырып җибәрде. Үземә шундый нәтиҗә ясадым, бары тик тырышып укырга, куйган максатларга ирешергә кирәк дигән фикергә килдем.

## ӘДӘБИЯТ


1. Әһлиуллин М.Ә. Зөя буе – туган җирем / М.Ә. Әһлиуллин. – Казан: “Матбугат йорты” нәшрияты, 2005. – 314 б.
2. Хаков В.Х. Туган як һәм туган тел хисе / В.Х. Хаков. – Казан: Казан университеты нәшрияты, 2007. – 165 б.
3. В. Хаков.Тел – тарих көзгесе / В.Х. Хаков. – Казан:Татар.китап нәшрияты, 2003. – 175 б.

## СОДЕРЖАНИЕ

## ЭЧТӘЛЕК

***Кузьмина Х.Х.*** Научное наследие заслуженного профессора Казанского университета Вахита Хозятовича Хакова................................. 3

***Алеева Г.У.*** К вопросу наклонения и модальности в современном татарском языке........................................................................................ 6

***Алексеенко В.Н.*** Метафоризация в художественном произведении как когнитивный процесс (на материале романа Д. Брауна «Кодда Винчи») ........................................................................................... 10

***Әсхадуллина Г.Г.*** Татарларда баш киеме атамаларының гомуми үзенчәлекләре........................................................................................ 13

***Ahmetoğlu M., Kirillova Z.*** Yabanci dil örenimindeki problemler ve çözümler........................................................................................ 16

***Валиуллин И.А.*** Татар теле дәресләрендә флеш-карталар куллану............ 19

***Габизов И.И.*** Хәзерге вакытлы матбугатта сүзьясалышы (“Ялкын” яшүсмерләр журналы һәм “Ватаным Татарстан” газетасы мисалларында) ........................................................................................ 22

***Газизова И.Р.*** Милли мәдәният реалияләре һәм аларны татар теленә тәрҗемә итү үзенчәлекләре (Ч. Айтматовның «Буранный полустанок» («И дольше века длится день») әсәре мисалында) ...................................... 25

***Гайфетдинова Р.М., Саттарова М.Р.*** Татар телендә *[a]* авазының сүз башы позициясендә акустик үзенчәлекләре........................................ 28

***Галиева Г.Ф.*** Особенности преподавания турецкого языка в татарской аудитории........................................................................................ 32

***Галимбикова И.И.*** «Ватаным Татарстан» газетасындагы өстәлмәләрнең структур характеристикасы............................................... 35

***Галяутдинова Л.А.*** Спорт мәкаләләренә исем бирү үзенчәлеге............... 39

***Гәрапшина Л.А., Садриева И.И.*** Татар әдәбияты дәресләрендә предметара бәйләнешләрне исәпкә алып укыту........................................... 43

***Гобәйдуллина Л.Ф.*** Татар блогосферасында фразеологиянең стилистик кулланылышы........................................................................................ 47

***Динаэр.*** Формирование татарской коммуникативной лексики............... 49

***Закирҗанова Г.З.*** XIX гасырның ике телле сүзлекләрендә сәламәтлек өлкәсенә караган сүзләрнең килеп чыгышы............................................ 53

***Закирова А.Р.*** “Ватаным Татарстан” газетасында соңгы елларда чыккан мәкалә атамаларында җөмлә кисәкләренең бирелеше.............................. 57

***Закирянова Ф.Ф.*** Халык авыз иҗатында зоонимнарның кулланылышы........................................................................................ 61
***Ибраһимова Ф.Б.*** Татар һәм төрек телләрендә сыйфат дәрәҗәләре......... 64
***Ибраһимова Э.И.*** Туган тел дәреслекләрендә сөйләм теле лексикасының бирелеше............................................................................ 67
***Камалетдинова Р.К.*** Системалы укыту шартларында заман таләпләренә туры китереп, укучыларны рухи яктан тәрбияләү үзенчәлекләре........................................................................................ 72
***Камалова Д.И.*** В.Х. Хаковның стилистика өлкәсендәге эшчәнлеге......... 76
***Книсарина М.М., Сисенова А.Т., Жумалиева Г.С.*** Изучение тревожности старшеклассников в условиях пандемии COVID-19................................................................................................ 80
***Латыпова К.Р.*** Лексикографирование междометий в двуязычных словарях.................................................................................................. 85
***Мөбәрәкшина З.Н.*** Татар һәм рус телләрендә төс атамаларының мәгънәләре (фразеологизмнар мисалында) ............................................... 90
***Мөхәммәтшина А.Ф.*** Татар әдәбияты дәресләрендә гаилә фольклорын өйрәнү үзенчәлекләре........................................................................... 94
***Ногманова А.И., Сафиуллина Г.И.*** «Сәлам» укыту-методик комплекты ярдәмендә туган телне өйрәнүнең нәтиҗәлелегенә ирешү......................... 97
***Рахимова А.Ф.*** Татар массакүләм матбугат чараларында прецедент исемнәр һәм аларның функцияләре........................................................ 98
***Рахматуллина А.А.*** Роберт Миңнуллин шигыренә эксперименталь-фонетик анализ........................................................................ 99
***Сабирова Г.Р.*** Тел бизәкләрен өйрәнүче галим.......................................... 102
***Сабирова Н.Н.*** Балалар һәм яшүсмерләр матбугатында кеше шәхесе белән бәйле атамалар кулланылышы........................................................ 105
***Сәгъдиева И.М.*** Татар телен чит тел буларак укытканда компьютер технологияләрен куллану үзенчәлекләре................................................... 108
***Садыкова А.М.*** О проблемах и перспективах развития поликультурного образования........................................................................................... 111
***Сафина К.Р.*** Фатих Хөсни иҗатында туганлык атамалары....................... 113
***Сахабиева С.Р.*** Возможности применения интерактивных технологий в процессе социализации младшего школьника......................................... 116
***Тагирова Л.Г.*** Ф. Әмирхан мирасы.......................................................... 120
***Темирова Д.А.*** Личные и указательные местоимения в sms-сообщениях на singlish (на примере sms-сообщений корпуса sms nus) ......................... 124

***Узум С.О-Ф.*** Татар һәм төрек телләрендә исем сүз төркемен чагыштыру........................................................................................... 127

***Фаттахов И.Ф.*** Остаз хакында.............................................................. 131
***Фахретдинова Р.Н.*** «Яңа мәхәллә хәбәрләре» турында........................... 134
***Хәбибуллина А.Р.*** Ф. Әмирхан драматургиясенең тел чаралары
һәм алымнары........................................................................................ 137
***Хәмзина А.А.*** Татар теле дәресләрендә мәдәниятара компетенция
формалаштыру........................................................................................ 142
***Харисов Ф.Ф.*** Телгә өйрәтүдә интернет-технологияләрнең роле.............. 145
***Харисова Г.Ф.*** Развитие креативного мышления на уроках родного
языка и родной литературы (из опыта работы ОШИ «Лицей имени
Н.И. Лобачевского» КФУ) ........................................................................ 150
***Хисмәтуллина И.М.*** Татар телендә кисәкчәләрне өйрәнү тарихы............. 155
***Хөснетдинова Г.М., Зәйнуллина А.М.*** Ф. Әмирхан иҗатында
синонимнарның роле............................................................................... 159
***Шакирова Э.Г.*** Научная деятельность В.Х. Хакова в сфере 162
тюркологии.............................................................................................
***Шакирова А.Р.*** Лексикографическое описание мифологического
персонажа «Албасты» ............................................................................. 164
***Шәймәрданова Г.А.*** Татар телен чит тел буларак өйрәткәндә компьютер
технологияләрен куллану......................................................................... 167
***Яруллин А.А.*** Фәнгә багышланган гомер.................................................. 169

*Электронное научное издание*
*сетевого распространения*

# ХАКОВСКИЕ ЧТЕНИЯ – 2021

**Материалы Международной научно-практической конференции молодых ученых, посвященной 95-летию со дня рождения заслуженного профессора Казанского университета Вахита Хозятовича Хакова**

---

# ХАКОВ УКУЛАРЫ – 2021

**Яшь галимнәрнең Казан университеты атказанган профессоры Вахит Хөҗҗәт улы Хаковның тууына 95 ел тулуга багышланган халыкара фәнни-гамәли конференция материаллары**

Подписано к использованию 11.11.2021.
Формат 60х84 1/16. Гарнитура «Times New Roman».
Усл. печ. л. 10,2. Заказ 175/10

Издательство Казанского университета

420008, г. Казань, ул. Профессора Нужина, 1/37
тел. (843) 233-73-59, 233-73-28